ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№9 (333) – СЕНТЯБРЬ 2019

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

Көткәнне аклар вакыт

Мәгариф ветераннары: галстуклы Әлфия

«Бәләкәй комиктан» – СССРның халык артистына



ДАНИС ЗАРИПОВ – ХОККЕЙ ҺӘМ «ИНСТАГРАМ» ЙОЛДЫЗЫ

4 612750 670011

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская, Ольга Туманская,
Алёна Кутыркина, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Сафа Гәрәев, Мөршидә Кыямова,
Ксения Сёмина, Луиза Шарова, Әнвәр Шәрипов
Фотографлар: Лилиана Вәлитова, Александр Ефремов,
Ната Смирнова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта хоккейчы Данис Зарипов.
Фото «Татар-информ» МАнан алынды.
Михаил Захаров фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Татар телендә тираж: 1150 данә,
рус телендә: 2350 данә

Гомуми тираж: 3500 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № О-2555
Басарга кул куелды: 24.09.2019
Басмадан чыкты: 27.09.2019

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

Коммерция директоры:
Юлия Фәсәхова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ВАКЫЙГАЛАРГА БАЙ СЕНТЯБРЬ

Сентябрь вакыйгаларга бай булды. Юмарт һәм мәрхәмәтле. Жириновскийның Татарстанга карата күңелсез нотыгын да искә алмасак. Әйе, искә алып тормыйк. Иң күңеллесе – сентябрьнең башы безгә мулдан өләшкән җылыны искә алыйк. Җитмәсә, җылыга җәен туенып җитә алмадык. Моннан тыш, бу ай безгә парклар белән скверларыбыз, җәмәгать пространстволары өчен бүләккә архитектура премиясе дә китерде әле. Татарстандагы һәрбер ишегалдын төзекләндерү вәгъдәсе белән сөендерде – була гына күрсен, нинди киң колачлы ниятләр бит!

Озын сүзнең кыскасы, игелекле эшләр елның теләсә кайсы фасылын мәрхәмәтлерәк һәм җылырак итә ала, алай гына да түгел, дөньяны үзгәртә һәм саклый, дигән фикергә килдек без. Бәлки, самими яңгырар бу фикер, әмма күзгә күренеп тора бит барысы да.

Әнә шул игелекле эшләр турында яза да бу айда «Татарстан». Аларны эшләү, асылда, әллә ни кыен да түгел икән. Моның өчен йөрәгеңнең тиешле көйгә көйләнгән булуы гына кирәк.

СЕЗНЕҢ РЕДАКЦИЯГЕЗ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **933 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ

Владимир Акимов. «Көзге Алабуга урамы»

СЕНТЯБРЬ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

6. Зирәк диалог сәясәте.
Бердәмроссиялеләрнең оппозициядән өстенлеге нидә

10. Ишегалларын төзекләндерү.
Татарстанда яңа проект күпмегә төшәчәк

16. Сөтчелек тармагындагы инновацияләр.
Роботлы ферма ничек эшли

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

22. Күнекмәләр генә булсын, форсат табылыр...
Һөнәри осталык буенча дөнья чемпионаты кай ягы белән гаҗәпләндерде

34. Данис Зарипов – «Татарстан» редакциясендә.
Хоккей йолдызы боздагы һәм «Инстаграм»дагы җиңүләре хакында

36. Мәгариф ветераннары.
Яраткан укытучыларыбыз турында

46. Редакция кухнясы.
Мәдәният министры безне ни белән сыйлады

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

54. Кече Ватан патриотлары.
Габдулла Шамуков бәхетне нәрсәдә күргән

60. Тарихи сәхифә.
Мәүла Колый турынданиләр беләбез

65. Салаватка – кунакка.
Хыялны чынга ашыру өчен таулар күчерергә кирәкми

68. Рәхмәт, Димаш!
Казах җырчысы кемнең хыялын тормышка ашырды

70. Җилкәнле регата.
Наркотикларга бәйлелектән ничек котылырга

76. Китап киштәсе.
Бичуралар... без түгелме?

84. Татар авыллары.
Арташ: кечкенә авылның үз рәхәте

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
www.protatarstan.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

12.09

Евгений Морозов, актер, «Зөләйха күзләрен ача» сериалында Игнатов ролен уйнаучы, – Казандагы Ленин исемендәге КМСда, Гүзәл Яхина романын экранлаштырудан өзекләрне күрсәтер алдыннан:

– Бер генә режим да, ир-атлар тарафыннан бүген әйтелә торган бер генә аклану сүзе дә бер бала хакына тормый. Ә бүген Сталинга һәйкәл куярга, һәм аны яхшы менеджер дип мактарга маташалар...

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

12.09

Андрей Макаревич – 13нче «Аксёнов-фест» әдәби-музыкаль фестиваленә багышланган матбугат конференциясендә:

– Василий Аксёнов гаҗәеп эчке ирекә ия шәхес иде, һәм ул ирек, үзенең теләгенә бәйсез рәвештә, аның текстларының һәр абзацында чагылыш тапты. Бу контрольдә тотылучы хисләр дә, әдәби һөнәрчелек тә түгел, моңа махсус өйрәнеп булмый. Минемчә, аның кабатланмас стиле бу, һәм без аңа соклана гына алабыз.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

12.09

Александр Васильев, мода тарихчысы, сәнгать белгече, «Модный приговор» тапшыруларын алып баручы, – Казандагы иҗат кичәсендә:

– Мода – төзүче, барлыкка китерүче түгел, киресенчә, ул һәрвакыт үз-үзен юкка чыгаруга юнәлтелгән. Мода уза, ә менә стиль мәңгелек булып кала. Мин барыгызга да экономияләргә һәм үз стилегезне булдырырга киңәш итәм, шул чакта сез һәрвакыт трендта калачаксыз.

Фото: «Татар-Информ» МА

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Татарстанда сайлаулар **НИЧЕК** үтте

Татарстан ишегалларын төзекләндерү **КҮПМЕ** тора

Роботлы фермалар **НИЧЕК** эшли

КӨТКӘННЕ АКЛАР ВАКЫТ

Көтелмәгән хәлләрсез. Сентябрь аенда Татарстанның Дәүләт Советына булып узган сайлау нәтиҗәләрен ике сүз белән әнә шулай бәяләргә буладыр. Яңа парламентта күпчелек тавыш алган хакимият партиясенең ышанычлы җиңүе дә, КПРФның икенче урында булачагы да сайлауларга кадәр үк фаразланган иде. Сайлаучылар сәясәт белгечләренә ялгышырга урын калдырмады – фаразланган саннарның аз гына үзгәрүен исәпкә алмаганда.

Автор:
Сафа Гәрәев

Шул ук вакытта сайлау нәтиҗәләрен шиксез җиңүгә ирешүчеләр дә, күпмедер дәрәҗәдә оеша алган оппозиция вәкилләре дә үз активларына язып куя ала. Беренчеләре, бердәмроссиялеләр, – миллион ярымга якын (2061059 тавыш бирүченең) сайлаучының ышанычын казанып, партия исемлеге буенча гына да парламентта 44 депутат портфеленә ия булды. Икенчеләре, КПРФ, – 10, 74 процент тавыш җыеп, парламентка үзенең алты вәкилен юллады – бу, бишенче чакырылыш Дәүләт Советы белән чагыштырганда, ике тапкыр күбрәк, дигән сүз.

ХАКИМИЯТ ПАРТИЯСЕ: КӨНДӘШЛЕЛЕКСЕЗ

Бердәмроссиялеләрнең оппонентлары, әлбәттә, быелгы

Фото: Александр Ефремов

сайлауларда көндәшләренең барыбер тавыш җыюда ниндидер өлешне югалтуларын әйтми кала алмаячак. Шулайдыр, тик, әйдәгез, реалист булыйк. Биш ел элек сайланган бердәмроссиялеләрнең уңышы ил әлегә Көнбатыш санкцияләренең йогынтысын тоеп өлгермәгән вакытка туры килгән иде, ул чакта тотрыклы икътисадый күтәрелеш тормыш дәрәҗәсенең үсешен тәэмин итте. Бүген әлеге үсешне тәэмин итү күпкә авыррак, бизнесны үстерү һәм икътисадта, социаль өлкәдә киң колачлы проектларны тормышка ашыру да кыенрак. Моңа да карамастан, Татарстанда, башка төбәкләрдән аермалы буларак, уңышка ирешелә, шуңа күрә миллион ярымга якын сайлаучы аларга тавышын бирә дә. Республиканың ил буенча берсүзсез хакимият партиясен яклап тавыш биргән беренче җиде төбәге арасына керүе очраклы түгел.

Партия исемлеге буенча бердәмроссиялеләр алган тавышларның күпмедер күләмдә югалуына (2014 елгы сайлаулар белән чагыштырганда – ред. иск.) килгәндә исә, монда шуны да исәпкә алырга кирәк: соңгы вакытларда үзәк тарафыннан кайбер популяр булмаган карарларның кабул ителүе, әлбәттә, үзенең йогынтысын ясамый кала алмады, әйтик, пенсия яшенең күтәрелүе, НДСның арттырылуы. КПРФтан депутатлар саны артуы да күпмедер дәрәҗәдә әлеге карарларның кайтавазы, әлеге адымнарны тәнкыйтьләп, оппозиция электоратның тотрыксыз өлешен үз ягына аударырга тырышты һәм хәтта кайбер уңышларга да ирешеп диярлек була. КПРФ иң күп тавыш җыя алган территорияләр арасында Яшел Үзән шәһәрен, Яшел Үзән районын, Буаны атарга мөмкин. Әмма бу районнарда да коммунистлар 20 процентлы чикне уза алмады. «Җирле әһәмияттәге көрәшләрдә» КПРФ ирешкән уңыш, футбол терминологиясен кулланып сөйләшкәндә, исәптә аерманы киметеп җиңелүгә генә кайтып калды. Өстәвенә, оппозициянең башка төбәкләрдә еш яңгыраган традицион аклану сүзләре Татарстанга туры килми. Мәсәлән, сайлауга килүчеләр санының түбән булуы, янәсе, сайлауга килмәүчеләрнең барысы да хакимият партиясенә каршы тавыш бирүчеләр дигән тезис берничек тә безнең республикада эшли алмый. Сайлау участокларына килгән 71 проценттан артык халык – Татарстанда бердәмроссиялеләрнең шиксез һәм абсолют җиңүенә иң яхшы дәлил.

КҮЗӘТҮЧЕЛӘР РЕКОРДЫ

Яраткан оппозиция ягыннан массакүләм фальсификацияләр, бюллетень ташлаулар, административ кысулар турында да көчле белдерүләр ишетелми диярлек. Кулланыштан әлеге тезисны алып ташлау өчен, әйтергә кирәк, оппозиция үзе дә тырышты. Федераль эксперт, хокук саклаучы Александр Брод «Волга» экспертлар клубының Татарстанда сайлау йомгакларын анализлауга багышланган утырышында болай дип белдерде:

– Ачык мәгълүмат чыганакларына, Татарстан Иҗтимагый палатасы һәм республика ҮСК биргән белешмәләргә караганда, КПРФ шактый кискен каршылык күрсәтте. Төрле төбәкләрдән 1000ләп яисә 1500ләп сайлаучы, һәм шулай ук Дәүләт Думасы депутатлары килеп, үзләренә игътибарны җәлеп итүне шактый катгый рәвештә таләп итте.

Ләкин күзәтүчеләрнең рекордлы саны да нәтиҗәләргә йогынты ясарга сәләтле хилафлыкларны таба алмады, нәкъ менә шул рәвешле оппозицияне, массакүләм шелтә-үпкәләр һәм шикләр таратып, җәмәгатьчелектә шау-шу куптару өметеннән мәхрүм итте. Сайлау нәтиҗәләре хәтта җиңелүчеләргә дә аңлаешлы һәм төшенерлек булып чыкты. Ләкин аларга, мөгаен, бер нәрсә аңлашылмыйдыр. Шундый катлаулы чорда бердәмроссиялеләр ничек итеп зур күпчелекнең тавышына ия була алды соң? Чыннан да, нәрсә хисабына?

АКЫЛЛЫ САЙЛАУЧЫГА ИСӘП ТОТУ

Татарстанда быелгы сайлауларда катнашучы затларның стратегиясен һәм тактикасын яхшырак бәяләр өчен, әйдәгез, ун ел элек уртача алынган төбәктә сайлау кампаниясенең ничек узуын искә төшерик. Һәр баганада агрессив агитация, кандидатларның сүзләрдә идеаллаштырылган портретларын күрергә мөмкин иде. Әллә каян кычкырып тора торган лозунглар, фантастик вәгъдәләр һәм бераз гына җитди булган һәр казанышны атау... Сәяси ыгы-зыгыдан туйган сайлаучы сайлау көне килеп җиткәндә: «Кайчан үтәр икән бу көн...» – дигән уй белән яши иде.

АЛТЫНЧЫ ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЛАРЫН САЙЛАУ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Республика һәм бер мандатлы округлар буенча мандатларның гомуми саны:

Бердәм Россия	85
РФ Коммунистлар партиясе	6
Россия либераль-демократик партиясе	1
Гадел Россия	1
Үсеш партиясе	1
Россия пенсионерларының гаделлек өчен партиясе	0
Россия коммунистлары	0
Үзләрен үзләре тәкъдим итүчеләр	6

Быел Татарстанда бөтенләй башкача булды. Юк, сайлау алды кампаниясен берәү дә сызып ташламады, әлбәттә. Ләкин аны оештыруның төп ысуллары шактый үзгәрде. Артыгы белән чәйнәлгән мәгълүматны, кеч-кенә генә вәгъдәләр белән тәмләп, сайлаучы каршына өеп кую – әлеге нафталин исе килеп тора торган тезис барыбер эшләмәс иде. Илнең демократик үсеше барышында пассив һәм барысын да үзенә сеңдерергә күнеккән сайлаучыны уйлый белә торган һәм инициативалы сайлаучы алыштырды. Шуңа йөз тотылды, ягъни аңа, сайлаучыга, күпмедер дәрәҗәдә хәтта инициатива да бирелде.

Асылда хакимият партиясе теләге булганнарның барысына да: «Сез үзегез төп проблемаларыгызны билгелисез, аларны чишү юлларын тәкъдим итәсез, без, үз чиратыбызда, иң кирәклесен сайлап алып, аны гамәлгә ашырырга алынабыз», – диде. Сайлаучыларның әлеге тәкъдимне кабул итеп аласыларына шикләнмәскә мөмкин иде. Татарстанлыларның хакимият белән узган еллар дәвамында тупланган мондый хезмәттәшлеге тәҗрибәсе үзенең нәтиҗәлелеген күрсәтте. Бәхәс-

ле моментларны уртак көч белән җайлау мөмкинчелегенә ирешеп, Казанның яңа генпланының җәмәгатьчелек тарафыннан актив тикшерелүе, төзекләндереләсе парк, сквер һәм яр буйларын күп очракта халык үзе билгеләп, татарстанлыларның җәмәгать урыннарын яңартуда эшлекле катнашуы – әлеге хезмәттәшлеккә ике генә күркәм мисал.

Нәкъ менә хакимиятнең сайлаучылар белән сөйләшә белүен һәм, иң мөһиме, проблемалар турында ачык итеп әйтергә курыкмавын «Волга» экспертлар клубы утырышына җыелучылар Татарстанда бердәмроссиячеләрнең уңышын билгеләүче фактор дип атады. «Петербургская политика» фонды президенты Михаил Виноградов, илнең уртача статистик төбәге өчен хас булмаган әлеге якын килүне билгеләп, болай диде:

– Проблемалы темаларны келәм астына яшерергә тырышу юк. Без биредә проблемалы темаларны яшерүдән бигрәк, алар турында сөйләшүгә омтылышны күрәбез. Бәлки, бу уртача статистик төбәкләргә хас та түгелдер, гадәттә башкача якын килү күзәтелә анда: «Сайлаулардан соң хәл итәрбез әле!» Республикада исә башкача эшләнде.

ЯҢА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР ТАНТАНАСЫ

Уртача статистик төбәкләргә Татарстан сайлаучылар белән максималь конструктив диалог төзергә мөмкинлек бирүче заманча инструментлардан тулы көченә файдалана алуын да күрсәтте. Беренче чиратта сүз «Минем депутат» сервисы турында бара, аның ярдәмендә татарстанлылар, сайлаучылар белән планлаштырылган очрашуларны һәм кабул итү көннәрен көтеп тормыйча, үзләренең теләкләрен, тәкъдимнәрен, шикаятьләрен парламентарийларга һәм депутатлыкка кандидатларга җиткерә алдылар.

– Быелгы сайлауларның яңалыгы – «Минем депутат» онлайн-сервисының, күчмә кабул итү бүлмәләренең эше, – дип саный узган бишенче, хәзер исә алтынчы чакырылыш ТР Дәүләт Советы депутаты Камил Садриев. – Без халыкка таба тагын бер адым атладык. Һәркем хакимияткә карата үз мөнәсәбәтен белдерә алды.

«Бердәм Россия»нең мобиль кабул итү бүлмәләре, кайнар линия телефоннары, ТР Дәүләт Советы депутатлыгына кандидатлар кизү торган колл-үзәк барлык бюрократик каршылыкларны җиңәргә ярдәм итте. Вәкиллекле хакимиятнең потенциаль вәкилләре үз сайлаучылары белән турыдан-туры аралаша алды, өстәвенә, сайлаучыларның үзләренә уңайлы вакытта. Һәм ике як та яңа мөмкинлекләрдән тулысынча файдаланды. «Минем депутат» сайтына гына да 12 меңнән артык мөрәҗәгать килде.

– Кешеләр колл-үзәккә депутатлыкка кандидат булган, карарлар кабул итә алучы кеше белән конкрет сөйләшүгә өметләнеп шалтыраталар, – дип аңлата Камил Садриев. – Элемтәнең икенче очында булдыклы кандидат утыруын тоясылары килә. Миңа, кандидат буларак, сайлаучыларыбызның ни дәрәҗәдә җитди мәсьәләләрне күтәрүләрен ишетү мөһим булды.

ИХЛАС КҮҢЕЛДӘН, ЯЛГАННАРСЫЗ

Башка төбәкләрнең сайлауларны әзерләү һәм үткәрү буенча Татарстан тәҗрибәсен куллану мөмкинлеге турында сөйләгәндә, шулай да, мөһим бер нәрсәне истә тотарга кирәк. Теләсә кайсы, хәтта иң заманча сайлау алды технологияләре дә бер очракта гына яхшы һәм көткән нәтиҗәләрне бирәчәк: әгәр сайлаучы үзе юллаган теләкләренең игътибарсыз калмавына, үзе тавыш биргән

кандидатның вәгъдә иткәннәрен үти алуына ышанса гына.

Бу яктан караганда бик азлар гына Татарстандагы бердәмроссиялеләргә тиңләшә ала. Соңгы бишьеллыклар шуны раслый: сүзләрендә торалар, вәгъдә бирәләр – үтиләр. Шактый катлаулы шартларда икътисадны үстерү – бу абстракт саннар гына түгел. Югары технологияле медицина, боз ареналары һәм бассейннар, яңартылган парклар һәм скверлар, төзекләндерелгән яр буйлары, зур һәм кечкенә авылларда ачылган клублар... Боларны һәм тагын башка бик күп нәрсәләрне кешеләр күреп кенә калмый, тоя һәм куллана да: тормыш сыйфаты чыннан да яхшыра.

Шуңа күрә сайлаулар алдыннан яңгыраган һәм халыкка җиткерелгән яңа колачлы планнарга абсолют ышаныч та бар. Якындагы өч ел эчендә барлык күпфатирлы йортларның ишегалларын төзекләндерүне күздә тоткан, чыгымнары буенча бик җитди программаның (сүз уңаеннан, 50 миллиард сум) тормышка ашырылачагына шик юк.

– Төгәл көн тәртибе, лоббистик көч буларак, республика өчен мөһим темаларны алга этәрергә сәләтле «Бердәм Россия» өчен тавыш бирергә анык рациональ мотивация бар, – дип билгеләп үтте Михаил Виноградов.

Татарстанда бердәмроссиялеләрнең сайлау алды кампаниясенә хас тагын бер үзенчәлекне дә күрми мөмкин түгел иде. Монда «паровоз» схемасыннан баш тарттылар, бу очракта партия исемлегенә төп урыннарны танылган, абруйлы шәхесләр били, ә аннан, сайлаулардан соң, алар тыйнаграк иптәшләре исәбенә үз мандатларыннан баш тарталар. Теоретик яктан «паровоз» схемасы ихтимал булган тавышларның күпчелеген тәэмин итә, ләкин аннан соң сайлаучы үзен алдангандай хис итә – берәүләр өчен тавыш бирелә, парламентта икенчеләр эшли...

Хакимият партиясе вәкилләре шуны төгәл аңларга мөмкинлек бирде: партия исемлегенә кергән кандидатлар, элек нинди вазыйфаи урын биләүләренә карамастан, җиңүгә ирешкән очракта депутат мандатларыннан баш тартмаячак. Министрлар да, ведомство җитәкчеләре дә, район башлыклары да. Бердәмроссиялеләрнең ниятләренең ихласлыгы, исегезгә төшерик, алга таба расланды да. Авыл хуҗалыгы министры Марат Әхмәтов, җир һәм милек мөнәсәбәтләре министры Азат Хамаев, «ТАТМЕДИА» республика агентлыгы җитәкчесе Айрат Зарипов, Алабуга районы башлыгы һәм Алабуга мэры Геннадий Емельянов, Яшел Үзән районы башлыгы һәм Яшел Үзән мэры Александр Тыгин, үз кәнәфиләрен калдырып, алтынчы чакырылыш ТР Дәүләт Советы депутаты вазыйфасында сайлаучыларның наказларын үти башлады.

ХАТАГА УРЫН КАЛДЫРМЫЙЧА

Яңа парламент формалашты, депутатлар таныклыкларын алды. Дәүләт Советында абсолют күпчелеккә ирешү бердәмроссиялеләргә төп постларга үз кандидатураларын проблемаларсыз гына үткәрергә һәм уйлаган-ниятләгәннәрен тормышка ашырырга мөмкинлек бирә. Җиңүме? Әлеге сорауга, минемчә, Казан мэры Илсур Метшин барысына караганда да төгәлрәк җавап бирде:

– Миндә мэр буларак җиңүдән баш әйләнү тойгысы юк. Кызганыч, телевизордан кайбер коллегаларымнан киресен ишетергә туры килә. Менә нәрсә әйтер идем: сайлау алды эшебезнең нәтиҗәсе буларак яңгыраган фикерләрне без игътибар белән тыңладык һәм тыңлыйбыз. Бу уйланырга бер сәбәп. «Ура-ура! Без җиңдек!» – дип шапырыну белән мин бөтенләй килешмим. Чишелеше көтелгән проблемалар бик күп. Халыкка үзгәрешләр, яңарышлар кирәк, без үзебезнең уртак эшебездә калышмаска, тавыш бирүчеләр көткән һәм алдыбызга куйган бурычларны үтәргә өлгерергә тиешбез.

Шуңа күрә уңышлар турында сөйләшүне киләчәккә калдырыйк. Әлегә парламентарийлар – бердәмроссиялеләр генә түгел, Дәүләт Советына узган оппозиция вәкилләре дә – якындагы биш елга ышаныч кредиты алды. Һәм бу ышанычны аларга бергә акларга туры киләчәк.

– Партия һәм башка юнәлешләребез төрле булуга карамастан, без сайлаучыларыбызга хезмәт итәбез. Алар бездән шуны көтә, – дип сөйләде ТР Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин алтынчы чакырылыш депутатларының оештыру җыелышында. – Яңа чакырылышның парламент корпусына республиканы үстерү, халык проблемаларын хәл итүгә караган актуаль бурычларны чишү юнәлешендә эшләргә туры киләчәк. Теге яисә бу закон буенча максатка ирешүнең иң яхшы юлларын бергә эзләячәгебезгә шикләнмим. Алда безнең өчен тавыш биргәннәрнең ышанычын аклау буенча җитди һәм җаваплы хезмәт көтә.

Татарстан сәясәте аксакалының әлеге сүзләре белән килешми мөмкин түгел.



ҺӘР ЙОРТКА – ЗАМАНЧА ИШЕГАЛДЫ

Республикада халыкка ишегалларын һәм ишегалларына халыкны кайтарачак программа гамәлгә кертелә башлаячак.

Автор:
Ксения Сёмина

8 сентябрь иртәсендә Казанның Габишев урамындагы 23 нче һәм 25 нче йортлар ишегалдында гомуми җыелыш үткәрелде: әби-бабайлар, әти-әниләр, балалар (шулай ук хәтта күгәрченнәр һәм бакчада яшәүче песи дә!) журналистларга үз ишегалларындагы тормышның яхшырак, җитерәк, күңеллерәк булуын теләүләре турында сөйләде. Әлеге ике йортта, шулай ук республикадагы барлык күпфатирлы йортларда яшәүчеләрнең өмете акланыр да кебек: нәкъ менә 8 сентябрьдән Татарстан яңа «Безнең ишегалды» программасын әзерләүгә керешә.

ТАШ ТАРТМАДА ЯШӘҮ ТУЙДЫРДЫ

Габишев урамындагы 23 нче йортны 1983 елда салганнар. Ишегалдын мәңгелеккә дип төзегәннәр, ахрысы, – футбол кыры булырга тиешле мәйданның нигезенә бетон плитәләр тезгәннәр. Тимер таган-карусельләр, инде берничә буын бала-чаганы үстереп, үз бурычын күптән үтәгән. Җирле флора һәм фауна һәркайсы үз тормышы белән яши. Ишегалдының төрле почмакларындагы ниндидер махсус сортлы розалар утыртылган чәчәк түтәлләре әлеге фонда күзгә бигрәк тә сөйкемле булып күренә.

Классик сүзләрен үзгәртеп әйтсәк, барысы да булмаса да, шәһәр ишегалларының күпчелеге бүген бер үк дәрәҗәдә бәхетсез.

Фото авторныкы

– Оят булса да әйтим әле, безнең икенче подъезд янын бәдрәфкә әйләндереп бетерделәр инде! – бер апа мине күршеләре һәм журналистлар төркеменнән читкәрәк тарта һәм тәрәзә төбендәге тәртипсезлекләр белән тәфсилләбрәк таныштыра.

– Беркем дә бернәрсә дә эшләмимени? – дип кызыксынам мин. Шулай да нәрсәдер эшләнә икән әле.

– Моннан берничә ел элек ишегалдындагы юллар сафтан чыкты. Коляска этеп йөрү түгел, җәяү йөрерлеге дә калмаган иде. Без район хакимиятенә мөрәҗәгатьләр яза башладык. Һәм менә быелтыр безне программага керттеләр һәм юлларны ясадылар, – дип сөйли 23 нче йортның подъезд буенча җаваплысы **Галина Загайнова**.

– Корыган агачлар, куаклар бар, шулар арасына чүп ташлыйлар – моннан без берничек тә үз көчебез белән генә котыла алмыйбыз. Бер генә эскәмия дә юк. ишегалдында яшеллек күп, ә менә утырыр урын юк, – ди 25 нче йортта яшәүче **Валентина Лазарева**.

– Юлларны ясагач, парковка мәсьәләсе хәл ителә язды. Әмма башка проблема баш калкытты – бездә пенсионерлар өчен бернинди урын да юк. Утырып, рәхәтләнеп аралашыр идек, – ди Галина Загайнова. – Без, проект ясаучылар килер дә, безнең теләкләрне исәпкә алып, территорияне планлаштырыр, дип өметләнәбез.

Галина белән бергә якындагы мәктәпкә сайлау участогына барабыз. Сайлаганнан соң, Галина Григорьевнага «Безнең ишегалды» анкетасын бирәләр. Юл һәм тротуарларны асфальтлау, урамдагы яктырткычларны ремонтлау, эскәмия һәм чүп савытлары кую, көнкүреш калдыкларын җыю мәйданчыкларын төзекләндерү, балалар мәйданчыклары булдыру, йорт

– Ишегалдын төзекләндерү буенча да без нәкъ шулай ук мөрәҗәгатьләр яздык – безнең хакимияткә дә, шәһәр башкарма комитетына да, мэрга да, Татарстан Президентының кабул итү бүлмәсенә дә. Моннан берничә көн элек миңа шуннан шылтыраттылар һәм «Безнең ишегалды» программасы әзерләнүен хәбәр иттеләр. Әлбәттә инде, безнең бу программага керәсебез бик килә.

– Безгә спорт мәйданчыгын ясарлармы-юкмы икәнен белер өчен, мин бүген инде иртәдән бирле биредә йөрим, – ди Никита. Ул дүртенче сыйныфта укый. Көрәш секциясендә шөгыльләнмәгән көннәрендә Никита күрше малайлары белән урамга уйнарга чыга. Хәзерге ландшафтны файдаланып, бала-чага үзенә төрле уеннар уйлап таба. Тик аларның да футбол яки волейбол уйныйсы, воркаут-тренажерда сикерәсе, дивар-кыя буйлап өскә үрмәлисе килә...

– Мондый таш тартмада баланы иҗади шәхес итеп тәрбияләп буламыни? Ул бала чагыннан гүзәллек арасында тәрбияләнергә тиеш. Монда яшәүчеләр бик актив, үз акчабызга үсентеләр сатып алабыз, аларны утыртабыз, карап үстерәбез, әмма бу гына җитми бит. Балалар мәйданчыгы кирәк! Безнең балалар күрше ишегалларына барып уйный, – дип сөйли 23 нче йортта яшәүче **Әлфия Абдуллина**.



яны территорияләрен яшелләндерү – гражданнар шундый 10 пунктның үз ишегаллары өчен кирәкле һәркайсы янына тамга куярга тиеш.

Галина Григорьевна янына күршесе килә:

– Галь, ә син яктырткычларга тамга куйдыңмы?

Хатын-кызлар ишегалдына өстәмә яктырткычлар кую кирәкме-юкмы икәнен тикшерә башлый. Ә чүп савытлары? Ә яшелләндерү? Процесс бара...

БАШТА ИШЕГАЛДЫ, АННАРЫ ЯР БУЕ

Татарстанлылар 8 сентябрьдә тутырган анкеталарны эшкәртү тулы куәтенә бара. Шул нәтиҗәләрдән чыгып, республика 2022 елга кадәр Татарстандагы барлык күпфатирлы йортларның ишегалларын яхшы якка үзгәртергә җыена.

Әлеге мәсьәләнең алтарихы болайрак: «Бердәм Россия» партиясенең ишегалларны төзекләндерү инициативасын 2019 елда республика Президенты Рөстәм Миңнеханов хуплый һәм «Безнең ишегалды» программасын 2020 ел азагына кадәр кабул итәргә күрсәтмә бирә. Аның өч еллык бюджеты, нефть компанияләре акчасын да кертеп, якынча 50 миллиард сум тәшкил итәчәк.

– Республиканың барлык ишегалларын тәртипкә китерү программасын, кертеләсе үзгәрешләр җәһәтеннән, Казан өчен Универсиада белән чагыштырып була. Безнең көнебез шул мәйданнан башлана бит. Иртүк ишегалдына чыгуга ук уңай үзгәрешләр күрсәгез, сез тормышның да үзгәрүен сизәчәксез. Моның өчен нинди дә булса матур яр буена барып җитү дә кирәкмәячәк, – дип шәрехли программаны Татарстан Президенты ярдәмчесе Наталия Фишман-Бекмамбетова. – Күпфатирлы йортта яшәүчеләрнең уртак мөлкәтенә дәүләт үз акчасын кертә. Бу әле моңарчы күрелмәгән хәл.

Аның әйтүенчә, Казан, Яр Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт һәм Яшел Үзәндә 2017 елда ук ишегалларын төзекләндерү буенча «пилот» җәмәгать тикшерүләре уздырылган.

Быелга кадәр Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгы, Техник инвентарьлаштыру бюросы белән берлектә, гомуми мәйданы 68,5 миллион квадрат метрлы 8861 ишегалдына (Татарстандагы күпфатирлы йортлар ишегалларының 100 проценты) экспертиза үткәргән.

– Бу мәйданның якынча чиреге начар сыйфатлы асфальт белән капланган. Хисаплауларны без шуңа нигезләнеп тә башкардык. Асфальт җәю, контейнер мәйданчыклары кую, яшелләндерү һ.б. бәясен исәпкә алдык, – дип сөйләде журналистларга Татарстанның төзелеш министры Ирек Фәйзуллин.

Анкета – әзерлек эшенең дәвамы. 8 сентябрьдә ул Татарстанның барлык күпфатирлы йортларының 90 проценты урнашкан 14 шәһәрдә һәм Васильево, Осиново, Җәлил, Кама Аланы бистәләрендә үткәрелгән. Нәтиҗәләре «Безнең ишегалды» программасын төзегәндә файдаланылачак.

– Без инвентарьлаштыру нәтиҗәләрен һәм халык фикерен чагыштырып уртаклыкларны ачыклыйбыз һәм шуннан чыгып программаны формалаштырачакбыз. Ишегалларындагы коммуникацияләр һәм инфраструктураны хәзер һәм киләчәктә ремонтлау да игътибарга алыначак, – дип сөйләде Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары Алексей Фролов. – Соңгы өч елда 2800дән артыграк ишегалды ремонтланды, ә 735 ишегалды яңа төзелә торган йортларныкы, әмма программа әлеге объектларга да кагылачак. Без барлык теләкләргә дә колак салачакбыз. Казанда, мәсәлән, Мәскәү һәм Идел буе районнарында кайчандыр фонтан атып торган ишегаллары бар. Әгәр идарәче компанияләр һәм анда яшәүче халык алардан файдалану һәм карап тоту мәсьәләләрен хәл итсә, нишләп шул фонтаннарны торгызмаска ди?

Казан Кремленең рәсми вәкиле Лилия Галимова әйтүенчә, һәр ишегалды буенча нәтиҗәләр ноябрьдән дә соңга калмый нәшер ителәчәк. 40 волонтердан торган төркем татарстанлыларның барлык теләкләрен махсус мобиль кушымтага кертәчәк һәм бердәм база төзиячәк.

– Юллар һәм тротуарга асфальт җәю 6,57 балл җыйган, икенче урында – балалар өчен уен мәйданчыклары булдыру, өченче урында – йорт яны территорияләрен яктырту, – дип, анкеталарның беренче нәтиҗәләре белән таныштырды Лилия Галимова һәм әлеге саннарның Татарстан буенча уртача булуын искәртте. Тулаем алганда исә төрле районнарда яшәүчеләр төзекләндерүнең төрле төрләренә өстенлек биргән.

Шулай булса да, проект төзүчеләр әлеге киңколачлы процессны оптимальләштерү өчен «уртача ваклаучы» табарга өметләнә.

– Без ишегалларын типлар буенча тикшерәбез, эшкә теге яки бу конфигурация белән килү юлларын сайлыйбыз, элементлар конструкторын эшлибез. Минемчә, бер 12–15 типтагы ишегалды булачак, – ди Наталия Фишман-Бекмамбетова. Әмма проектлар буенча соңгы карар милекчеләрнең коллектив карары нигезендә кабул ителәчәк.

ТАТАРСТАН
иҗтимагый-сәяси һәм популяр журнал (vertical side text partially: яңалыкларны һәм якындагылар турында)

«Татарстан» журналына ничек язылырга?

1. **ТР элемтә бүлекләрендә «ПОЧТА РОССИИ» каталогы буенча:**
6 айга язылу бәясе – 933 сум (П2378 – рус телендә; П2381 – татар телендә);
12 айга язылу бәясе – 1866 сум (ПА471 – рус телендә; ПА468 – татар телендә).
2. **podpiska.pochta.ru сайты аша:**
РФ буенча индекс П7076 – рус телендә; П7077 – татар телендә;
ТР буенча индекс П2378 – рус телендә; П2381 – татар телендә.
3. **ТР Дәүләт хезмәтләре порталы («Подписка» бүлеге) аша.**
4. **«УРАЛ-ПРЕСС КАЗАН» ҖЧҖ альтернатив хезмәте аша:**
тел. 204-16-20 (Казан, Яр Чаллы, Әлмәт шәһәрләре буенча гына).
5. **Россиядән читтә – элеккеге БДБ илләрендә һәм ерак чит илләрдә –**
түбәндәге электрон адрес буенча: podpiska@sootechestvennik.agency.
6. **Журналның электрон версиясенә онлайн-язылу – pressa.ru сайты аша.**
7. **«Татарстан» журналы редакциясендә түбәндәге адрес буенча:**
Казан ш., Декабристлар ур., 2, 11 кат, тел.: (843) 222-09-79, e-mail: milyaushanb@tatmedia.com

Федеральное государственное унитарное предприятие "Почта России" Ф. СП - 1
Бланк заказа периодических изданий

АБОНЕМЕНТ На газета **журнал** П2381 (индекс издания)

Татарстан на татарском языке
(наименование издания)

Количе ство комплектов

На 2020 год по месяцам

1	2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12
x	x	x	x	x	x						

Куда ____ (почтовый индекс) ____ (адрес)

Кому ____

Линия отреза

ПВ	место	литер

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА П2381 (индекс издания)

На газету **журнал** Татарстан на татарском языке
(наименование издания)

Стои - мость	подписки	933 руб. 00 копеек	Количество комплектов	
	каталож - ная	руб.		
	переадре - совки	руб.		

На 2020 год по месяцам

1	2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12
x	x	x	x	x	x						

почтовый индекс | Город, село, область, Район

код улицы | улица

дом | корпус | квартира

Реклама 16+

ЩЕЛКОВО АГРОХИМ

Соединяем науку и практику

«Щелково Агрохим» – один из крупнейших российских производителей средств защиты растений, биопрепаратов и агрохимикатов, семян сахарной свеклы, зерновых и зернобобовых культур.

Высокий научный потенциал, мощная производственная и научно-исследовательская база позволяют создавать и выводить на рынок современные инновационные решения в области защиты растений. Специалистами предприятия разработаны и внедрены уникальные препаративные формы: микроэмульсии, концентраты коллоидных растворов, масляные концентраты эмульсий, масляные дисперсии. Все разработки нацелены на достижение максимального результата в защите сельскохозяйственных культур.

Предприятие имеет Центр Агротехнологий, созданный для оценки эффективности и отработки технологий возделывания культур в условиях каждого конкретного региона; сотрудничает с российскими научно-исследовательскими институтами, такими как ВИЗР, ВНИИФ, ФНЦГ им. Эрисмана, НИИД, ВНИИСС, РГАУ МСХА им. К.А. Тимирязева и др. Сегодня предприятие производит более 25 тыс. тонн продукции на сумму более 16 млрд руб. в год. В ассортименте «Щелково Агрохим» – свыше 120 наименований продукции. Представительства компании работают от Калининграда до Владивостока, а также в странах СНГ, Алжире, Монголии, Сербии и Турции.

Направления работы:

- производство ХСЗР и агрохимикатов
- выпуск профессиональных средств защиты растений и микроудобрений, в том числе для владельцев ЛПХ под ТМ «Октябрина Апрелевна»
- опытное хозяйство ООО «Дубовицкое» в Орловской области – современный завод по производству высококачественных семян зерновых, зернобобовых и крупяных культур
- создание гибридов сахарной свеклы на базе селекционного центра «СоюзСемСвекла» в Воронежской области
- производство семян сахарной свеклы на заводе «Бетагран Рамонь» мощностью 400 тыс. посевных единиц в год
- поставка семян подсолнечника, кукурузы, сои фирм «АктивАгро», Euralis[1] и «ЛимагренРУ»
- производство сеток для защиты интенсивных садов от града и птиц в ООО «Бетанет»
- производство эмбрионов элитных пород КРС в первом российском селекционно-генетическом центре ООО «Бетагран Липецк»
- официальный дилер двух итальянских заводов по производству сельхозтехники – Projet[2] и Mascar[3]

420066, г. Казань, ул. Красносельская, д. 51А.
Тел.: +7 (843) 562-34-85
E-mail: kazan@betaren.ru

Реклама

www.betaren.ru

[1]Юралис, [2]Проджет, [3]Маскар.

АГРАР ТРАДИЦИЯЛӘР ЧИШМӘСЕ

«Яшь Көч» агрофирмасы – Кама аръягы индустриаль үзәкләрен азык-төлек белән тәэмин итеп торучыларның берсе, һәм ул, Иннокам хезмәтчәннәре өстәленә икмәк үстереп биреп, республика иминлеге өчен үзеннән зур өлеш кертә. Бу якларда туфрак уңдырышлыгы белән мактана алмаса да, ата-бабаларның бай тәҗрибәсенә таянып, заманча технологияләр кулланып эшләгән авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре җир эшкәртү һәм терлекчелектә шактый уңышларга ирешеп килә.

БҮЛӘКЛӘР ҺӘМ МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР:

- «Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исеме
- «Фидакарь хезмәт өчен» медале
- «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» орден медале
- Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Агросәнәгать комплексы системасында күпьеллык намуслы хезмәте өчен» Мактау грамотасы

ҖИТӘКЧЕЛЕК ИТҮ – ГАИЛӘ ЭШЕ

Сабантуйны Алабуга районы Татар Дөм-Дөме авылында зурлап, шул ук вакытта гаилә бәйрәмедәй җылы итеп үткәрәләр. «Яшь Көч» агрофирмасы» ҖЧҖнең төп җирләре урнашкан әлеге авыл элек-электән үзенең эшчән, традицияләргә тугры булган, җиргә үз анасыдай сакчыл караган халкы белән дан тота. Аңа дини эзәрлекләүләрдән Нократ урманнарына качарга мәҗбүр ителгән татарлар нигез салган. Ул заманнарда бергә килеп урнашучыларга бары тик Ходай Тәгалә һәм Җир-анага таянып, үз көчләренә ышанып эш йөртергә туры килә.

Туган җирендә хезмәт итәргә теләгән кешеләрне берләштерүче бу авыл хуҗалыгы предприятиесе тирә-як авыллар халкы өчен кирәкле эш урыннары гына түгел, ул-яшәү көче һәм үсеш мөмкинлекләре чыганагы, авыл халкын берләштерүче көч, үсеш өчен тырышлык кую ноктасы. Совет хакимияте чорында «Яшь Көч» колхозы оешкан елларда да, базар шартларында «Яшь Көч» авыл хуҗалыгы предприятиесе барлыкка килгәч тә шулай булган: коллектив икътисадый һәм көнкүрештәге сынауларга бирешмәвен раслый килә.

Традицион җәмгыятьтә, бигрәк тә авыл җирендә, лидер кешеләрнең роле зур, хәлиткеч үзгәрешләр чорында аеруча. «Яшь Көч» предприятиесенә җитәкчелек итәргә Рузилә Һадиуллина килгән вакыт 1998 елгы дефолтка туры килә, икътисадның нигезенә үк куркыныч янаган бу чорда бөтен ил, предприятие, җитәкче дә зур сынау тота. Әле генә ирен югалтып, аның урынына бурычка баткан хуҗалыкка директор булырга җыенганда, хатын-кызның күңелендә нинди кичерешләр кайнаганын бер Ходай гына белә. Уйлап карасаң, мондый шартларда идарәчелек бурычын аннан башка тагын кем башкара алыр иде соң? Бу вакытка Рузилә Һадиуллинаның ике дистә ел бухгалтерлык, аннары хуҗалыкта икътисадчы булып эшләү тәҗрибәсе тупланган була.

Туган ягы – Мөслим районы, Татар Дөм-Дөме авылына килен булып төшә, ире – «Яшь Көч» авыл хуҗалыгы предприятиесенә җитәкчелек иткән елларда халык бик күп изге гамәлләр кылган, үз эшенең белгече Әмир Һадиуллин була. Фаҗигале вакыйгалар сәбәпле, Рузилә Мирсәет кызына җитәкчелек дилбегәсен үз кулларына алырга, үзен максатчан, көчле, кирәк булганда кырыс лидер итеп күрсәтергә туры килә. Югыйсә яшьрәк чагында артист булырга хыяллана, килешкилбәте дә, иҗади сәләте дә бар: баянчы ире белән бергәләп оеш-

Фото: Ксения Богданова

Реклама

тырган чыгышлары һәрвакыт район җыеннары һәм үзешчән сәнгать конкурсларын бизәп тора.

Агросәнәгать комплексы җитештерүенә җитәкчелек итү, берүк вакытта агроном, зоотехник, икътисадчы... һәм психолог булу – катлаулы бурыч, барысын да контрольдә тотарга кирәк, шул ук вакытта юкка-барга игътибар итәргә, кирәкмәгәнгә энергияне түгәргә дә ярамый. Авыр булса да, ул бу хакыйкатьнең нигезенә төшенә, беренче чиратта, яраткан кешең турында истәлек, аның эшен саклап калу теләге алда торган максатларга ирешергә булыша.

Ата-ана үрнәгендә ике уллары да лидер булып үсә, үзләрен авыл хуҗалыгын үстерүгә багышлый: хәзерге вакытта Марат Әмир улы һәм Рөстәм Әмир улы республиканың башка районнарында эшлиләр.

ҖИР ТУРЫНДА КАЙГЫРТУ – КЕШЕЛӘР ТУРЫНДА КАЙГЫРТУ

2000 нче елларда хуҗалык аякка баса, күтәрелә башлый. Күп еллар инде бу агрофирма – алдынгылар рәтендә. Куптармаклы структура аңа табышлы эшләргә, ит, икмәк һәм сөт бәяләреннән бәйсез булырга мөмкинлек бирә.

Компаниянең 2700 га сөрүлек җире, 7 терлекчелек фермасы бар. Терлек саны һаман артып тора, яңа технологияләр кертү бәрабәренә хайваннарны тоту шартлары да яхшыра. Дәүләт программасында актив катнашып, эшләрнең 30%ына субсидия алу исәбенә (моның өчен үз акчаларыңның да булуы кирәк бит әле!) хуҗалыкта абзарлар, силос чокырлары төзелә һәм искеләре капиталь ремонтлана. Хуҗалыкта 1100 МЭТ бар, шуларның 330ы савым сыеры, алар өчен бик яхшы шартлар тудырылган – 400 баш өчен исәпләнгән абзарда сөт үткәргечле һәм заманча суыткычлы «ДеЛаваль» сөт саву комплексы урнаштырылган. Әлеге фермада җитештерелгән сөтнең майлылыгы 4%ны тәшкил итә. «Яшь Көч» сөт җитештерү һәм бер сыердан савып алынган сөт күләме буенча районда әйдәп баручылар рәтендә (төрле елларда тәүлеклек савым – 20-23 литр). Ит җитештерүдә дә күрсәткечләр яхшы. Ирешелгән уңышлар белән генә тукталып калырга уйламыйлар – МЭТнең югары продуктлы голштин токымын үрчетү белән шөгыльләнә башлаганнар.

Үсемлекчелеккә энергияне саклау технологияләрен файдалану, минераль һәм органик ашламалар куллану, бүгенге көндә 20дән артык берәмлеккә җиткән машина-трактор паркын яңартып тору үз нәтиҗәләрен бирә – бөртекле һәм бөртекле-кузаклы культураларның уңыш күләме арта бара.

Хуҗалык игенчеләренең үз принциплары бар. Мәсәлән, алар, заман шаукымына ияреп, сөрүлек җирләрен тирәнтен эшкәртүдән баш тартмаган, элеккечә сукалауга чыгымнар күбрәк китсә дә, чүп үләннәре бетерелә, бөтен катламнар ачылып, аларга дым үтеп кергәнгә күрә, туфракның структурасы яхшыра, дип фикер йөртә алар. Һәр гектардан суктырылган бөртекләр уңышы 30 центнердан артык, димәк, «бабайлар» тәҗрибәсе үзенең нәтиҗәлелеген тагын бер кат раслый.

Кайбер ФТИлар белән хезмәттәшлек итү нәтиҗәсендә хуҗалык селекционерлардан югары нәтиҗәле сортлар ала: ел саен бодайның «Симбирцит», «Эстер», «Икада», арпаның «Тимерхан», солының «Рысак» һәм башка элиталы сортларны чәчеп-үстереп, йөзләрчә тонна ашлыкны табыш китерерлек итеп сата.

Хуҗалыкта көчле идарә звеносы формалашкан. Баш инженер Наил Ибниев һәм баш бухгалтер Асия Нәбиуллина, ферма мөдире Илдар Хәбибуллин, ветеринария табибы Федор Бухаров, баш агроном Рафат Нотфуллин үз эшләренең осталары, алар теләсә нинди вазгыятьтә дөрес юл табарга сәләтле белгечләр.

Җитәкченең хезмәт коллективында да таянырлык кешеләре җитәрлек, тәҗрибәле остазлар – бригадир Азат Хуҗин, сыер савучы Гөлнур Сибгатуллина, бозау караучы Наталья Такранова, механизаторлар Алмаз Закиров һәм Виталий Захаров башкаларга тырыш хезмәт үрнәге күрсәтәләр.

Хуҗалыкта лаеклы хезмәт шартлары тудыру өчен күп эш башкарыла: эшчеләр өчен кайнар ризык әзерләнә, хезмәт хакы арта, мохтаҗларга матди ярдәм күрсәтелә, шифаханәләргә юлламалар бирелә. Предприятие яшь белгечләрне уңайлы торак һәм лаеклы хезмәт хакы белән тәэмин итәргә әзер.

«АВЫЛ ЭШСЕЗ ҮЛӘ»

Хуҗалык җитәкчесе бу фикерен еш кабатлый: эшсезлекне авыл хуҗалыгының төп проблемасы ди ул, әмма шул ук вакытта социаль факторларны да күздән ычкындырмый. Авылларда мәшгульлек проблемасын чынлап та хәл итә алырлык фермерлыкка каршы түгел Рузилә Һадиуллина. Шуңа да карамастан, күпчелек фермерларны керем генә кызыксындыра, үз хуҗалыкларыннан читтәге вазгыять борчымый, дип басым ясый ул.

Аның фикеренчә, авылны торгызу, андагы тормышны уңайлы итү – коллектив хуҗалыклар кулыннан гына килә торган эш. Бары тик кешеләрнең күршедә яшәп, бердәм булып эшләве, уртак проблемаларны бергә хәл итүе һәм үзара ярдәмләшеп көн күрүе югары нәтиҗәләр бирә, дип саный ул.

Агрофирма, гадәттәгечә, авыл халкы өчен эш урыны гына түгел, ул күпчелек социаль бурычларны да үти, нәкъ менә хуҗалык – авыл халкы ярдәм сорап мөрәҗәгать итә торган беренче инстанция. Директорның, шул исәптән җирле Совет депутаты буларак та, бу юнәлештә эше җитәрлек: авылга газ кертелгән, юлларга асфальт җәелгән. Авыл ел саен үткәрелә торган «Иң яхшы авыл йорты» район бәйгесендә һәрвакыт призерлар рәтендә, чөнки үз йорт-җирләрен төзекләндерергә һәм яңартырга теләүчеләргә хуҗалык төзелеш материаллары белән булышлык күрсәтә. Ул ветераннарга, пенсионерларга һәм инвалидларга авыл хуҗалыгы продукциясе белән ярдәм итә, терлек асраучы шәхси хуҗалыкларга арзанлы бәядән печән, салам, фураж белән булыша, теләүчеләргә фермадан бозау да алырга мөмкин.

Хуҗалыкның иң мөһим бурычларының берсе – агрофирмада да, шәхси хуҗалыкларда да терлекләрнең баш санын саклап калу, дип саный директор. Авылда терлек булса, эшче кулларга да ихтыяҗ да бар дигән сүз. Димәк, халык үзен туган җирендә туендыра алачак. Шуңа күрә иртән автобуслар читкә йөреп акча эшләүне хуп күргән берәүләрне алып китсә, икенчеләрне «Яшь Көч»кә китерә – биредә күрше авыллардан килеп эшләүчеләр шактый, бигрәк тә урак өстендә хуҗалыкта эшчеләр саны ике һәм аннан да күбрәккә арта.

– Җирдә эшләү – кешене туган җире белән бәйли, Ватаныбызның лаеклы гражданины итә, патриотизм, милли үзаң тәрбияли, гаилә мөнәсәбәтләрен ныгыта, гореф-гадәтләрне саклый, – ди директор.

Бишенче дистә ел авылда эшләүче ТРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре Рузилә Һадиуллинаның бу фикерләре белән килешмичә булмый.

ХУҖАЛЫК КӨЧЕ РОБОТЛАРДА ТҮГЕЛ

«Мөхәммәтшин З.З.» крестьян-фермер хуҗалыгы, Татарстанда беренчеләрдән булып, сөтчелек фермасында эшләүчеләрне роботларга алыштыра. Хәзер бирегә авыл хуҗалыгы идарәчеләрен һәм студент-ветеринарларны экскурсиягә алып киләләр. Моннан 6 ел элек беренче урнаштырылган робот янына сыерларны мәҗбүриләп китергән булсалар, хәзер савымга хайваннар үзләре килә.

Татарстан Республикасы Саба районының Икшермә авылындагы сөтчелек комплексы моннан алты ел элек Голландиянең тәүлек буе эшли торган автоматлаштырылган Lely[1] сыер саву системасы белән җиһазландырылган иде, шул рәвешле кул хезмәте тулысынча бетерелде. Абзарларны һәм азык бирү савытларын чистарту, терлекләрне ашату һәм саву, хәтта санитар күзәтү эшен дә роботлар башкара. Эксперименталь ферманың 240 сыеры исә көн саен югары сортлы 6,2–7,4 тонна сөт бирә, бер сыердан тәүлек эчендә савылган продукция күләме уртача 25–32,2 кг тәшкил итә, аерым «рекордсмен» сыерлар көненә биш савымга 45 кг сөт бирә.

Сыер савым өчен бокска үзе теләгән вакытта килә, кирәк булса, төнлә дә. Хайван турындагы бөтен мәгълүмат – муенчактагы чипка кертелгән. Савар алдыннан компьютер аны терки: экранга токым, савым күрсәткечләре, аның авырулары турында хәбәр чыгарыла. Мастит булса, шунда ук ачыклана – робот сөтне аерым контейнерга җибәрә. Барлык эшне автоматлаштырылган «кул» эшли: җиленнәр юыла, массаж ясала, махсус эретмә сиптерелә. Лазер белән капшаганнан соң, робот сыер җиленәнә саву стаканнарын кигертә, эш беткәннән соң, сыер бокстан чыга.

Үз эшчәнлеген 1997 елда төрле токымлы 40 сыердан башлап җибәргән КФХ өчен үсеш юлы җиңел булмаган. Әмма 2010 елда район хакимияте башлыгы Рәис Миңнеханов 80 миллион сумга (проектның беренчел бәясе) бурычка кереп үзендә роботлаштырылган фермалар төзергә әзер булган өч хуҗалык кирәклеге турында игълан иткәч, Зөфәр Мөхәммәтшин тәвәккәлләргә була.

Голландия проектын илебез экспертизасы тикшерергә алынмый, аңа Казанда заказ бирергә туры килә. Шулай итеп, төзелеш бәясе 40тан 90 миллионга кадәр арта, калган ике хуҗалык кеше хезмәтеннән башка абзарларны чисталыкта тотарга мөмкинлек бирүче ярыклы идәннәрдән баш тарта. Яхшы әле Lely җиһазларын китерү, урнаштыру һәм җайга салу эшләре башта килешенгән исәп–хисап дәрәҗәсендә кала – 43 миллион сумга төшә. Роботларга хезмәт күрсәтүне Lely компаниясенең Татарстан буенча авторизация узган дилеры – «Агроробот» башкара. Даниядән голштин-фриз токымлы 120 тана сатып алуга тагын 12 млн сум акча тотарга туры килә. Мөхәммәтшин кредит буенча барлык бурычларын биш ел эчендә түләп бетерәчәгенә шикләнми.

Үзендә булган бөтен акчаларын, кредитларын кулланып, 2013 елда робот фермасын эшләтеп җибәргәндә, крестьян-фермер хуҗалыгы барлыгы 145 миллион сум акча тоткан була, дәүләт, мәсәләнә, 2014 елда барлык дәрәҗәдәге бюджет чараларыннан шуларның 23,8 миллион сумын компенсацияли.

Хезмәткәрләргә яхшы саналган 17,3 мең сум хезмәт хакы түләгән хуҗалыкның кереме шул ук елда, сөтнең үзкыйммәте 13 сум итеп саналганда, 32 млн сум тәшкил итә. 42,5 млн сумлык кредит түләнә, 15 млн сумлык техника алына, 9 млн сумга 400 башка исәпләнгән бозау абзары төзелә.

Әлбәттә, гаҗәеп ферма гына үзен бер ел эчендә аклап өлгерми. Зөфәр Зиннәт улы хуҗалыгының башка табышында шикләнми. 15 еллык терлекче тәҗрибәсе булган җитәкче эшен бик оста җайга салган: 65 хезмәткәре, роботлаштырылмаган икенче, «ДеЛаваль» саву залы булган фермасы, 2,5 мең гектарда терлек азыгы җире, 1400 баш мөгезле эре терлек, шул исәптән чит илдән кертелгән таналардан шундый ук «импорт» белән орлыкландырып туган яшь терлекләр – барысы да табыш китерә. Бер үк вакытта үгезләр симертү өчен ферма да төзиләр, елына 220–250 баш терлек сатыла.

Ә роботлы ферма бүген дә, 6 ел элек кебек үк, роботтан курыкмаучы махсус сайлап алынган 240 сыерга хезмәт күрсәтә. 4 берәмлек Lely Astronaut A4[2] роботы күбрәк саварга өлгерми икән.

Әмма бу ферма – киләчәк үрнәге, аңа 6 оператор хезмәт күрсәтә (смена саен икәү), алар җиһазларның төзеклеген күзәтеп тора, кирәк булган очракта, системаны энергия белән тәэмин итүнең резерв чыганагына күчерә. Башка кеше юк. Идәннән тирес җыючы 2 данә Lely Discovery[3] роботы йөри, азык күчерүче Lely Juno[4] роботы эшли, автономияле режимда Lely Cosmic[5] азык станциясе гамәлдә.

Гомумән алганда, «Мөхәммәтшин З.З.» крестьян-фермер хуҗалыгында сөт һәм сыер ите житештерүнең, нәсел эшен алып баруның һәм нәселле бозаулар үстерүнең, терлек азыгы әзерләүнең барлык заманча технологияләре чагылыш тапкан һәм мул сөт бирә торган сыерларны үзенчәлекле тукландыру тәҗрибәсе тупланган.

Фото «Мөхәммәтшин З.З.» крестьян-фермер хуҗалыгыннан алынды
Реклама

[1] Лели; [2] Лели Астронаут А4; [3] Лели Дискавери; [4] Лели Джуно; [5] Лели Космик

«Татарстан» журналын кайдан сатып алырга?

1. **«Татарстан почтасы» Федераль почта элемтәсе идарәсе – «Почта России» ФДУП филиалы элемтә бүлекләрендә.**
2. **«Басма продукцияне тарату агентлыгы» ҖЧҖ киоскларында.**
3. **«Дейли» кибетләрендә.**
4. **«Бәхетле» кибетләрендә.**
5. **«Пресс-медиа» ҖҖЧ:**
   - Онкоүзәк
   - «Васильевский» шифаханәсе
   - ЭЭМ госпитале
   - Төбәкара клиника-диагностика үзәге
   - БРКХ
   - РКХ
   - Ветераннар госпитале
   - 2, 7, 12, 18 номерлы шәһәр хастаханәләре

«Татарстан» журналын сатып алу сорауларына караган өстәмә мәгълүмат (язылу, аерым номерлар, архив номерлары) буенча дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе Байрашева Миләүшәгә мөрәҗәгать итәргә мөмкин:
тел. (843) 222-09-79, (1448 внутренний)
e-mail: milyaushanb@tatmedia.com

Реклама 16+

ПЛАСТИК ҺӘМ КАУЧУК ҖИТЕШТЕРҮ ӨЛКӘСЕНДӘ ФЛАГМАН

Агымдагы елның сентябре башында 180 Россия һәм чит ил җитештерүчесе үзенең иң соңгы казанышларын нефть-газ форумы кысаларында берләштерелгән өч күргәзмәдә тәкъдим итте. «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ экспозициясе, алдагы еллардагы кебек үк, Казанда оештырылган халыкара чарада катнашучыларның һәм кунакларның игътибар үзәгендә булды. Быел да предприятие үзенең иң алдынгы эшкәртмәләрен күрсәтә алды.

ДИПЛОМ
I СТЕПЕНИ
Конкурса
«Лучший экспонат, лучший проект или лучшее техническое решение»
В РАМКАХ
ТАТАРСТАНСКОГО НЕФТЕГАЗОХИМИЧЕСКОГО ФОРУМА-2019
В номинации
«Продукция с новыми или улучшенными характеристиками»
награждается
Публичное акционерное общество «Нижнекамскнефтехим»
Республика Татарстан, г. Нижнекамск
за организацию производства метоксиполиэтиленгликолей (МПЭГ)
Премьер-министр Республики Татарстан А.В. Песошин
2-4 сентября, Казань-2019

ҮСЕШ ЮНӘЛЕШЕН БИЛГЕЛӘП

26 нчы халыкара форум традицион рәвештә өч тармак күргәзмәсен берләштерде: «Нефть, газ. Нефть химиясе», «GEO-КАЗАН: Геологоразведка. Геодезия. Картография» һәм «Интерпластика Казан-2019». Россия компанияләре, 23 якын һәм ерак чит ил вәкилләре әлеге тармакларга караган иң алдынгы эшкәртмәләр белән таныштылар һәм тыгыз эшлекле программа кысаларында хезмәттәшлек итү мөмкинлекләрен тикшерделәр.

– Татарстан янә Россия химиясе һәм нефть-газ сәнәгате өчен төп тармак вакыйгасының үткәрелү урынына әверелде. Форумда тармакны цифралаштыру, нефть табуда һәм нефть сервисында инновацияләр, табигатьтән дөрес файдалану кебек темалар буенча фикер алышулар үтте. Нәкъ менә шушы темалар якын киләчәктә илебезнең нефть-газ сәнәгате үсеше динамикасын билгеләячәк, – дип билгеләп узды форумны ачу тантанасында Татарстан Президенты.

Шуннан соң Рөстәм Миңнеханов күргәзмәдә катнашучылар белән аралашты. Татарстан Президентын Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча Федераль хезмәт җитәкчесе урынбасары Александр Трембицкий, Россия Федерациясе сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары Олег Бочаров, Россия Федерациясе Нефть-газ сәнәгатьчеләре берлеге президенты Геннадий Шмаль һәм «ТАИФ» АҖ генераль директоры Руслан Шиһабетдинов озата йөрде. «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ стенды делегациянең игътибарын беренчеләрдән булып җәлеп итте.

ЯҢА ЮНӘЛЕШЛӘРНЕ ҮЗЛӘШТЕРЕП

Европаның иң эре нефть химиясе компанияләренең берсе булган «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ базарга нинди яңа продуктларын чыгарырга ниятли? Бу турыда Татарстан Президентына компаниянең генераль директоры Азат Бикмурзин сөйләде.

– Без каучукның яңа төрләрен эшләү белән шөгыльләнүебезне дәвам итәбез. Шуларның берсе – бутадиен-стироль каучук (ДССК). Ул менә дигән кулланучылык сыйфатларына ия һәм премиаль сегментка караган шиннар җитештерүдә таләп ителә. Бу дөньяда барлыгы берничә генә компания җитештерә торган бишенче буын каучуклар. Әлеге продуктка сорау бик зур һәм, ким дигәндә, тагын ун ел әлеге ихтыяҗ кимемәячәк. Җитештерүне инде 2020 елда эшләтеп җибәрәчәкбез, – дип сөйләде компания башлыгы.

Сүз яшел дип аталган шиннар турында бара. Аларны куллану экологик яктан файдалы. Мондый шиннар ягулыкны янга калдырырга мөмкинлек бирә, ә бу исә әйләнә-

Фотолар «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ матбугат хезмәтеннән алынды

Реклама

тирә мохиткә зарарлы газлар чыгаруны киметә. Әлеге шиннарның шулай ук чыдамлылык дәрәҗәсе дә югары, алар тиз тузмый, юл өслеге белән ябышу сыйфаты да әйбәтрәк. ДССК җайланмасын эшләтеп җибәрү нәтиҗәсендә «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ шин сәнәгате өчен эретмә синтетик каучукның барлык төрләрен чыгаручы аз сандагы дөньякүләм җитештерүчеләрнең берсенә әвереләчәк.

– Моннан тыш, әлеге каучукны җитештерә торган җайланма уникаль һәм күпфункцияле. Ул безгә шулай ук термоэластопласт, ягъни юл өслекләре өчен сыйфатлы өстәлмәләр җитештерергә мөмкинлек бирәчәк. Ихтыяҗ зур булган әлеге яңа продуктны якынча 10 мең тоннага кадәр җитештерүне планлаштырабыз, – дип дәвам итте яңалыклар белән таныштыруны Азат Бикмурзин.

Әлеге продуктка сорау чыннан да зур булачак, чөнки термоэластопластлар температура үйнауларга һәм дымлылыкка бирешми. Алар бөтен Россия буенча юллар төзелешендә актив кулланыла.

Татарстанда узган нефть-газ химиясе форумы кысаларында «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖның тагын бер эше аерым бүләккә лаек булды. Бүләк «Иң яхшы экспонат. Иң яхшы проект яисә техник чишелеш» конкурсында тапшырылды. «Яңа яисә яхшыртылган сыйфатлы продукция» номинациясендә I дәрәҗә диплом метоксиполиэтиленгликольләр (МПЭГ) җитештерүен оештырган өчен бирелде. Бу продукт бетон катнашмаларының «суперпластификаторларын» җитештерүдә кулланыла. МПЭГ цемент катнашмасының үзлелеген киметергә һәм бетонның техник сыйфатларын яхшыртырга мөмкинлек бирә.

ТОП-10 – ЧИК ТҮГЕЛ

«Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ генераль директоры шулай ук Рөстәм Миңнехановка республиканың әйдәп баручы нефть химиясе компаниясен үстерү планнары турында да сөйләде.

– Без бүген синтетик каучук җитештерү буенча дөньяның топ-10 компаниясе исемлегендә. Хәзерге вакытта җитештерү куәтләре елына 730 мең тоннаны тәшкил итә. Якындагы планнарда – күләмнәрне елына миллион тоннага кадәр җиткерү.

Этиленга килгәндә исә, җитештерү куәтләрен елына бер миллион ике йөз мең тоннага кадәр арттыру планлаштырыла. Төп проектлаштыру эшләре төгәлләнгән, 2020 елда җиһазлар китерү һәм төзелешне башлау көтелә. Җитештерү 2023 елдан да соңга калмый эшләп китәргә тиеш.

Киләсе этап – этилен комплексы җитештергәннәрне куллану проектларын тормышка ашыру. Ассортиментта пластик, полиэтилен, полипропилен һәм полистирол каралган. Шулай ук пропилен окисен һәм башка продукцияләр җитештерү буенча югары технологияле проектлар эшләү ниятләнә.

ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫН КАЙГЫРТЫП

Табигатьне һәм табигый ресурсларны саклау өлкәсенә караган эшләр Татарстан Президентының аерым контролендә тора. Җитештерүгә экологик технологияләрне кертү сораулары буенча «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ шулай ук республика буенча да, Россия күләмендә дә алдынгы урыннарның берсен били.

– Без бөтен шәһәргә хезмәт күрсәтүче (йөкләнешнең 19%ка якынын алып тора) биологик чистарту корылмаларын (БОС) реконструкцияләү буенча киң колачлы эшне төгәлләдек. Калган егәрлекләр безнең компания һәм Түбән Кама сәнәгать мәйданчыгында урнашкан башка предприятиеләр ихтыяҗлары өчен тәгаенләнгән. Әлеге чистарту корылмасына иң яңа технология – биофильтрация урнаштырылды. Зарарлы газларны чистартуның нәтиҗәлелеге 95%ка җитә. Бүгенге көндә сәнәгать агынтылары өчен яңа коллектор төзелешен тәмамлап киләбез. Аның гомуми озынлыгы 15 км ны тәшкил итә. Коллектор микротоннельләштерү технологиясе буенча төзелә, әлеге метод торбалар салуның буеннан-буена чокыр казуны таләп итми. Шул рәвешле без экологиягә йогынтыны минимумга калдырырга тырышабыз.

Әлеге проект республикабызның табигый ресурсларын саклау буенча компания тарафыннан башкарылган чираттагы адым санала. Тагын да элегрәк «Түбән Кама Нефтехим» үзендәге идарә системасының энергияне нәтиҗәле һәм дәүләт стандартлары таләпләренә ярашлы рәвештә тотуы хакында Татарстанда беренчеләрдән булып сертификат алды. Ә 2003 елда предприятиенең әйләнә-тирә мохитне саклау буенча эшчәнлеге республикада беренче булып халыкара стандартларга ярашлы була башлады.

РЕСПУБЛИКА ҺӘМ КОМАНДА ЯРДӘМЕ НӘТИҖӘСЕНДӘ

Бүгенге көндә «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ 4 төрле пластик һәм 7 төрле каучук җитештерә. Ул полиизопрен чыгару буенча дөньяда иң эре җитештерүче санала. Бутил каучук белән тәэмин итү буенча дөньяда өченче урында тора. Татарстан компаниясе продукциясенә Европаның, Американың, Көньяк-Көнчыгыш Азиянең, Якын Көнчыгыш һәм Африканың 50 дән артык илендә ихтыяҗ зур.

Ярты гасырдан артык тарихы дәвамында компания гаять зур һөнәри капитал туплады. Бүген үз белгечләренең инициативасы, республиканың прогрессив җитәкчелеге ярдәмендә ул җитештерүдә яңа офыкларны иңләргә омтыла.

МОТОР, ДРАЙВЕР, ГЕНЕРАТОР…

Василий Маньковский – КАМАЗның беренче төзүчеләреннән. Башка меңләгән яшьләр кебек үк, 1973 елда ул комсомол юлламасы буенча Чаллыга – галәмәт зур төзелеш мәйданчыгына килә. Шул рәвешле Чулман буендагы кала аның өчен туган шәһәргә әверелә, монда балалары, оныклары һәм оныгының кызы туа.

Василий хезмәт юлын шофер булып башлый, ә 1980 елгы Мәскәү олимпиадасында автобуста башкала кунакларына хезмәт күрсәткәч, КАМАЗның тышкы сәүдә ширкәтенә күчә. Бер үк вакытта Кама политехник институтының автомобиль төзелеше факультетында кичке бүлектә белем ала. Василий Владимирович өчен нәкъ менә автомобиль төзелеше бар язмышын билгеләгән тармак булып чыга. Шул өлкә аны автомобиль каласының тәүге эшмәкәрләре сафына да алып килә – 1990 елда Василий Маньковский махсус автомобильләр өчен егәрлек тапшыру тартмаларын эшләү һәм җитештерү буенча «КОМ» машина төзелеше предприятиесен терки. Бу катлаулы, әмма әллә ни табыш китерми торган эш белән шөгыльләнергә теләүчеләр бик аз була…

Бүген Элеватор тавында урнашкан, дөнья брендларының югары җитештерүчәнлеккә ия станоклары белән җиһазланган иркен һәм якты цехларның кайчандыр автобус паркының ташландык җитештерү корпуслары икәнлеген белүчеләр бармак белән генә санарлык. 2000 елда исә монда егәрлек тапшыру тартмалары җитештерелә башлый.

Бүген әлеге кече предприятие 400 кешелек компанияләр төркеме дәрәҗәсенә кадәр үсте. «КОМ» ҖЧҖнең эшен Механик трансмиссияләр заводы («ЗМТ» ҖЧҖ) дәвам итә, ул егәрлек тапшыру, көч тарату, тизлек тапшыру тартмаларын, йөреш киметүчеләр, махсус редукторлар, трансмиссия элементларын эшләү һәм җитештерү белән шөгыльләнә. Бу – тулы цикллы предприятие: идеядән алып әзер эшләнмәгә кадәр барысы да биредә тормышка ашырыла. Заводның җитештерү портфелендә трансмиссия агрегатларының 300дән артык төрле моделе һәм модификациясе бар. Партнерлар арасында – КАМАЗ, БАЗ, ГАЗ, УРАЛАЗ кебек компанияләр. Василий Владимирович җитәкчелегендә коелмалар һәм кою җайланмалары җитештерү җайга салынган («КОМ-Металлургия» ҖЧҖ), инновацион транспорт чаралары – вездеходлар, кар һәм саз машиналары, йөк автомобильләре, автобуслар («РУСАК» ҖЧҖ) эшләнә һәм җитештерелә.

2008 елдан Василий Маньковский «КОМ» идарә компаниясе» ҖЧҖ директорлар советының рәисе булып тора һәм ширкәтнең стратегик, техник үсеше мәсьәләләрен хәл итә. Моның нәтиҗәсе күз алдында: компания Россиядә махсус техника өчен катлаулы һәм аз серияле продукция җитештерү тармагында лидер булып тора.

Василий Владимирович – илебезнең машина төзелеше тармагын Россия эшләнмәләре нигезендә үстерүнең берсүзсез тарафдары. «КОМ» компанияләр төркеме Р.Е. Алексеев исемендәге Түбән Новгород техник университеты белән уртак фәнни эшчәнлек алып бара, тәҗрибә-экспериментлар ясый. Әлеге тикшеренүләр катлаулы табигать һәм климат шартларына ия районнар өчен «РУСАК» маркасында тәгәрмәч яки чылбырлы кече вездеход техникасының яңа үрнәкләрен булдыруны күздә тота. Василий Владимирович җитәкчелегендә җитештерелгән урта тоннажлы «РУСАК-5354» йөк автомобиле 2009 елда «Россиядә елның иң яхшы коммерция автомобиле» конкурсында «Ел перспективасы-2009» номинациясендә I урын алды. 2012 елда энергияне нәтиҗәле куллана торган һәм югары экологик таләпләргә җавап биргән чылбырлы «РУСАК» вездеход-амфибиясе үрнәге эшләнде. Хәзерге вакытта вак серияле җитештерү өчен әзерлек эшләре һәм сынаулар алып барыла. Үтә түбән басымлы шинлы вездеход-амфибияләрнең ерак Себер шартларында уңышлы сынаулары узды да инде.

«КОМ» компанияләр төркеме Татарстанның Машина төзелеше кластеры әгъзасы булып тора, республикада машина төзелеше үсешенә ярдәм итеп, әлеге тармакның барлык чараларында да актив катнаша. Компания продукциясе күп тапкыр төрле форумнарда, бизнес-миссияләрдә Татарстан Республикасы территориясендә җитештерелә торган кирәкле продукт буларак күрсәтелде.

«КОМ» компанияләр төркеме машина төзүчеләренең тату коллективы ширкәткә нигез салучы, аны идеяләр белән рухландырып торучы, чын профессионал – **Василий Владимирович Маньковскийны** «Татарстан Республикасының атказанган машина төзүчесе» дигән мактаулы исем бирелү белән котлый:

– Хөрмәтле Василий Владимирович! Сез бер үк вакытта мотор да, драйвер да, идеяләр генераторы да. Әнә шуңа күрә безнең компаниядә ачыклык, җаваплылык һәм профессиональлек рухы хөкем сөрә. Сезнең белән бер командада – фикердәшләр коллективында эшләвебез белән горурланабыз! Сез төзү-җитештерү хезмәтенең авыр юлын узган бик аз санлы шәхесләрнең берсе, көчсезлек күрсәтеп туктап калмагансыз, катлаулы эштә зур уңышларга ирешкәнсез, без Сезнең хезмәт җимешләрен ачык күрәбез – завод төзелгән һәм гөрләп эшли! Сез, чыннан да, тармакны үстерүгә зур өлеш кертүче, Россиянең барлык машина төзелеше өчен чын күңелдән янып йөрүчен көндәлек хезмәте белән раслаучы атказанган машина төзүче.

Без Сезнең ярдәмчеллегегез өчен ихлас рәхмәтле, заводта булдырылган уңайлы хезмәт шартларын, кайгыртучанлыгыгызны бик югары бәялибез. Василий Владимирович, үз энергиягезне, сәламәтлегегезне һәм оптимизм хисен озын-озак еллар дәвамында саклап калуыгызны телибез!

Реклама

Фото «КОМ» компанияләр төркеме тарафыннан бирелде

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Татарстан профессионаллары **НИЧЕК** дөнья профессионалларына әверелде

Онлайннан офлайнга **НИЧЕК** күчәргә

Данис Зарипов **НИНДИ** уй-ниятләр белән яши

Укытучыларны без **НИ ӨЧЕН** яратабыз

Мәдәният министры безне **НӘРСӘ** белән сыйлады

КИЛӘЧӘКТӘН **КУНАКЛАР**

Август азагында Татарстан башкаласында 45 нче WorldSkills Kazan 2019 дөнья чемпионаты узды. Әлеге «зөбәрҗәт шәһәрдә» һәркем үзе күптән эзләгән нәрсәне чынбарлыкта таба алды. Кемдер – һөнәри белем бирү һәм практиканы тоташтыруның идеаль моделен, кемдер – үзенең компаниясе яки тармагы өчен яңа перспективалар, кемдер исә – кайчандыр хыялланырга гына мөмкин булган һөнәр алу мөмкинлеген.

Автор:
Ксения Сёмина

Ярышлар, эшлекле программа, партнерлар стендларындагы беренче чиратта балалар һәм үсмерләргә тәгаенләнгән бихисап активлыклар, Try-a-skill («Үзеңне бу һөнәрдә сынап кара») проекты, грандиоз ачылу һәм ябылу тантаналары... Бу колачлы вакыйгаларның идеясе стендлардан берсендә язылган бер гади формулага сыя – «Where there is a skill, there is a way – Күнекмә генә булсын, мөмкинлек исә табылачак».

«АНСАТТА» – ЙОЛДЫЗЛАРГА

– Космонавт – универсаль һөнәр, күп нәрсәне белергә кирәк. Борттагы ватылган җиһаз-җайланмаларны төзәтергә, медицина ярдәме күрсәтергә, ашарга әзерләргә... Ашарга пешерә белү бик мөһим, космоста кибетләр юк бит, – дип сөйли эшлекле программа аудиториясенә «Соңгы чик: йолдызлар дәресе» дискуссиясе спикеры, Россиянең легендар космонавты, «Роскосмос» ДКнең очу программалары буенча башкаручы директоры Сергей Крикалев. Аның сүзен астронавт Скотт Келли дә җөпли:

– Миңа бервакыт Халыкара космос станциясендә коллегамның тешен дәваларга туры килде хәтта...

Чыгыш ясаганнан соң йолдызларга ярыш мәйданчыклары буйлап экскурсия үткәрәләр. «Авиация техникасына хезмәт күрсәтү» компетенциясе турында кунакларга бик тәфсилләп сөйлиләр.

– Компетенция модульләренең берсендә бәйгедә катнашучы файдалану буенча кулланмадан двигатель белән идарә итү системасының механикасын тикшерү регламентын табарга һәм аны тикшерергә, шулай ук һава судносының билгеле бер зоналарын карап чыгарга тиеш. «Ансат» мондый биремнәрне үтәү өчен җыйнак һәм уңайлы, – дип аңлата компетенциянең россияле эксперты **Норайр Хачатурян.**

Компетенция эчтәлеге гади авиация техникгы функционалы кысаларыннан күпкә катлаулырак. Мәсәлән, аңа детальләрне ясау һәм ремонтлау кертелгән, чынбарлыкта исә моны башка хезмәтләр һәм башка белгечләр эшли. Көндәлек эштә әлеге күнекмәләрнең кирәге чыгуы икеле, әмма аларның бик мөһим һәм чыннан да кирәкле өлеше – дефектларны таба һәм сурәтләп

Фотолар WorldSkills International тарафыннан бирелде

бирә белү осталыгы, дип аңлата белгеч.

Чемпионат биремнәре – чит илдә техниклар укый торган программадан күчермәләр ул. «Җитештерү-эксплуатация» бүленеше анда уку тәмамланганнан соң була. Россиядә исә махсуслашу югары яки урта махсус уку йортында укыганда ук башлана. Әмма күп кенә һөнәри белем бирү учреждениеләрендә хәзер әлеге юлдан баш тартырга җыеналар. Чемпионатка әзерлек һәм анда катнашу илдәге югары уку йортларын тәмамлаучыларның төшенә дә кермәгән дәрәҗәдәге белем һәм күнекмәләр бирә. Бу – чын тәҗрибә, белгечнең сыйфаты, көндәшлекле өстенлек. Һәм аларга ия булу чыннан да мөмкин: әйтелгән (һәм башка) компетенция буенча милли җыелмага сайлап алу даими рәвештә бара. Хәзер «Авиация техникасына хезмәт күрсәтү» компетенциясе буенча милли җыелмага өч татарстанлы керә. Компетенция үзе прогресстан артта калмый: якын киләчәктә аның «Авиация техникасына хезмәт күрсәтү» компетенциясеннән «Авиакосмик технологияләргә» әйләнүе бик ихтимал. Сергей Крикалев гаммәви матбугат чараларына сөйләгәнчә, хәзер Россия космонавтлары командасына белгечләрне җыю бара. Йолдызлар көтә!

P.S. Норайр Хачатурянның шәкерте Николай Пилюшенко, 743 балл җыеп, чемпионатның көмеш медален яулады. Ул Хэйдн Джейкска (Бөекбритания, 746 балл, алтын) гына бирешеп, пьедесталны кытай Чжуншэн Е белән бүлеште. Ябылу мәрасименнән соңгы көнне үк Хэйдн Джейкснның фотосы Британиянең The Sun таблоидында пәйда булачак. Шул ук мәкаләдә Казандагы чемпионатның грандиоз ябылу тантанасы һәм Владимир Путинның шундагы чыгышы турында да сөйләнәчәк. Игътибар: көн саен чыга торган The Sun газетасының тиражы – 2,8 миллион данә.

ИНГЛИЗЧӘ БЕЛМИСЕҢМЕ? ЕЛМАЙ!

«Бөтен дөньядан килгән 900дән артыграк гаммәви мәгълүмат чарасы» – чемпионатның журналистлар пулын WorldSkills International оешмасының маркетинг һәм элемтәләр буенча директоры Криспин Торольд шулай сурәтләгән иде. Әмма бу турыда ишетү бер хәл, ә менә күрү – бөтенләй икенче: медиа-командалар бертуктаусыз төшерә, интервью ала, стендаплар яза, ашап алуга, язмаларны эшкәртүгә һәм җибәрүгә генә бераз бүленеп, минут саен диярлек онлайн-трансляция алып бара.

Механди татуировкасы остасына (Һиндстан стендындагы А павильонында аны көн саен бушлай ясадылар) тезелгән чиратны ерып, һинд телевидениесе янына киләм.

– Барысы да бик яхшы оештырылган! Безнең хакта күп кеше кайгырта, бөтен кирәк-ярак белән тәэмин иттеләр, навигация бик уңайлы, без шаттлларда киләһәм китә алабыз, ресторан эшли, даими чаралар үткәрелә! Ачылыш тантанасы искиткеч булды, тавыш та, сурәт тә – барысы да бик шәп! –

дип соклана оператор Манодж Прадхан. Ул, аның коллегасы Джаганнат Прадхан һәм алып баручы Кшипра Баллани чемпионатка Мумбайдан Һинд хөкүмәте заказы буенча Hunnarbaaz программасы өчен видео төшерергә килгәннәр.

– Безнең программа һөнәрнең ничек илһамландыруы, осталыкның кеше тормышын яхшы якка ничек үзгәртүе хакында. 2020 елда илебездә яшьләр саны тарихта моңарчы булмаган санга җитәчәк. Яшьләргә шуны күрсәтү мөһим – алар, үзләре эшләп кенә калмыйча, башкаларны эшкә урнаштыру мөмкинлекләрен дә тудыра ала бит! – дип аңлата Кшипра. Ул да, Манодж кебек үк, бөтен нәрсәнең шулай яхшы оештырылуына таң калган. Команда инде кичен шәһәр үзәгендә дә булырга өлгергән.

– Чиста, яшел! Матур шәһәр! Кешеләр бик дустанә, таныш булмасак та, елмаялар. Һиндстанда мондый ачыклык юк, – дип сөйли кыз. – Дөрес, монда инглизчә белүчеләр аз. Бу, әлбәттә, аралашуны кыенлаштыра. Әмма сезнең елмаю хакына моны гына кичереп була!

РОССИЯГӘ – МӘХӘББӘТ БЕЛӘН

«Казан Экспо» территориясе бүленгән кластерлар системасында адашмаска кунакларга волонтерлар булыша. Бу чемпионатта волонтер сыйфатында 3,5 мең кеше мәшгуль, шулардан 100 есе – чит илнеке. Әлеге ирекле ярдәмчеләрнең бурычларына (алар чыннан да ашау, юл бәясе, торак һәм әйбәт резюме өчен генә эшли) үзәк һәм шәһәр буенча навигациядә булышу, бәйгедә катнашучыларга ассистентлык итү, командаларны озатып йөрү, мәйданчыклар буенча экскурсияләр үткәрү һәм башкалар керә. Волонтерлар штабында кайнаган тормыш бер үк вакытта пионер лагерен дә, хәрби частьны да хәтерләтә. Мин алар янына кергән чакта ярдәмчеләр WorldSkills Kazan2019 илчесе, комик, «Вечерний Ургант» тапшыруының текстлар авторы Александр Гудков белән аралаша иде. Спикер шаяру барып чыкмаган очракта нишләгәнен аңлата.

– «Вечерний Ургант» тапшыруын ачканда, Америкадан шоураннер килгән иде, ул безгә: «Иң мөһиме – эш барып чыкмаудан курыкмау», – диде. Бик әйбәт эфир булырга мөмкин, аннары бераз начаррак, аннары тагын да начаррак, тик бу нормаль хәл, бу – тормыш, – ди Гудков.

– Фильмнарда гына ул руслар төксе һәм явыз, – ди миңа янәшәмдәге волонтер – афроамериканлы егет. – Мин бөтен кешегә алар белән якыннанрак аралашырга киңәш итәм: чынлыкта, руслар бик ачык, күтәренке күңелле һәм дусларына бик хәерхаһлы. Шуңа да уңайлы очрак булган саен Россиягә омтылам – күптән күрешмәгән дуслар сагындыра.

Минем әңгәмәдәшем **Брунель Муба** чемпионатта чит ил медиачараларына ярдәм итә. Ул инде ярты гомерен волонтерлыкта үткәргән, 17 яшеннән бирле илләр гизә. Эмиейтста эшли, Португалиядә яши, элегрәк АКШ һәм Бельгиядә яшәгән. Россиядә күп кенә зур чараларда катнашкан, Казанда – Универсиадада, Конфедерацияләр кубогында, Мундиальдә. Брунель – таза гәүдәле егет, шунлыктан мин аңардан ашау якларын сораштырам.

– Волонтерлар ашханәсендә мин баштарак ризыкны сорап өстәтә идем, аннары мине хәтерләп калдылар һәм инде баштан ук күп итеп сала башладылар. Бу супер! Әйе, мондагы ризык безнең илдәгегә охшамаган, тик ул бик тәмле! Мин борщны бик яратам. Менә кичә Бауман урамындагы Татар ашлары йортына кердем һәм гомеремдә беренче тапкыр сарык итеннән әзерләнгән ризыкны авыз иттем. Татар ашларының барысының да нинди икәнен белмим, әмма кичә мин ашаганы искиткеч тәмле иде! – ди Брунель.

Аны Россиядә WorldSkills белән шулкадәр мавыгу таң калдырган. «Казан Экспога» килгән кунакларның күплеге (чемпионат вакытына барлыгы 250 меңләп кеше) шаккатырган үзен. Чараны оештыру дәрәҗәсе дә.

– Әлеге хәрәкәтнең мин булган барлык чемпионатларыннан сездәгесе – иң яхшылардан берсе. Территорияне беренче тапкыр кластерларга бүлгәннәр, бу бик уңайлы. Медиаүзәк искиткеч, – дип мактавын дәвам итә әңгәмәдәшем. – Россиядәге кайбер объектларда навигация белән проблемалар килеп чыккалый, әмма биредә барысы да идеаль. Һәм, әлбәттә, мин тагын киләчәкмен! Мин Казанга гомерлеккә гашыйк булдым ахры. Бу шәһәр дә, Мәскәү һәм Санкт-Петербург кебек үк, Россиянең тулы хокуклы вәкиле булып тора. Һәм бу яхшы да, чөнки биредә дустанә кешеләр алардагыга караганда күпкә күбрәк!

НИЧЕК МИЛЛИАРДЕР БУЛЫРГА

Волонтерлар штабыннан чыккач, экскурсиягә килгән өлкән сыйныф укучылары колоннасына кушылып китәм. Юлда тагын шундый биш төркемне очратабыз. Ярышлар вакытында әлеге «Карарга килүче» программасы буенча мәйданчыкта Татарстаннан һәм Россиянең башка төбәкләреннән меңнәрчә мәктәп баласы һәм урта махсус уку йортлары студенты булып киткән. Безнең төркемне FutureSkills – F павильонына, югары технологияле җитештерү һәм цифрлы икътисад өчен перспективалы һөнәрләр буенча ярышлар зонасына кертәләр.

– Сезгә ничә яшь? Унбишме? Безнең һөнәрләр белән кызыксына башлар өчен бер-ике елыгыз бар икән әле, алайса тормыштан артта калачаксыз! – дип мөрәҗәгать итә төркемебезгә «ТР Лазер үзәге» ҖЧҖ генераль директоры, «Лазер технологияләре» компетенциясе буенча WorldSkills эксперты **Николай Насонов.** Соңгы сүзләрен ул бик нык кычкырып әйтә.

Автор фотосы

Автор фотосы

Мәйданчыкта Татарстан бәйгечесе, Әлмәт политехника техникумы студенты **Руслан Баһманов** модуль биремен үти – бирелгән параметрлар буенча аңа шильдикка лазер җайланмасы ярдәмендә гравировка төшерергә кирәк.

– Бу саф безнең ил компетенциясе. Лазерны уйлап табучы Александр Прохоров һәм Николай Басов 1964 елда әлеге ачышлары өчен Нобель премиясенә лаек була. Илебездәге гыйльми мәктәп саклана, безнең галимнәр биредә дә, чит илләрдә дә эшли. Mercedes, BMW, Bosch, Schneiderelectric заводлары Россия лазерлары белән җиһазландырылган, – дип сөйли эксперт. – Кичә безгә WorldSkills International вәкилләре килгән иде. Мин аларга үзебез җитештерә торган стентларны күрсәттем. Бер вәкилнең тәнендә шундый ике стент бар икән, ул безнең ни өчен дөнья базарына чыкмавыбыз белән кызыксынды. Базарга чыгу өчен исә белгечләр кирәк. Ә аларны әзерләү шактый ресурс таләп итә. Казан медицина инструментлары заводы белгечен 0,5 миллиметрлы чыбыкка үлчәү шкаласын төшерергә без бер ел буе өйрәттек.

FutureSkills бурычы – ниндидер чикләүләр, мәсәлән, кирәкле закон һәм нормалар булмау сәбәпле киң кулланыла алмый торган технологияләргә игътибарны җәлеп итү.

–Дөньяны үзгәртәчәк технологияләр топ-10лыгына лазер куллануга нигезләнгән квант һәм аддитив технологияләр керә. Ул – хәзерге заман икътисадының нигезе. Смартфон эченең 80 проценты лазер ярдәмендә эшләнә! – ди Николай Насонов. – Әлеге белгечлек бик популяр булырга тиеш кебек тә, чынлыкта башкачарак: бүген эретеп ябыштыручыны табу катлаулы булса, лазер белән эретеп ябыштыручыны бөтенләй табып булмый. Ә бит җепселле лазерның тотрыклы чыганагын тапкан Россия физигы Валентин Гапонцев доллар миллиардеры булды һәм Forbes исемлегенә керде...

ТЕЛӘК БУЛСА, ҖИҢҮ ТАБЫЛА!

Һөнәри осталык буенча WorldSkills дөнья чемпионатының Казанда үткән 45 нчесен хәрәкәт тарихында беренче тапкыр Россия кабул итте. Кунаклар һәм катнашучыларның күпсанлы мактау сүзләренә караганда, премьера бик уңышлы булып чыкты. Татарстан медальләр буенча икенче урынга чыккан Россия милли җыелмасы казанышларына да үз өлешен кертте (безнекеләр 1 алтын, 1 көмеш, 1 бронза медаль яулады). Чемпионат илчесе, «Ралли Дакар» узышының күп тапкыр җиңүчесе Владимир Чагин журналистларга әйткәнчә, бик теләгән, хәтта үзенең узышта катнашуын һәм җиңүен төшләрендә күргән кеше генә иң шәп пилот була ала.

WorldSkills чемпионатындагы иң яхшы тәҗрибәләрне кертү җәһәтеннән республика тәмам уянып җитте һәм яңа җиңүләргә әзер.

– Дөньяны үзгәртәчәк технологияләр топ-10лыгына лазер куллануга нигезләнгән квант һәм аддитив технологияләр керә. Ул – хәзерге заман икътисадының нигезе. Смартфон эченең 80 проценты лазер ярдәмендә эшләнә! – ди Николай Насонов. – Әлеге белгечлек бик популяр булырга тиеш кебек тә, чынлыкта башкачарак: бүген эретеп ябыштыручыны табу катлаулы булса, лазер белән эретеп ябыштыручыны бөтенләй табып булмый.

Фото WorldSkills International тарафыннан бирелде

PRESSA

WORLDSKILLS KAZAN 2019:
ЧЕМПИОНАТТАН СОҢ БАР ДА КАЛА...

Казанда үткән һәр дөньякүләм вакыйгадан соң, шәһәргә истәлеккә һәм файдалану өчен шактый нәрсәләр кала.

WorldSkills 2019 эшче һөнәрләр чемпионатыннан соң, Казан инфраструктурасы «Казан Экспо» Халыкара күргәзмә үзәге, иң югары халыкара стандартларга туры килүче өр-яңа җиһазлар һәм, әлбәттә инде, дөньядагы иң яхшы белгечләр белән тулыланды. Ә бу вакыйгага катнашы булган һәркемдә бөтен гомерләренә җитәрлек онытылмас тәэсирләр һәм матур истәлекләр калды. Алар бу турыда «Татарстан» хәбәрчеләре белән дә уртаклашты.

КЕШЕЛӘРНЕҢ ТУГАН ИЛЛӘРЕ БЕЛӘН ГОРУРЛАНУЫН КҮРҮ-ИШЕТҮ КҮҢЕЛЛЕ

Изабель Коллин, тимлидер, Нью-Брансуик, Канада:
– Мин Канаданың Калгари шәһәрендә узган шундый ярышларда катнашкан идем. Менә хәзер, 10 ел узганнан соң, тимлидер буларак бирегә килдем. Рус кешеләренең менталитеты мине гаҗәпләндерде һәм шатландырды: алар бик җитди, төгәл һәм барысын да нәтиҗәле итеп башкаралар. Кешеләрнең үз илләре белән горурлануын күрү-ишетү бик күңелле!

БЕЗ БЕРГӘЛӘП ГАРМОНИЯЛЕ КИЛӘЧӘК БУЛДЫРЫРБЫЗ

София, робот. WorldSkills 2019 чемпионаты ачылу тантанасының махсус кунагы:
– Технология – бу дөньяны өйрәнүнең инструменты гына. Без бергәләп йолдызара чакрымнарны узып, бөтен кешеләр өчен матур һәм имин киләчәк булдыра алырбыз.

Алёна Кутыркина, Александр Ефремов фотолары

БАРЫННАН ДА БИГРӘК МИҢА САБАНТУЙ ОШАДЫ

Дан Ши, Кытай җыелма командасы әгъзасы:
– Миңа Казанда барыннан да бигрәк Сабантуй ошады – шулкадәр күп конкурсларда катнаша алуың бик шәп бит. Безнең Кытайда моңа охшаган милли бәйрәмнәр бар, һәм аларны кешеләр сездәге кебек үк күңелле итеп үткәрергә ярата.

САННАР ГЫНА:

22–27 августларда WorldSkills 2019 эшче һөнәрләр чемпионатына җыелдылар:

63 ил

1360 конкурсант

1294 эксперт

3 688 волонтёр

272 345 җанатар

МИҢА ТУГАН ҖИРЕМ ҺӘМ ТАТАР МУЗЫКАСЫ ЯРДӘМ ИТТЕ

Айдар Минеев, Яр Чаллы шәһәре, Татарстан. Айдар «Прототиплар әзерләү» компетенциясендә алтын яулады:
– Бу максатка ирешү өчен бик күп көч түгелде. Бу колачлы эш минеке генә түгел, экспертларныкы һәм тренерларныкы да. Мин күп айлар дәвамында 8–11әр сәгать шөгыльләндем. Һәм хәзер бик бәхетле. Миңа шулай ук туган җирем, ышанычым һәм яраткан татар музыкасы да ярдәм итте дип уйлыйм. Мин шөгыльләнгән чакта татар көйләрен тыңлый-тыңлый эшләдем, алар миңа тиешле эш темпын бирә иде. Хәзер мин туган илем һәм Татарстаным өчен горурлык хисләре кичерәм. Россиянең мин ярышкан компетенциядә дөньяда беренче булуын телим, шуның өчен WorldSkills хәрәкәтендә калырга һәм булачак чемпионнарны әзерләүдә катнашырга җыенам.

КАЗАННЫ УЗДЫРУ БИК АВЫР БУЛАЧАК

Вильям Исейсе, КАР, фотограф:
– Мин чын-чынлап Россиягә гашыйк булдым. Монда бик күп төрле, әмма бик тә кызыклы һәм бай мәдәниятکә ия кешеләр яшәве минем өчен күңелле ачыш булды. Мин шәһәр буенча оештырылган экскурсияләрнең берсендә катнаша алдым – без Ленин университетында булдык. Мин WorldSkills ярышларының торган саен яхшыра гына баруын беләм, әмма моннан соңгы оештыручыларга Казанны уздыру бик авыр булачак.

ТОРМЫШЫМДАГЫ ИҢ ЯХШЫ ИСТӘЛЕКЛӘР КАЗАН БЕЛӘН БӘЙЛЕ

Анастасия Камнева, Ярославль шәһәре, «Лаборатор химик анализ» компетенциясе. Анастасия чемпионатның Гран-прие – WorldSkills хәрәкәтен булдыручыларның берсе Альберт Видаль бүләген алды:
– Тәэсирләр сөйләп бетергесез! Шатлыктан мин хәтта берни әйтә дә алмадым, сәхнәдә бәхетемнән еладым гына. Хәзер, чемпионаттан соң, үз эшемдә тагын да камилләшәсем һәм мин җиңүгә ирешкән «Лаборатор химик анализ» компетенциясен Россиядә үстерәсем килә. Мин чемпионатның Россиядә үтүенә бик шатмын. Казан миңа бик ошады, гаҗәеп матур шәһәр һәм хәзер тормышымдагы иң якты истәлекләр шушы урын белән бәйле.

Алёна Кутыркина, Александр Ефремов фотолары

БАРЫБЫЗ ДА ТАТАР МӘДӘНИЯТЕНӘ МӨКИББӘН

Юлия Маликина, Петрозаводск ш., Карелия Республикасы:
– Мин – штабта волонтёр, чемпионатка җәлеп ителгән волонтёрлар өчен вчек-ин һәм чек-аут. Без, Төньяк-көнбатыш федераль округыннан килгән делегациябез белән бергә (Карелия, Ленинград өлкәсе шәһәрләреннән, Архангельск, Мурманск, Калининградтан барлыгы 20 кеше килдек) Казанны бераз гына өйрәнергә өлгердек, Кремльдә, Игенчеләр сараенда булдык, шәһәр буйлап йөрдек, аның матурлыгына сокландык. Барыбыз да шәһәргә, татар мәдәниятенә мөкиббән. Легендар өчпочмак белән сыйландык, бу шулай ук милли традицияләр белән танышуның бик шәп ысулы.

ТАТАР КУХНЯСЫН ӨЙРӘНҮ ДӘ КЫЗЫКЛЫ БУЛЫР ИДЕ

Искәндәр Слаев, Оренбург ш., «Аш-су эше» компетенциясендә 1 нче урын:
– Кулинария – минем мәхәббәтем, аны тулысынча белү өчен тулы бер гомер җитмәве миңа ошый. Үзем ит һәм балык ашлары әзерләргә яратам, десертларны ял итү өчен ясыйм, ә инде ашарга гади өй ризыкларын яратам. Казан – бик матур шәһәр, татар кухнясын өйрәнү кызыклы булыр иде, әлегә мин өчпочмакларны бик яраттым.

БЕЗГӘ БӨТЕН ДӨНЬЯНЫ ҖИҢҮ НАСЫЙП БУЛДЫ!

Анастасия Распопова, Чиләбе ш., Анастасия «Визуаль мерчендазинг» компетенциясендә алтын яулады:
– Минем өчен бу компетенциядә нәкъ менә Россиянең җиңеп чыгуы гаҗәп тоелды, чөнки бездә бу белгечлеккә беркайда да өйрәтмиләр бит. Без мәгълүматны бөртекләп эзләдек дияргә була, чит ил китапларыннан җыйдык. Һәм безгә бөтен дөньяны җиңү насыйп булды! Хәзер минем максатым –Россиядәге яшь белгечләргә бу эшкә җиңелрәк өйрәнү мөмкинлеге булсын өчен, витриналар эшләү буенча китап язу. Казан – шундый җыйнак һәм яшел шәһәр. Кайбер почмакларында үзеңне Европадагы кебек хис итәсең. Минем хәтта монда яшисем һәм эшлисем килеп китте, чөнки тормыш дәрәҗәсе буенча Казан Мәскәү янсә Санкт-Петербург кебек, шул ук вакытта ул тынычрак, ә бу тормыш өчен бик уңайлы.

Фото: РФ Президенты рәсми сайтыннан

РӘХМӘТ ТАТАРСТАНГА! РӘХМӘТ КАЗАНГА!

Владимир Путин, Россия Президенты, WorldSkills 2019 чемпионатын ябу тантанасында:
– Безнең кунакларыбызга Казан ошагандыр дип ышанам – борынгы тарихы һәм актив яшьләре булган искиткеч, алгарышлы үсештәге шәһәр. Биредә намуслы, гадел ярыш максаты белән 60тан артык илдән килгән катнашучыларга һәм тамашачыларга дусларча аралашу өчен барлык шартлар тудырылган иде. Рәхмәт Татарстанга, рәхмәт Казанга!

САННАР ГЫНА:

2015 елда Россия җыелма командасы Сан-Паулода 14 нче урын алды

2017 елда Абу-Дабида Россия инде 5 нче урынга чыкты

2019 елда Казанда Россия гомумкоманда зачетында 2 нче урын алды

Россия җыелма командасы тупланмасында 22 медаль:

14 алтын

4 көмеш

4 бронза

25 медальон профессионализм өчен

Төрле дәрәҗәдәге 35 медаль иясе булган Кытай командасы беренчелекне яулады

ТАТАРСТАН ПРОФЕССИОНАЛЛАРЫ – ДӨНЬЯ ПРОФЕССИОНАЛЛАРЫ

Августта Казанда WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык дөнья чемпионаты узды. Вакыйга әлеге хәрәкәт тарихында Россиядә беренче мәртәбә дөнья дәрәҗәсендә үткәрелүе белән дә уникаль. Аны үткәрүдә «Челтәр компаниясе» ААҖнең 200дән артык белгече катнашты.

– Дөнья дәрәҗәсендәге спорт, мәдәни, иҗтимагый чаралар Казанның визит карточкасына әверелде. Без масштаблы чараны энергия белән тәэмин итүне оештыру процессын эшләдек һәм җайга салдык, шуңа күрә WorldSkills дөнья чемпионатында эш фактта штат режимында алып барылды. Шул ук вакытта безнең һәрберебез җаваплылыкны тоеп, үз бурычын хилафлыкларсыз, төгәл үтәүнең никадәр мөһим икәнлеген аңлап, тулы көченә эшләде, – ди «Челтәр компаниясе» ААҖ генераль директоры Илшат Фәрдиев.

ӨЗЛЕКСЕЗ РЕЖИМДА

Чемпионатка әзерлекне компания алдан ук башлады.Чара өчен әһәмиятле энергообъектларның исемлеге шактый озын иде: 110–500 кВ лы 19 подстанция, 27 һава һәм кабель-һава линиясе, «ТГК-16» ААҖнең бер объекты һәм «Татэнерго» АҖнең 3 объекты. «Юбилей» һәм «Аэропорт» подстанцияләрен әзерләү аерым игътибарны таләп итте.

– Подстанцияләрдә барлык инженер-техник җайланмалар тикшерелде, сак хезмәтен алып бару өчен шартлар яхшыртылды. Лаеш подстанциясе төркеме хезмәткәрләре – электромонтер Илнар Сабитов һәм мастер Андрей Моряшинның үз эшләрен җиренә җиткереп башкаруларын билгеләп үтәсе килә, – дип сөйләде безгә Идел буе электр челтәрләренең (ПЭС) төп электр челтәрләре буенча баш инженер урынбасары Илдар Баязитов. – Идел буе электр челтәрләренең Шәһәр буе районы электр челтәрләре «Дорожный» РПнең оператив-күчмә бригадасы монтёрлары Айдар Акмаев һәм Артем Писакин чемпионатның үзәк объекты – «Казан Экспо» халыкара күргәзмә үзәгендә төп чыганакның өзлексез эшен контрольдә тотты. Моннан тыш, су аркылы чыгу юлындагы 6 «алтын» терәк баганаы, һәм шулай ук «Казан Экспо» белән янәшәдәге электр установкаларын саклау көчәйтелде. Әлеге объектларны карау һәм контрольлектә тотуны ПЭС линияләре хезмәте электромонтёрлары Александр Клочков һәм Виктор Петрунин башкарды.

Чемпионатны «Челтәр компаниясе» тулы әзерлек – энергия белән тәэмин ителешнең көйләнгән ышанычлы схемасы, кизү торуларның, ватылу-өзелүләрне тиз арада ачыклау һәм штаттан тыш инцидентларны кисәтү максатында карап-тикшереп чыгуларның төгәл графигы белән каршы алды. Казан энергорайоны буенча контроль максатында үткәрелгән гомумсистема аварияләргә каршы күнегүләр персоналның авария-торгызу эшләренә әзерлеген күрсәтте. «Челтәр» белгечләре хәтта форс-мажор хәлләргә калу очрагын да тикшерделәр: «Казан Экспо» ХКҮндә һәм «Казан-Арена» стадионында тышкы энергия тәэмин ителешен сүндереп, дизель-генератор установкаларын эшләтеп карадылар.

ИГЪТИБАР ҮЗӘГЕНДӘ

«Казан Экспо» ХКҮ территориясе чемпионат көннәрендә шаугөр килде: дөньяның 63 иленнән килгән 1300 дән артык конкурсант 56 компетенция буенча көч сынашты. Аларның эшенә 1300 гә якын

Фотолар «Челтәр компаниясе» ААҖ матбугат хезмәтеннән алынды

Реклама

эксперт бәя бирде. 22 августтан 27 августка кадәр «Казан Экспо»га 250 мең кунак килде. Компетенцияләрне урнаштыру өчен, даими павильоннарга (сүз уңаеннан, аларның гомуми мәйданы 58 гектардан артык) өстәмә рәвештә берничә вакытлычасы төзелде. Ярыш мәйданчыклары А үзәк павильонында төзелде, анда шулай ук фуд-корт, чемпионатның күпләгән партнерларының демо-зоналары урнашты, эшлекле программа, мәктәп укучылары һәм яшьләр өчен чаралар да оештырылды. Моннан тыш, А павильоны шәһәр һәм «Казан» аэропортын тоташтыручы хаб ролен дә үтәде.

– Без күпләгән объектны энергия белән тәэмин итүне контрольдә тоттык. Иң мөһим объектларның берсе матбугат үзәге булды, аннан дөньяның төрле почмакларыннан килгән телеканаллар һәм мәгълүмат агентлыклары онлайн-трансляцияләр һәм туры эфирлар алып барды, – дип сөйләде «Казан Экспо»ның энергоменеджеры, Идел буе электр челтәрләре баш инженеры урынбасары Илдар Хәмитов.

– Чемпионат вакытында «Казан Экспо»да ышанычлылыкның махсус дәрәҗәсе булдырылды, ә үзәк электр энергиясенең резерв чыганаклары белән дә тәэмин ителде, – Чистай электр челтәрләре хезмәтләрен гамәлгә ашыру буенча директор урынбасары Сергей Панфилов.

ҖИҢҮЧЕЛӘР АВЫЛЫ

Ярышлар вакытында Россиядәге иң яхшы студент кампусларының берсе булган Универсиада авылы – WorldSkills авылы конкурсантлар һәм 3,5 мең волонтёр өчен чын йортка әверелде. 28 бинадан торган комплексны энергия белән тәэмин итү эшен Казан электр челтәрләренең (КЭС) оператив-технологик идарә буенча баш инженеры урынбасары Марат Гайфуллин җитәкчелегендәге КЭС белгечләре контрольдә тотты. Авылда чемпионатны үткәрүгә җәлеп ителгән барлык оешмаларның эшен көйләп торучы төп операцион үзәк тә урнашты. «Челтәр компаниясе», чараларның энергооператоры буларак, электр белән тәэмин итүнең эчке һәм вакытлыча челтәрләренә техник аудит үткәрде, электр установкаларын карап тотуга һәм аларга хезмәт күрсәтүгә методологик һәм техник контроль ярдәме күрсәтте. Чемпионат чараларына «Челтәр компаниясе» ААҖ филиалларының һәм идарәсенең 200 гә якын хезмәткәре җәлеп ителде. Ярышларга кадәр һәм алар вакытында объектларны электр энергиясе белән ышанычлы тәэмин итү максатында компаниянең генераль директоры Илшат Фәрдиев Компания идарәсендә республика сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, һәм шулай ук Татарстанның энергетика предприятиеләре вәкилләре катнашлыгында оператив штаб утырышлары үткәрде.

ИҢ ЯХШЫЛАР ПЬЕДЕСТАЛЫ

София исемле робот, стадион өстендә йөзеп йөргән виртуаль кит, 300 артист катнашлыгындагы театраль тамаша – болар һәм башка бик күп кызыклы мизгелләр «Казан-Арена» стадионында узган чемпионат ачылышы тантанасында бик күпләрнең исендә калгандыр. Ябылу тантанасының төп вакыйгасы чемпионатта җиңгән 130 кешегә бүләк тапшыру мизгеле булды. Тамашаның онлайн һәм телетрансляцияләрен 140 миллион тамашачы карады. Болар барысы да 11 энергетиктан торган һөнәрмәндләр командасы – Алабуга электр челтәрләре директоры, энергоменеджер Эдуард Шаронов җитәкчелегендәге Әлмәт, Алабуга, Чистай, Яр Чаллы электр челтәрләре бүлекчәләре белгечләре командасының җайга салынган профессиональ хезмәте нәтиҗәсендә мөмкин булды. Нәкъ менә әлеге команда, 2013 елгы Универсиададан башлап, теләсә нинди һава шартларында һәм тәүлекнең теләсә кайсы сәгатендә «Казан-Арена»да узган һәр зур чараны өзлексез рәвештә электр энергиясе белән тәэмин итүне башкара.

– Без – энергетика өлкәсендә берничә бөтенроссия конкурсларының җиңүчеләре. Әгәр без үзебез WorldSkillsta катнашсак, һичшиксез, пьедесталга менәр идек, – ди Эдуард Шаронов.

Шулай ук стадионның периметры буенча урнаштырылган электр установкаларында – трансформаторлы дүрт подстанциядә һәм РП-109 энергия бүлү пунктында Төньяк РЭС башлыгы Рәис Халиков җитәкчелегендәге оператив-күчмә бригада вәкилләре тиз арада эш итү максатында вазгыятьне контрольдә тотты.

«Челтәр компаниясе» белгечләре хезмәтләрендә генә түгел, яраткан шөгыльләрендә дә камиллеккә ирешәләр: Россия гимнын, шулай ук Игорь Крутой һәм Димаш Кудайбергенов композицияләрендәге партияләрне башкарган хор составында «Челтәр компаниясе» ААҖнең конкурслы сатып алулар бүлеге белгече Оксана Бажина да катнашты.

«СПАСИБО!» ҺӘМ «РӘХМӘТ!»

Ябылу тантанасында Россия Президенты Владимир Путин һәм WorldSkills президенты Саймон Бартли чемпионатны кабул иткән якка рәхмәтләрен белдерде. «Миңа «спасибо!» һәм «рәхмәт!» әйтергә рөхсәт итегез», – диде Саймон Бартли. «Татарстанга рәхмәт! Казанга рәхмәт!» – дип тәмамлады үзенең чыгышын Владимир Путин. Әлеге сүзләр «Челтәр компаниясе» ААҖ белгечләренә дә юлланды.

– WorldSkills дөнья чемпионаты – осталыкка, яшьлеккә һәм буыннар алмашына мәдхия, ата-аналарга, укытучыларга, мастерларга, остазларга мәдхия. Ул киләчәкнең яңа һөнәри офыкларга омтылучы яшьләр кулында икәнлеген ачык күрсәтте, – дип чарага йомгак ясады Илшат Фәрдиев. – Мин исә чемпионатны, Казанны һәм Татарстанны дөнья дәрәҗәсендә электр энергиясе белән тәэмин итеп, тагын бер мәртәбә үзенең осталыгын раслаган «Челтәр компаниясе» командасы белән горурланам.

ОНЛАЙННАН – ОФЛАЙНГА

КАЗАН БЛОГЕРЛАРЫ ВИРТУАЛЬ АРАЛАШУГА КАРАГАНДА РЕАЛЬ АРАЛАШУ ШӘБРӘК ДИП САНЫЙ

«Татарстан» журналы һәм «Казан блогерлары рейтингы» (RBK) «Инстаграм»да «Спортблогер» һәм «Медиаблогер» номинацияләре буенча иң яхшы блогер исеменә тавыш бирү уздырды. «Татарстан» редакциясендә финалистлар һәм җиңүчеләр ике ай дәвамында кунак булды – үз тормышлары турында сөйләделәр, «Инстаграм»да популярлык серләре белән уртаклаштылар, редакциядән виртуаль түгел, ә чынбарлыктагы дуслар булып киттеләр, чөнки күзгә-күз аралашу, бәйгедә катнашучыларның һәркайсы раслаганча, виртуаль аралашудан күпкә шәбрәк. Чөнки аларның күбесе «Инстаграм» буенча кардәшләрен беренче тапкыр гына «тере килеш» күрә алды.

Фото: Юрий Похлёбин



MediaBloger

номинациясендә

– язылучыларының гомуми саны 8 000 112 кеше булган
– 120 блогер катнашты
– барлыгы 100 000 кеше тавыш бирде

MediaBloger номинациясе җиңүчеләре:
– Айгөл Бариева, ТРның атказанган артисты
– Ләйлә Дәүләтова, «Адәм белән Һава» (ТНВ) тапшыруының авторы һәм алып баручысы
– Римма Никитина, татар эстрадасы йолдызы

SportBloger

номинациясендә

– язылучыларының гомуми саны 2 000 000 кеше булган
– 75 блогер катнашты
– барлыгы 50 000 кеше тавыш бирде

SportBloger номинациясе җиңүчеләре:
– Данис Зарипов, «Ак Барс» хоккей командасы капитаны
– Никита Комаров, тренер
– Валерия Харебова, тренер
– Федор Тимофеев, тренер

SportBloger номинациясендә җиңүчеләр арасында Данис Зарипов RBKның махсус бүләгенә лаек булды.

ДАНИС ЗАРИПОВ: ӨСТЕНЛЕК – ХОККЕЙГА

«Ак Барс» хоккей командасы капитаны, өч тапкыр дөнья чемпионы, биш тапкыр Гагарин кубогы иясе Данис Зарипов «Татарстан» редакциясенә туп-туры «Инстаграм»нан килеп керде. Челтәрдә исә язылучыларның фотолары, постлары һәм лайклары, редакциядә – җылы хисләр һәм «Татарстан» укучылары белән җанлы әңгәмә калды.

Автор:
Артём Гайнетдинов

– Дөресен генә әйткәндә, бу пьедесталга ирешүемә гаҗәпләнәм дә, чынлыкта мин бу аккаунтны үстерү белән әллә ни шөгыльләнмим дә. Һәр адымымны төшереп барырга, тормышым белән уртаклашырга яратмыйм. Вакыт-вакыт мин, әлбәттә, анда фотолар куйгалыйм. Сәхифәмдә күңелле атмосфера сакларга тырышам. Әмма исемемнең бу конкурста яңгыравына бик шатмын, җиңү яулавы бик күңелле. Бәлки, бу җиңүдән соң «Инстаграм» сәхифәмә җитдирәк карый башлармын.

– Алканың шешә капкачына эләгүенә караганда да җитдирәкме? Сезнең бу темага челленджыгыз, караучылар саны буенча фикер йөрткәндә, шаккаткыч булып чыкты…

– Мин үзем дә гаҗәпләндем, бу эшкә ярты көн китәр инде дип уйлаган идем, җиденче тапкырында бугай, килде дә чыкты.

– 70 мең язылучыгыз бар, яхшы сан. Безнең шәһәр спортка якын һәм күп спортчылар үз аккаунтын актив алып барырга тырыша, ләкин сезнең хоккей сәхифәгез баскетболчылар, футболчылар, волейболчыларныкының гомуми массасыннан аерылып тора… Шул исәптән юмор хисе белән дә. Ул сезгә язылучылар армиясен арттырырга булышамы?

– Ничек атала әле? Сүзен оныттым… Ә-ә, «накрутка»! Менә! Миңа күпләр әнә шул «накрутка» белән шөгыльләнергә тәкъдим итте. Тик мин мондый алымнар яклы түгел. Мине башкалар кебек язылучылар саны артыннан куу кызыксындырмый. Андый теләгем бөтенләй юк. Күпме бар, шуның кадәр булсын. Барысына да шатмын.

– Сезнеңчә ничек: сез спортта күбрәк танылганмы, әллә «Инстаграм»дамы?

– Әлбәттә, «Инстаграм»да.

– Әмма спорт бүләкләрен сез анда җыймадыгыз бит. Реаль карьерагыз таң калдыра! Дөнья чемпионаты, КХЛ… Шундый атаклы өчлектә уйнадыгыз: Зарипов –Морозов – Зиновьев… Җанатарлар мондый уеннан чын рухи ләззәт ала иде. Телефонда утырып, андый нәрсәләр ясап булмый. Моны ничек булдырдыгыз?

– Хәзер менә бу сүзләрегездән соң сагынып җибәрдем. Уеннарга кертсән өлешемне, хезмәтемне һәм җиңүләремне онытмавыгыз һәм бәяләвегез өчен рәхмәт. Мин җиде яшьлек чагымда хоккейда ясаган беренче адымнарым бушка китмәгәнгә бик шат. Бөтен хезмәтем, беренче чиратта, үземне тәрбияләү эше, шул җиңүләр белән бүләкләнде. Бу минутларда, бу сезоннарда минем белән бергә бозда, командада булган барлык партнерларыма да бик рәхмәтле-

Фото: Александр Ефремов

Фото «Ак Барс» хоккей клубының рәсми сайтыннан алынды

мен. Ачыктан-ачык әйтәм, хоккейның бер уенчыныкы гына түгел, ә команда уены икәнен һәркем яхшы аңлый, партнерларсыз берни дә эшли һәм бернигә дә ирешә алмыйсың.

– Әниегез ягыннан тамырлар Алабуга районының Татар Дөм-Дөме авылына тоташа, һәм сез анда һәрвакыт Гагарин кубогын алып киләсез. Әлеге кечкенә авылдагы малайларның да сезнең кебек танылган хоккейчы булу мөмкинлеге бармы?

– Һәркайсының форсаты бар, тик мөмкинлекләр генә күпкә азрак. Шуңа күрә ярдәм итәргә тырышабыз да. Туган-тумача, егетләр ярдәме белән без авылда хоккей белән шөгыльләнү өчен шартлар тудырдык, хәтта ишегалды хоккее өчен булса да. Берничә ел дәвамында минем исемдәге турнир үткәрелде, Дөм-Дөм малайлары хоккейга бик күп вакыт бирә иде. Әмма, кызганычка, заманалар үзгәрә, һәм күп кенә ата-аналар балалары белән зур шәһәрләргә күчәргә тырыша. Шәһәр җирендә балаларны спорт (һәм ул гына да түгел) белән шөгыльләндерү мөмкинлекләре күбрәк. Хәзер анда ниндидер команда ясардай дәрәҗәдә хоккей белән җитди кызыксынучы балалар калмады диярлек. Әлегә ниндидер тынычлык, сүлпәнлек күзәтелә. Мин бу юнәлешне ташларга җыенмыйм, ярдәм итәчәкмен һәм үстерәчәкмен, булдыра алганның барысын да эшләячәкмен. Күрше авыллар да бар бит. Балалар бөтен җирдә дә спорт белән шөгыльләнергә тиеш, ә моның өчен мөмкинлекләр минималь булган төбәкләргә ярдәм итәчәкбез – шулай кирәк ул.

– Төрле авыллардан чыгып, тормышта ниндидер уңышларга ирешкән күп кенә кешеләр хәзер үзләренең туган җирләренә ярдәм итәргә тырыша. Әлеге уй ниндидер бер яшьтә килә һәм нинди дә булса файдалы эш эшләгәнче, һич китми, диләр...

– Нәкъ шулай булды да. Тугыз ел элек, 2009 елгы җиңүдән соң, миндә шундый фикер туды. Абзый белән сөйләшеп утыра идек, шулчак ул күп балаларның хоккей белән янып, кызыксынып йөргөн әйтте. Авыл үзе әллә ни зур түгел, тик анда барысы да хоккей карый. «Зарипов, Морозов һәм Зиновьев өчен җан аталар», – диде абзый. Ул идея әнә шулай туды – малайларны хоккейга өйрәтеп карарга, турнирлар үткәрергә карар кылдык. Ул вакытта барысы да бик яхшы барды. Хәзер хоккей уйнау теләге югалганмы, әллә кызлар малайларга караганда күбрәк була башладымы... Гомумән алганда, Дөм-Дөмдә хоккей дәрте бераз сүрелде.

– Ә сезнең үз уен стилегез яшь белән бергә үзгәрәме? Бу хакта үзегез ни уйлыйсыз?

– Барысы да тренер кушканга, тактикага бәйле. Нинди генә стилең булмасын, барыбер кайдадыр җайлашасың, киңәшләшәсең, командада булырга кирәк, ул – бердәм, бер организм.

– Әгәр сез спорт министры булсагыз, беренче эш итеп нишләр идегез?..

– Бу хакта уйлап та караганым юк. Быел минем өчен бик җитди сезон. Әүвәлгеләре җитди булмаган кебек килеп чыкты бу сүзләр... Шулай да быелгысы үзенчәлекле – егерме еллык һөнәри карьерамда беренче тапкыр мине сезон башыннан ук капитан итеп куйдылар. Моңа бик җаваплы карыйм. Егетләрнең барысының да миңа ышанычын сизәм, команданы үз артымнан алып барырга кирәклеген тоям. Һәркем арасында яхшы мөнәсәбәтләр урнашсын, коллектив бердәм булсын, каршылык-бәхәсләр килеп чыкмасын, нәтиҗәгә комачаулар-лык һичнәрсә калмасын өчен, командада уңай мохит булдырырга тырышам. Әлбәттә, җиңүләр өчен хәлебездән килгәннең барысын да эшләргә тырышырбыз, ә килеп чыкмаса, тренировкаларны үзгәртербез. Башымда шундый уйлар гына. Шуңа күрә башка нәрсә турында – әйтик, бизнес турында (бу хакта күпләр кызыксына), берни дә әйтәсем, алдан фаразлыйсым килми. Барысы турында да бер үк вакытта кайгыртып йөреп булмый. Югыйсә, хоккей шунда ук аска тәгәрәячәк. Әлегә булдыра алуымны тойганда, теләгем булганда, сәламәтлегем мөмкинлек биргәндә, хоккейга үземне тагын берничә ел тулысынча багышларга телим. Карьера тәмамлангач, вакыт күпкә иркенрәк булачак, анда инде бөтенләй башка юнәлешне тулы куәткә үстерергә мөмкин. Ә әлегә өстенлек – хоккейга.

ТАТАРСТАНДА ЖИҢӘСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»!НЫ УКЫ

МАХСУС ПРОЕКТ

УЗГАН ГАСЫР УКЫТУЧЫЛАРЫ

Иллюстрация: Бачевская-Беляева Прасковья Филипповна, «Учительница»

ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның җиңел кулыннан социаль челтәрләрдә #МинемЯратканУкытучым акциясе башланып китте. Теләге булган һәркем үзенең мәктәбе, укытучылары турындагы якты истәлекләре белән уртаклаша алды. Гаилә корып, балалар-оныклар тәрбияләгән, бу гасырда инде үз эшләренең осталарына әверелгән узган гасыр укучылары сентябрь ае дәвамында яраткан укытучылары турында сөйләделәр. Укытучыларның кайвакыт шаян-шук балаларга белем генә биреп калмыйча, аларны гап-гади кешелеклелек сыйфатларына: дуслыкка, хөрмәткә, җаваплылыкка, миһербанлылыкка, үзара ярдәмгә, тыйнаклыкка өйрәтүләре турында сагынып искә алдылар. Узган гасыр укучыларының бүгенге көнгә кадәр һәр очрашуда яраткан мөгаллимнәрен искә алулары, аларга кунакка йөрүләре, авыр вакытта киңәш сорап килүләре дә очраклы хәл түгел. Хөрмәт һәм соклану – инде олыгайган укучыларның үз укытучыларына карата булган хисләрен әнә шулай атарга буладыр. Бүген дә укытучылар белән укучылар арасында шундый җылы мөнәсәбәтләр сакланамы? Балаларыбыз үзләренең мәктәп укытучыларына шундый ук җылылык белән карасын өчен нишләргә? Укытучыга балаларның гомер буена җитәрлек мәхәббәтен яулар өчен нишләп була? Укытучылар көне алдыннан «Татарстан» журналында узган гасыр укытучылары – иң яраткан һәм хөрмәт иткән кешеләребез.



МАХСУС ПРОЕКТ
УЗГАН ГАСЫР УКЫТУЧЫЛАРЫ

ЯРАТЫП УКЫТЫГЫЗ

Фронтовик Галина Середа үзенең 40 ел гомерен совет мәктәбенә багышлаган. Сугыш афәте укытучыны кырысландырмаган, балаларга ул үзенең күңел җылысын биргән, укучыларыннан да шундый ук җавап алган.
–Яратып укытыгыз, – дип киңәш бирә Галина Михайловна, – шул вакытта гына нәтиҗәсе була. Сез биргән белем балаларда гомер буена калачак, ә тәрбия һәм шәхси үрнәк шәхесне формаштыруда зур роль уйный. Шул вакытта мәктәптән лаеклы һәм гыйлемле кеше чыга!

Автор:
Гадел Хәеров

Галина Михайловнаның никадәр чыгарылышы булганын, үзенең никадәр укучыны, кош балаларыдай канаты астыннан очырып, зур тормыш юлына озатканын санап бетерерлек түгел! Күпчелеге укытучыларын әле дә онытмый. Алар арасында Татарстан Республикасы Премьер-министры Алексей Валерьевич Песошин да бар.

– Алеша минем соңгы чыгарылышым сыйныфыннан иде, – дип искә төшерә Галина Михайловна. – Узган елда, Җиңү парадыннан соң, ул мине ресторанда күреп, яныма килде. Без аның белән читтәрәк өстәл артына күчеп утырып, бер сәгатьләп сөйләштек, мәктәпне, укытучыларны һәм укучыларны искә төшердек.

КЫЗ БАЛА ҺӘМ СУГЫШ

Тумышым белән мин Смоленскидан. Ничек Казанга килеп чыктыммы? Бу бик озын тарих, аның исеме – сугыш.

Сугышның беренче айларында ук фашистлар Смоленск шәһәрен бомбага тотып, аны нигезенә кадәр җимерде. Успение соборы гына исән калды, аңа люфтваффе* тимәде, чөнки шәһәрне чираттагы тапкыр утка тоту өчен ориентир кирәк иде. Сугыштан соң без олы апам Вера белән туган нигезгә кайттык. Землянка казып, берникадәр вакыт анда яшәдек…

Сугыш Вера өчен Орелда башланып Польшада тәмамлана, фронт юлын ул шәфкать туташы булып уза, танкистка кияүгә чыга. Ирен Казан танк училищесына укытырга җибәрәләр, фатир бирәләр. Шулай итеп, апа мине һәм кечкенә сеңлебезне үзенә чакырып китерде.

Бөек Ватан сугышында мин партизаннарда санитарка идем. Брянск урманында землянкада урнашкан госпитальдә эшләдем. Җыештырдым, перевязкалар ясадым, авыруларны ашаттым-эчердем, авылга көмешкә алырга йөрдем, аны без яралыларга ампутация алдыннан наркоз урынына бирә идек.

Аннары мин генерал Павел Беловның (соңрак – Советлар Союзы Герое) икенче кавалерия корпусында разведчица булдым, 41нче елда миңа бары тик 9 яшь иде, шуңа күрә мин дошманнар тылында шик уятмадым. Шуннан файдаланып, мин немецларның урнашкан урыннары, техникалары турында мәгълүмат җыеп йөрдем. Ләкин 43нче елда оккупацияләнгән территориядә элемтәче белән очрашу алдыннан мине полицайлар эләктерде һәм концлагерьга озатты.

Фронт рейх чикләренә якынлаша иде. Бу көннәрдә фашистлар бик усалланды. Балаларны баракларга ябып, ишектәрәзәләрне кадаклап куялар. Эчтә калучылар ачтан газапланып үлүгә дучар булалар. Газ мичләре сүнгән булганга, мәетләрне урманга илтеп, чокырга ыргыталар. Без, поляк кешесе белән бергә, көн саен анда балаларның үле гәүдәләрен ташырга тиеш идек. Качып китеп булмый, өстемдә ак-

Фотолар авторныкы һәм Галина Середа архивыннан.

* Германиянең хәрби-һава көчләре

лы-каралы кием, полицайлар шунда ук атып утерәчәк. Совет кораллары тавышы якынрак ишетелә башлагач, поляк миңа хутордан бер күлмәк һәм ипи кисәге алып килеп бирде. Киемнәремне алыштырып, үле балалар арасына чокырда яшеренергә кушты. Мин төн җиткәнне көтеп яттым да урман аша үзебезнекеләр янына киттем... Котылуым могҗиза булды!

МОНДА МИН МӘХӘББӘТЕМНЕ ОЧРАТТЫМ

Казанга яшәргә күчкәч, мин монда полкташым табиб Али Хөсәенович Терегуловны очраттым, аның белән бер партизан отрядында булган идем. Ул миңа: «Галина, мединститутка барыгыз. Мин сезгә ярдәм итәм!», – дип киңәш итте. «Сез нәрсә? – дип кул селтәдем мин. – Аллаһ сакласын. Тагын кан, тагын газапланулар... башка боларны күрәсем килми!» дидем дә мин документларымны университетның мехматына тапшырдым.

Ул вакытта студентлар уртача, ләкин дус яшәде. Сугыш тәмам – иң мөһиме шул иде. Стипендия – 200 сум. Һәрвакыт бергәләп киногa (билет – 10 тиен), театрга (галеркага – 40 тиен) йөрдек, студент ашханәсендә һаман зур чәйнек белән кара ипи тутырылган кәрҗин тора иде. Туйганчы ашап була, бушлай!

Ял көннәрендә кызлар белән Горький паркына биергә йөгерә идек. Шунда мин мәхәббәтемне очраттым. Шулай итеп, Казанда калдым...

Укуны тәмамлагач, Юдинодагы мәктәпкә билгеләделәр. Анда якын-тирә авыллардан килеп укучылар күп иде. Сыйныфта – кырыгар бала. Ул вакытта, нигездә, 7 нче класска кадәр укып, заводка эшкә китәләр иде. Эшче һөнәре бик дәрәҗәле саналды.

Анда ике ел укытканнан соң, 122нче мәктәпкә күчтем. Пенсиягә кадәр шунда эшләдем. Бу һөнәрне сайлавыма мин беркайчан да үкенмәдем.

Укытучы булыр өчен балаларны яратырга кирәк – тыңлаучаннарын да, үзсүзлеләрен дә... Бөтенесен дә! Һәм алар, һичшиксез, шундый ук ярату белән җавап бирәчәк. Укытучы эше – зур җаваплылык ул. Үз-үзен тотышы, тышкы кыяфәте, сүзләре һәм кылган гамәлләре белән ул – балалар өчен үрнәк. Ул яхшы психолог булырга, балаларның эчке дөньясын да күрә белергә тиеш. Ни өчен күзләре яшьле, нинди борчуы бар, нишләп уку белән кызыксынмый башлаган, ни өчен агрессия яки битарафлык күрсәтә? Сәбәбен табарга кирәк... Әлбәттә, дәресләр кызык үтәргә тиеш. Мәсәлән, мин укучыларга әти-әниләре, аларның һөнәрләре турында инша язарга кушам. Аннары өй эше бирәм: балалар әти-әниләреннән математиканы ничек итеп үз эшләрендә кулланганнары турында белешеп килергә тиеш. Шул рәвешле мин математиканың, абстракт фән булмавын, көндәлек тормышта кулланылуын күрсәтәм. Укучылар математиканы бар өлкәдә дә бик кирәкле икәнен аңлап, тырышыбрак укый башлый.

БЕЗНЕ БОЛАРГА МӘКТӘПТӘ ӨЙРӘТТЕЛӘР!

Мәгариф реформасы турында бәхәсләрне күп ишетергә туры килә. Реформалар белем дәрәҗәсен яхшыртуга юнәлдерелгән булырга тиеш, аны гадиләштерү һәм төшерү турында сүз бармый. Шундый бер очрак искә төшә. Германиядән укучым Юра Зельманзон кайтты. Ул анда инде күптәннән яши, инженер-механик булып эшли. Немецлар техниканың нигә ватылганлыгын аңлап, компьютер программасы ярдәмендә исәпхисап ясаганчы, мин башымда тиз генә исәпләп, чишелеш тәкъдим итәм, дип сөйләде ул. Алар бик нык гаҗәпләнәләр. Ничек алай инде? Син гениймы, дип сорыйлар. Мин, юк, безне боларга мәктәптә өйрәттеләр, дип җавап бирәм, диде ул.

Билгеле булганча, фикерләү сәләтен шахмат һәм математика үстерә. Әгәр бөтен нәрсәне компьютерга йөкләсәң, баш мие үсүдән һәм эшләүдән туктый. Бу хәл Европа белән АКШта күзәтелә, ә без аларга охшарга тырышабыз, алардан өйрәнәбез. Компьютерга ышанып, үзебезнең мөмкинлекләрне онытып җибәрәбез. Башыбызда яхшырак шәхси компьютер бар бит!



Хезмәт кнәгәсе

Фамилия Середа

Исем Галина

Атасының исме Михайловна

Туган елы

Белеме: башлангыч, урта, югары (астына сызарга) высшее

Профессиясе (төп кәсебе) учитель

Хезмәт кнәгәсе иясенең имзасы

Хезмәт кнәгәсен тутыру көне

. . 19 е.

Редакция «Татарстан Республикасының Укытучылар газетасына» материалларны әзерләүдә күрсәткән ярдәме өчен рәхмәтен белдерә.

ГАЛСТУКЛЫ ӘЛФИЯ

Хәзерге мәктәп балалары пионервожатыйның кем икәнен дә белми. Ә без үскәндә мәктәптә бер чара да шушы кешедән башка узмый иде. Берәр чит мәктәпкә килсәң дә «пионервожатый апа»ны тиз танып аласың: муенында кызыл галстугы булыр. Биек үкчәле туфлиен киеп, кәс-кәс атлап, мәктәп коридорыннан узар. Аны һәр бала белә, якын итә. Ул иптәш тә, укытучы да...

Яңа уку елы башланган көннәрдә Арча районының атаклы пионервожатые белән очраштык. Хатирәләр яңартып, әлеге һөнәрнең үзенчәлекләре хакында сөйләштек.

Автор:
Руфия Фазылова

«УКУЧЫЛАРЫМ ӘБИ БУЛЫП БЕТТЕ...»

Әлфия Бәдретдинова гомер буе Яңа Кенәр урта мәктәбендә эшләгән. Быел җәй көне туксан яшен тутырган. Кул биреп исәнләшүгә, гаҗәпкә калдым: чигүле түбәтәй белән кызыл галстук бик килешле икән! (Әлфия апа шулай киенгән иде). Тәҗрибәле пионервожатыйның үзенә шулай дигән идем:

– Кызым, ак шәлем дә бар. Фотога төшерергә кирәк, дисәгез, бәйлим, – диде.

– Юк, кирәк түгел, ак шәл япкан ханымнарны бик еш күрәбез. Ә менә сезнеңчә киенгән әбиләрне беренче очратам, – дип шаяртткан булдым.

Әлфия апа яшь кызлар кебек кызарып куйды:

– Гомерем буена матур киенергә яраттым. Ак кофта, матур кара итәк, кызыл галстук – гел шулай йөрдем. Әле чәчләрне дә ясап куясың, кызыл галстукка пар итеп иренне дә кызартасың...

– Һәм кәс-кәс атлап мәктәп коридорыннан узасыз, – дим. (Ни өчендер нәкъ шулай күз алдына килде).

– Атлап түгел, очып йөри идем, кызым. «Бу Әлфия кайчан гына ял итә икән», – дия торган булганнар икән. Мәктәп белән ике арада йөреп, күп вакыт аяк өстеннән генә ашадым-эчтем. Әни: «Кызым, бу гөнаһларыңны кая куеп бетерерсең, утырып ашамыйсың да ич», – дип әйтә торган иде. И, шул вакытларны сагынам. Кайчагында үз-үземә: «Минме соң бу?!» – дип куям...

Әлфия апа сигез ел инде бердәнбер кызы Кадрия Хакимова тәрбиясендә яши икән. Яңа Кенәреннән күрше Югары Оры авылына алып килгәннәр. Гомер иткән нигезен, авылдашларын бик сагына.

– Бик яхшы тәрбиялиләр, тик авылымны уйламаган бер сәгатем дә юк. Күршеләремне бик юксынам. Күңелле, тату яшәдек без, – ди.

– Әни, күршеләрең исән түгел бит инде. Укытучы Миләүшә апа, Зәйнәп апа, Нәфисә апа да үлде, – дип сүзгә кушылды Кадрия апа.

– Беләм лә... Үлгән кешене дә сагынасың бит. Алар урынына башкалары бар. Үземнең укучыларым да әби булып йөри инде хәзер. Алар белән күрешеп, сөйләшеп утырыр идем. Әнә, җәй көне үз пионерларым Гөлфия, Сәрия, Фадия килгән иде бит. И, сөйләшеп утырырга рәхәт булды. Онытмаганнар, рәхмәт яугыры...

– Ә ни өчен Яңа Кенәрдән үзегезгә алып килдегез? – дим Кадрия апага.

– Сәламәтлеге күзгә күренеп начарланды. Күршедә генә яшәсәк, кереп-чыгып йөрер идем әле. Юк бит. Әнинең хәле ничек, дип, ут йотып торганчы, үзебезгә алып килик, дидек. Тәрбиядә яшәсен.

Кадрия Хакимова Югары Оры башлангыч мәктәбендә укытучы булып эшли.

– Әни кияүгә чыгып эти белән озак яшәмәгән. Мине, күкрәк баласын иярттеп, эти-әнисе янына – туган нигезенә кайткан. Мин шунда үстем, – диде Кадрия апа.

Фото: Лилиана Вәлитова



«ШАГЫЙРЬ БУЛА ЯЗДЫМ»

Әлфия апа өстәлдә яткан калын альбомны кулына алды. Хезмәт юлынданиләр булган, кая, кайчан барган, шулар турында бөтен мәгълүматны җыеп, теркәп, ябыштырып барган ул. (Иң күбесе – фотолар). Әлеге кадерле ядкарен безгә күрсәтергә дип әзерләп куйган икән.

– Монысы 1947 елда төшкән сурәт, – дип сүзен башлады, иркенләп утырышкач. – Казанда өлкән пионервожатыйлар курсында укып йөргән чак. Безне анда Сара апа Садыйкова үзе укытты. Атаклы биючеләр дә дәрескә керә иде…

Курсларны тәмамлаганнан соң, Әлфия апа Үрнәк сигезьеллык мәктәбендә пионервожатый булып эшли башлый. Һәм читтән торып Казан дәүләт педагогика институтының татар теле, әдәбияты факультетына укырга керә.

– Тик укытучы булып бер көн дә эшләмәдем, – диде Әлфия апа.

– Ник? – дим.

– Яңа Кенәрдә пионервожатый урыны бушагач, әти-әнигә якынрак булыйм, дип, туган нигезгә кайттым. Шулай итеп, үзем белем алган мәктәптә гомер буе эшләргә туры килде.

– Көндәлдә балаларга белем бирү хыялы калмадымы соң? – дим.

– Әлбәттә, башта укытасы килде. Ә аннан онытылды. Эшкә чумдым. Яңа Кенәр урта мәктәбе зур булганлыктан, район, республика күләмендә төрле чаралар еш кына бездә узды. Ул тематик кичәләр үткәрү, дисеңме… Мәхмүт Хөсәенов, Гариф Ахунов кебек язучылар, шагыйрьләр килгәндә, аларның әсәрләре буенча программа төзисең. Сыер савучы яки башка өлкәдә эшләүчеләр килсә, аларга бүтән программа әзерлисең. Шулай, шигырьләр эзли-эзли, укый-укый, үзем шагыйрь булып китә яздым.

Яңа Кенәрдә мәктәп кенә түгел, клуб та тирә-юньдәге авыллар арасында иң зурларыннан саналды. Шуңа күрә районга килгән кешеләрне иң беренче безгә җибәрделәр. Ә кеше килгәч, үзегез беләсез, якты йөз, такта чәй кирәк. Кая кушсалар, шунда чыптым. Кызымны карашырга әле ярый әти-әни бар иде…

Әлфия апа гомер юлын искә алканда, нык дулкынланды. Күзләре дә яшьләнде. Ә альбомда фотоларның саны юк. Аларның һәркайсында бер тарих ята. Менә – Артекка баргач төшкән фотосы. СССРның иң яхшы пионервожатыйлары арасында ул…

– Артекта биш-алты тапкыр булдым, – диде Әлфия апа.

– Юллама бирәләр идеме? – дим.

– Мин бит бөтен конкурсларда диярлек катнаштым. Җыннүләр дә яулый идем. Әнә шундый актив булганым өчен төрле бүләкләр бирәләр иде, шул исәптән Артекка юллама да. Иосиф Малкин – Татарстанда беренче булып пионер оешмасын төзегән кеше. Ул мине әллә каян танып, җилкәмнән кагып кына исәнләшә иде. Гел уйлыйм: пионервожатый булуым нәтиҗәсендә үз заманыбызның бик күп дәрәҗәле кешеләре белән аралаштым. Бу эш минем бәхеткә килеп чыккандыр.

Альбомны карауны дәвам итәбез. Бер сурәтне күргәч, Әлфия апа кош тоткан кебек елмаеп куйды:

– Бу – Казанда, украин халык биюе белән конкурста чыгыш ясыйм. Биергә бик яраттым, пионерларымны да өйрәттем. Ә менә украин биюен аеруча яратып башкара идем.

«ПИОНЕР ЯРДӘМЕ ЧИКЛӘРНЕ БЕЛМӘДЕ!»

Әлфия апа ишле гаиләдә үсә, җиде туган алар, ул үзе – өченчесе. Бөек Ватан сугышы башланганда, Әлфия апага 11 яшь була. Шул чорларны әңгәмәдәшем менә ничек искә алды:

– Сугышта берәүгә дә җиңел булмады, шул исәптән – балаларга да. Ачка шешендек. Нурания исемле зәңгәр күзле бик матур сеңлем бар иде, ул вафат булды. Ә иң олы апам Дания үзе теләп сугышка китте. Тагын ике кечкенә энем туган иде, алар исән-имин калды.

– Әтиегез дә сугышта идеме? – дим.

Әлфия апа сигез ел инде кызы Кадрия тәрбиясендә яши.

– Юк, сәламәтлеге буенча әтине сугышка алмадылар. Әтиләр дә ишле гаиләдә үскән, бик авыр тормышта яшәгәннәр. Бер бай, әтине йомышчы малай итеп сайлап, Троицк шәһәренә алып киткән. Күрәсең, ул бай мәрхәмәтле кеше булган: әтине укыткан. Заманына күрә бик башлы иде. Шуңа күрә сугыш вакытында колхозда эшләде, исәп-хисап эшен дә алып барды. Сугышка китмәгәненә бик борчыла, үзен гаепле хис итә иде.

– Ә Дания апагыз сугыштан кайттымы соң? – дим.

– Кайтты. Сугыш беткәч, быргы-барабаннар белән көн дә авыл башына чыгып, сугышчыларны каршы алдык. Алар, кайткач, авыл клубына җыелалар иде. Көтәбез, көтәбез, апабыз юк та юк. Ә ул, җаныем, яраланып, госпитальләрдә яткан. 1947 елда гына кайтты. Тәнендәге шул җәрәхәтләре белән 94 яшькә кадәр яшәде. Казанда, кызында үлде.

Әлфия апа белән иң кызык тема – шул чордагы пионер оешмаларының нәрсә эшләве, ничек яшәүләре турында сөйләшмәгәнбез бит. (Өлкән кеше истәлекләре белән бүлешкәндә, аны ничек бүлдерәсең, ди!)

– Әлфия апа, – дим, – гел «пионерларым» дип искә аласыз. Нәрсә эшли иде алар? Пионер тормышы турында сөйләгез әле.

– Барысын да эшлиләр иде. Авылның ялгыз картларына булышудан башлап, спорт, җырбию, яхшы уку – барысы да пионерның бурычы. Авылда яшәүче пионерларның эшенә тагын хезмәт тә өстәлде. Авыл җирлеге идарәсенә нинди план килә, шулкадәр сөяк, тимер, кәгазь җыеп тапшырдык. Иген уңышын күтәрү өчен көл тапшыру, башак җыю – барысы да пионерларның җилкәсендә иде. Эшләмәгән эш калмады безнең.

Пионерның тагын бер бурычы – газета-журналларга язылып, аларга күзәтү ясау. Мисал өчен, Әлфия апа үзе 15 союздаш республиканың газета-журналларын алдырган. Хәтта бүген дә аларның язылу квитанцияләрен саклый.

– Үзең үрнәк күрсәтмәсәң, ата-аналарны газета-журналларга яздыра алмыйсың, – ди әңгәмәдәшем. – Балаларда шул рәвешле уку культурасы тәрбияләдек. Мин мәктәптәге һәр укучы, һәр гаилә турында фикер әйтә ала идем: укуда ничек, эштә, өлкәннәргә мөнәсәбәттә һ.б. Пионерларым укытучыларына сөйләмәгән серләрен дә минем белән бүлеште.

Әлфия апа лаеклы ялга чыккач, мәктәптә пионер оешмасы озак яшәмәгән. Юк, ул эштән киткәнгә түгел, ә илдә барган сәясәткә бәйле рәвештә. Тәҗрибәле пионервожатый бүген дә шуңа уфтана, көенә:

– Пионер отрядлары булдыру СССРның иң зур казанышларыннан берсе булгандыр, мөгаен, – диде ул. – Пионерия бурычлары исәбенә үз иленңне ярату, өлкәннәргә хөрмәт белән карау, тырышып уку – бөтенесе дә кергән иде, чөнки пионер булу боларның барысын да колачлый. Менә шуны юкка чыгару – бик зур хата. Мин үземнең бер генә пионерым турында да начар сүз әйтә алмыйм. Алар, тормышта үз урыннарын табып, кеше булдылар.

...Әлфия апаның альбомында: «Пионер ярдәме чикләрне белмәде» дип язылган сүзләрне укыган идем. Канатлы сүз буларак кулланылган әлеге җөмлә, чынлап та, пионерларның бөтен эшен ачып бирәдер кебек тоелды. Хәзерге балалар Әлфия апа кебек пионервожатыйларны күрми, кызыл галстук такмый, «Пионер анты» кабул итми... Бүген аларның барысын да Интернет, төрле гаджетлар алыштырды. Шуларны уйлап, аңлап, кызганыч булып китте.

БЕЛЕШМӘ

Пионер «беренче» дигәнне аңлата. Пионерлар – киләчәккә юл яручылар, курку белми, алдан баручылар, дип тә әйткәннәр. Владимир Ильич Ленин исемендәге Бөтенсоюз пионер оешмасы 1922 елның 19 маенда төзелә. Пионер сафларында чыныгу үткән яшьләр соңрак комсомолга кабул ителә.

www.protatarstan.ru
Поиск...
Подписка!
РУС | ТАТ
ТАТАРСТАН
Иҗтимагый-сәяси басма
Әһәмиятле
Игелекле
Мәңгелек
Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
23 сентября 2019
20 сентября 2019
19 сентября 2019
Гаделлек тантанасы
Каһарманнарыбыз
Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари: милләтнең рух сагында
Тарихи сәхифә
Үз арабыздан чыккан маһир рәссам
Кече ватан патриотлары. Рәссам Харис Якупов
Реклама 16+

«ИСӘНМЕСЕЗ!» БЕЛӘН ГЕНӘ ЧИКЛӘНМӘСЕННӘР!

Уеннан уймак чыкмый! Казан шәһәренең 116 нчы лицеенда татар теле һәм әдәбияты укыткан Зилә Габдинова шулай дип ышандыра. Рус телле балаларны татар теле серләренә төшендерүдә нәкъ менә уен формасына өстенлек бирә ул. Татар телен тагын нинди ысуллар ярдәмендә үтемле итеп өйрәтеп була? Кайсы методология нәтиҗәле эшли? Ике дистә гомерен ана телен укытуга багышлаган тәҗрибәле мөгаллим белән әнә шул хакта сөйләштек.



Автор:
Илсөяр
Ибраһимова

– Зилә Әфтәховна, бүген күпләр татар телен укыту методикасының катлаулы булуыннан зарлана. «Баланы авыр грамматика укытып биздергәнче, татар телендә сөйләшергә өйрәтергә кирәк», – дигән фикерне дә еш ишетергә туры килә. Бу фикер белән килешәсезме?

– Мин элек-электән дәресне укучылар өчен ничек кызыграк итәргә икән дип баш вата идем. Укучы дәресеңә яратып йөрсен, телне өйрәнсен өчен нишләргә? Укыту программасы авыр итеп төзелгән, дәреслекләр шулай ук бик катлаулы… Шуңа күрә мин беркайчан да программага гына таянмадым. Дәреслекләр буенча гына да эшләмим. Мин Максимов, Фәтхуллова, Хәйдәрова кебек методика авторларының һәркайсыннан кызыклырак алымнарын алып, үземнекен өстәп, балаларны иң элек татар телендә сөйләшергә өйрәтергә тырышам. Күп кенә укытучылар дәреслеккә карап, һәр ноктасына кадәр эшләтеп, балаларны телдән биздерә. Катлаулы грамматиканы аңламагач, балага тел өйрәнү кызык түгел.

– Шулай да искә алган методикалар арасында кайсысын иң отышлысы дип саныйсыз?

– Әңгәмә, уен формасы, Максимовның структуралары, сөйләм калыплары, Хәйдәрованың төрле-төрле ситуацияләр бирү алымы – боларның һәркайсын кулланам. Әлеге методика авторлары минем дәресләргә дә килеп йөри иде. Алар белән бергә дәрес планнары төзедек, эшләдек. Галимнәр бу бурычларның ничек үтәлгәнен үзләре килеп карый, балаларны сөйләштерә иде. Яшерен-батырын түгел, укучылар белән килешеп, алдан әзерләнгән дәресләр дә була. Әнә шундый очрак түгелме икән, дип тикшерер өчен, балаларга үзләре дә сораулар биреп карыйлар иде. Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы тәкъдиме белән өч ел элек безне Валерия Мещерякова укытты. Инглиз теле буенча Россия күләмендә семинарлар үткәргән галим бу. Әнә шул инглиз теленә өйрәтү методикасын татар теленә карата да кулланган ул. Үзе камилләштергән әйбәт система килеп чыккан. Дәрес энәсеннән-җебенә кадәр язылган. Монда бернәрсә дә уйлап утырырга кирәкми. Нинди уенчык алырга, нинди сүз әйтергә – барысы

Фото: Александр Ефремов

да билгеле. Бер дәрес, бер уен икенчесенә бәйләнеп китә. Балаларны ул өйрәткәнчә укыта башладык. Дәресләребезне видеога төшереп җибәреп, ул аларны карый, тикшерә, хаталарны әйтә иде. Дәрес гел уеннардан тора. Бу системага шулкадәр яратып кереп киттек. Балалар да, ата-аналар да бик канәгать калды. Бу аңлашыла да, укучылар дәрестә катлаулы грамматика гына өйрәнеп утырмый, рәхәтләнеп татар телендә аралаша. Ата-аналар да: «Күптән шулай укытасыгыз калган», – ди иде. Уен формасындагы дәрес бик күп әзерлек сораса да, балалар анда телне теләп һәм җайлы итеп өйрәнәләр. Бу дәрестән дә нәтиҗә бирә торган методика. Уен барышында бер сүзне төрле структурада кабатлыйлар. Әйтик, шул ук зат килешләрен генә алыйк. Уен барышында укучы: минем чәчем матур, синең чәчең матур, аның чәче матур кебек җөмләләрне кабатлый-кабатлый, килешләрне дә отып бетерә. Шәһәр баласына моны китаптан укып кына аңлатуы кыен. Мондый дәресләрдә укытучыга да гел сөйләп торырга кирәк.

– Татар теле тирәсендә бәхәсләр куерган чорда да шушы уен алымы турында бик күп фикерләр яңгырады. Кайбер белгечләр: «Татар телен уен рәвешендә генә укыту дөрес түгел, аны башка телләр кебек үк тирәнтен өйрәтергә, бөтен кагыйдәсенә төшендерергә кирәк» – дип белдерде...

– Андый катлаулы ысул белән ничә еллар дәвамында тел өйрәтеп карадык бит инде. Татар теленнән, киресенчә, биздереп кенә бетердек. Уен формасы барыбер үзен аклый. Телгә өйрәтсәң, башлангыч сыйныфларда өйрәтеп каласың. Бу чорда бала телне тулысынча сеңдерә. Бишенче класстан соң исә ул инде телне авыррак үзләштерә башлый. Гадәттә, дәрестә 14 уен үткәрәм. Бер уенга уртача 2–3 минут вакыт туры килә. Шуннан да күбрәк уйнаса, бала туя башлый. Шуңа күрә аңа тиз арада икенчесенә күчәргә кирәк. Шулай бер уеннан икенчесенә күчә-күчә дәрес үтә дә китә. Балалар: «Бүгенгә беттедәмени?», – дип күңелсезләнеп утыралар.

– Сез эшли башлаган чор укытучы һөнәренең дә, татар теленең дә шактый популяр чорына туры килгән. Шушы вакытлар сагындырамы? Әллә инде яңа технологияләр, мөмкинлекләргә бай булган хәзерге заман шартларында эшләргә җиңелрәкме?

– Ул чорда эшләве күпкә җайлырак иде, чөнки ул вакытта татар теленең кирәклеге сизелеп торды. Балалар да тел белү кирәк дип, теләп, тырышып укыйлар иде. Ул чорда ата-аналар да татар телен укытуга бик җитди карады. Хәзер, әлбәттә, мөмкинлекләр күп. Ләкин балаларда да, ата-аналарда татар телен өйрәнү, өйрәтү теләге кимеде. Хәзер аларга татар теленең нигә кирәк икәнен ешрак аңлатырга туры килә. Татар балалары өчен туган тел булса, рус телле балалар өчен ул – дәүләт теле. Җәмәгать урыннарында аралашканда, мәдәни чараларда, гомумән, янәшәңдә синең белән бергә гомер кичерүче халыкның телен, тел аркылы аның гореф-гадәтләрен белү замана кешесенә рухи байлык өсти, дип саныйм мин.

– Соңгы елларда татар теле тирәсендә шушындый катлаулы вазгыять килеп туунын төп сәбәбен нидән күрәсез?

– Беренчедән, бу эш дәүләт дәрәҗәсендә куелмаган. Әйткәнемчә, 90нчы елларда телгә карата булган кызыксыну белән бүгенге кызыксыну шактый нык аерыла. Телнең киләчәктә ни дәрәҗәдә кирәк булачагына фаразлар буенча, әлбәттә. Кирәк булмагач, аңа уку сәгате бүлүне дә кирәк тапмыйлар, билгеле. Аннан шунысы да бар: ничә еллар дәвамында атнасына 4–5 сәгать татар теле дәресе укып, балалар татарча тиешле дәрәҗәдә сөйләшергә өйрәнмәде. Күп балалар мәктәптән татар телен белми чыга. Ата-аналарның төп дәгъвасы да шул. «Грамматиканы өйрәнеп утырып, сөйләшергә өйрәнә алмады», – диләр.

– Зилә Әфтәховна, сез татар теле һәм әдәбияты укытучыларының бөтенроссия съездында: «Безнең буынга, бәлки, татар теленә яңа сулыш өрү вазыйфасы йөкләнгәндер», – дигән идегез. Яңа сулыш дигәндә, нәрсәне күздә тотасыз? Татар телен ничек популярлаштырырга?

– Беренчедән, кеше күп җыела торган җәмәгать урыннарында татар телендәге язулар күбрәк булсын иде. Барлык татарлар да, оялмыйча, горурланып үз телендә сөйләшсен иде. Мисал өчен, минем тормыш иптәшем Айдар (Айдар Габдинов – Татарстанның атказанган артисты, – Ред.), русча ничек кенә яхшы сөйләшсә дә, җәмәгать урыннарында гел татарча гына аралаша. Татар телендә әйткән сүзен аңларга тырышып басып торган рус кешесе белән дә тегесе аңлаганчы барыбер татар телендә сөйләшә ул. Безнең өйдә кагыйдә шундый: өйдә фәкать татар телендә генә сөйләшәбез. Шуңа күрә яңа сулыш дигәндә, әнә шулай гаиләдә ата-ана тарафыннан туган телгә мәхәббәт, хөрмәт хисе тәрбияләүне дә күздә тотуым. Укытучыдан да күп нәрсә тора. Дәресен мавыктыргыч, кызыклы итеп оештырса, укучы аның дәресенә яратып йөреп кенә калмыйча, телне дә җиренә җиткереп өйрәнәчәк. Аннары бүген төрле чараларда ясалган чыгышларның да нигедә рус телендә булуы күңелгә тия. «Исәнмесез!» дип башлыйлар да рус телендә сөйләргә тотыналар. Түрәләргә ике дәүләт телен дә тигез дәрәҗәдә белгән, кулланган өчен өстәмә эш хакы түләүне дә кире кайтарыр идем. 90нчы елларда бик нәтиҗәле эшли иде бу кагыйдә. Искиткеч зур стимул булыр иде ул. Элек түрәләр хәтта репетитор яллап татар телен өйрәнә иде. Үземнең дә икеөч кешегә дәрес биргәнем булды. Беркем дә татарча сөйләшмәгез, татар сүзләрен бөтенләй кулланмагыз, дип мылтык тотып тормый бит. Барысы да үзебездән генә тора!

ТАТАРСТАННЫҢ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЫННАН *азәрбайҗанча пылау*

«Татарстан»ның редакция кухнясында» бүген тәмле ризык кына түгел, мәдәни программа да әзерләнә. Башкача булуы мөмкин дә түгел, чөнки бүген кулинария бәйрәмен Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова үзе оештыра бит!

Автор:
Татьяна Вафина

ПЫЛАУ ТӨРЛЕ БУЛА

– Мин үзем Бакудан, шунлыктан традицион әзәрбәйҗан ризыгы – сарык ите белән дөге пешерәчәкмен. Бу классик үзбәк пылавы түгел, шуңа безгә кишер бөтенләй кирәкми! Мондый ризыкны минем әнием, әниемнең әнисе, аның әбисе – кыскасы, җиденче буынга кадәр әбиләремнең барысы да әзерләгән. Безнең гаиләдә аны бик яраталар – ул үзе гади, үзе тәмле һәм туклыклы.

Азәрбайҗанда берничә төрле пылау пешерәләр, тик аларның барысында да дөге иттән аерым әзерләнә. Дөгегә төрле ингредиентлар – бүгенге кебек ит яки кайвакыт баллы җиләк-җимеш өстәлергә мөмкин. Азәрбайҗанда майда кыздырылган кипкән җимешләр белән дөгене дә еш пешерәләр, ул бик баллы һәм тәмле була. Бу ризыкны тавык белән дә, балык белән дә әзерләргә мөмкин... Минем кызым, мәсәлән, дөгене махсус кыздырма (азәрбайҗанча ул «газмах» дип атала) белән ашарга ярата, ул ахырдан кыек шакмаклап киселә һәм ризыкның өстенә куеп бирелә. Бүген сез газмахның ничек ясалганын күрерсез.

Иттән башлыйбыз. Сарык итен кинза белән томалап пешерәбез. Күп кеше сарык итенең тәмен яратмый, кинза исә аны нейтральләштерә. Итне шактый эре кисәкләргә турыйбыз – пешкәч тә авызда сизелерлек булсын. Аннары майсыз кәстрүлдә пешерәбез, чөнки сарык ите болай да майлы, һәм аннан бүленеп чыккан шулпа да бик тәмле.

СЫЙ ӘЗЕРЛӘҮ – СИРӘК ЭЛӘГҮЧӘН ЛӘЗЗӘТ

– Ирада Хафизҗановна, министр кешенең пешеренергә вакыты каламы соң?

– Минем өчен ашарга пешерү – мәҗбүри бурыч түгел, бик сирәк эләгә торган рәхәт ләззәт кенә. Мин үзем ирләр күпкә тәмлерәк пешерә дип саныйм. Ирләр гомумән бар нәрсәне дә остарак эшли. Әлбәттә, эшләмичә өйдә утырган хуҗабикәләр төрле ризык әзерлидер. Әмма, плитә янында кем генә басып тормасын, иң мөһиме – ул ризыкны күңелен биреп пешерергә тиеш, шул вакытта гына сый тәмле була.

Боларны сөйләгән арада Ирада Хафизҗановна әллә ничә баш зур суганны божралап һәм ярымбожралап туравын дәвам итте. Үзен яратып тураганны сизгән суган да пешерүчене елатмый, күз яшьләрен агызмый икән. Бөтен суганны турап бетергәнче министрның матур күзләреннән бер генә яшь тә таммады шуңа күрә!

Фото: Ната Смирнова

то,что
ТАТАРСТАН
СПУТНИК
ТАТАРСТАН
ЖИЗНЬ
ЛЕНИНА
ТАТАРСТАН
ВЕСТНИК
НИКИТА

Безгә кирәк булачак:

- 1 кг сарык ите
- 1 кг суган
- 1 кг озын бөртекле дөге
- 2 бәйләм кинза
- 4 данә йомырка
- 200 г атланмай
- Тәменчә тоз, борыч

– Суган никадәр күбрәк булса, шулкадәр яхшырак, – дип аңлата министр. Һәм менә инде кәстрүлдәге ит өеме суган тавы астында күмелде дә. Чиратта – ике бәйләм кинза. Министрның үткен пычагы аларны да хуш исле яшел өемгә әйләндерергә тиеш.

Тик кинза әлегә көтеп торсын, без исә мәдәни программага күчик.

МӘДӘНИ ПРОГРАММА

– Казан үзенең шактый җете мәдәни тормышы белән горурлана ала. Әмма, мәгълүм булганча, камиллекнең чиге юк. Татарстанның мәдәният министры сыйфатында сез аңа нинди яңа төсмерләр өстәүне планлаштырасыз?

– Әгәр без казанлыларны гаҗәпләндерерлек мәдәни вакыйгаларны күз алдында тотабыз икән, мин бүген бары тик интерактив белән генә шаккатырып була дип саныйм. Иң зур теләгем – әлеге чараларга кеше күзәтче сыйфатында гына килмәсен иде. Концертны бит өйдә телевизордан да карап була. Аның эчтәлеге тамашачының күңелен кузгатсын, ул анда үзе дә катнашсын һәм хәтта үзе оештырышсын да иде.

– Сез моны ничек күз алдыгызга китерәсез?

– Үзләрен иҗатта тапкан кешеләр бәхетле ул. Иҗатны исә бөтен җирдә – китапханәдә дә, ресторанда да, һәм хәтта чәчтарашханәдә дә кулланырга мөмкин. Менә минем ял итүче бер коллегам чәчтарашханәгә баласының чәчен кистерергә барган һәм анда китапханә булуын күреп таң калган, миңа шуны язып та җибәрде. Мәсәлән, хәзер рестораннарда, мәдәни процесска җәлеп итү өчен, рәсем ясау буенча мастер-класслар оештыралар. Ни өчен караоке-барлар популяр? Чөнки кешенең үзенең җырлыйсы килә. Рәсем ясыйсы, иҗат итәсе. Мәдәни чараларда үзе катнашкан кеше әлеге темпларга чыдауның никадәр авыр икәнен үз җилкәсендә татый һәм профессионалларны күбрәк хөрмәт итә башлый.

АЕРЫМ ТӨБӘКЛӘРНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

– Сез күп сәяхәт итәсез. Дөньяның кайсы шәһәре сезгә мәдәни кыйммәтләрне саклауда үрнәк булып күренде?

– Һәр шәһәр, районның – барлык территорияләрнең үз үзенчәлекләре бар. – Ирада Хафизҗановна бу вакытта дөгене юа һәм аның бик яхшысы, һәр бөртеге бөтен булганы әләккәненә сөенә... – Бары тик боларны күрә белергә һәм теге яки бу территориянең мәдәниятендә нәрсәнең өстенлекле булуын яхшы аңларга кирәк. Һәм сәфәргә алдан әзерләнү мөһим. Үземнең сәяхәткә әзер булуымны яратам. Барып төшкәч, кайбер урыннарны таныйм – чөнки бу шәһәр турында алдан ук күп укыган булам. Мәдәният ул – музей, театр, күргәзмәләр генә түгел бит. Ул әле төрле ризыклар да. Безнең милли ризыкларыбыз – чәкчәк, бәлеш, өчпочмак аша Татарстаныбызда хәтта гаиләдә дә мәдәни кыйммәтләребезне саклау мөмкинлеге булу бик шәп бит...

Миңа Франция провинцияләрендәге үзара мөнәсәбәтләр культурасын саклау бик ошый. Анда халыклар мәдәниятенең бөтен палитрасын күзәтеп була, бу Парижны барып күрүгә караганда күпкә кызыклырак.

Европада ял итү бик кыйммәт санала. Әмма арзанга да рәхәтләнеп ял итеп була бит. Биш йолдызлы кунакханәгә урнашмыйча, хостелда яшәсәң, акция буенча арзанлы самолетлар таба белсәң... Әле тагын коучинг-система да бар: алданрак кем белән булса да хат алышасың һәм шул кешегә барып урнашасың. Тагын да кызыклырак сәяхәт килеп чыга. Чөнки дөньяны шул илнең төп халкы күзлегеннән күрәсең. Мәдәният ул кешеләрдә яши. Син алар белән аралашмыйсың һәм аларның көнкүреше ничек оештырылганын белмисең икән, бу халыкның мәдәниятен, аның гасырлар буе ничек формалашуын аңлау кыен.

ТАТАРСТАНДА МӘДӘНИЯТ НИЧЕК ҮСКӘН

– Ә без аны ничек формалаштырганбыз? Менә тиздән исикткеч юбилейны – ТАССР төзелүгә 100 ел тулуны зурлап билгеләп үтәчәкбез. Сез Дәүләт архивында эшләдегез һәм республикабыз тарихын яхшы беләсез. Бу елларда Татарстанда мәдәният ничек формалашкан, шуңа кыскача гына күзәтү ясый аласызмы? Ниндидер төп вакыйгалар, мөһим документлар һәм вакыйгалар... Татарстанның мәдәнияте хәзер нинди дәрәҗәдә?

– Безнең республикага турыдантуры мөнәсәбәтле өч дата бар: 1920 елның 27 маенда автономия оешу турында документ алу; 1920 елның 25 июнендә әлеге документны халыкның кабул итүе, аның республика территориясендә гамәлгә керүе; 1990 елның 30 августында республикабызга суверенлыкның кире кайтарылуы.

Хәзер үткәннәргә кагылышлы иллюзияләр күп, барысы да бу ниндидер фейк булган, көтмәгәндә революция ясалган, дип саный. Алай түгел! Милли мәсьәлә бик четерекле. Яңа хакимият нәрсә бирә? ТАССР оешуның башы – милли элиталар булдыруның формалашуы ул. XX гасыр башының этнографик картасын карасак, 1920 елны, сез бу вакытта татарларның нигездә авылларда яшәвен күрерсез. Казан университетында кем укыган? Анда татарлар бик аз булган. Шунлыктан максатчан сәясәт алып барылган – милли элита булдырылган: табиблар, тарихчылар, педагоглар. Музыкантларга, театр сәнгатенә булышлык күрсәтелгән. Театр культурасын авылларга илтеп җиткерү өчен, Тинчурин театры махсус күчмә итеп оештырылган. Дәүләт җыр һәм бию ансамбле дә, филармония дә, Язучылар берлеге дә, Композиторлар берлеге дә 30 нчы елларда төзелгән... Милли сәнгатьне күтәрү җәһәтеннән әлеге йөз еллык дәвер бик күп нәрсә биргән.

30 нчы елларда репрессияләр башлангач, ТАССР бу чорны да ил

Paprika
Редакция «Паприка» кулинария студиясенә рәхмәтен белдерә.
8-937-776-33-28,
paprika_kazan@mail.ru,
Казан шәһәре,
Бауман ур., 44/8 йорты.
Реклама

белән бергә кичерә. Без менә быел Шәриф Камалның музей-фатирын ачтык. Шәриф Камал әдип кенә түгел, ул гуманизм символы да булып тора. Кәрим Тинчурин, Кави Нәҗмиләр репрессияләнгәндә, Шәриф Камал каләмдәш дусларының гаепсез булуын дәлилләргә тырышкан, үзенә кыенлык килүдән курыкмаган. Заһидә ханым белән каләм әһелләре аралашмый башлаган бер чорда Тинчуринның хатыны янына килеп, хәлләрен сорашудан тайчанмаган. Һәм безнең тарихта мондый шәхесләр күп.

Мин республикабыз халкының, үз гаилә бюджетын планлаштырганда, рухи азыкның да матди азык кебек үк мөһим булуын аңлавын телим. Петербургтагы кебек булсын иде ул. Россиянең гомуми культурасы күзлегеннән караганда бу шәһәр үрнәк булып тора. Гаилә ялын оештырганда мәдәнияткә зур урын бирелүе петербурглылар өчен норма санала. Бу – без омтылырга тиешле дәрәҗә. Мин кешеләр китапханә, музей, театрларга кабат күпләп йөри башласын иде, дип хыялланам.

– Хыялыгызны ничек тормышка ашырырга җыенасыз?

ҮСЕШ АГЕНТЛАРЫ

– Без 1 июльдән балаларны музейларга бушлай кертә башладык. Әлбәттә, бу үзенә бер төрле сынау, чөнки хәзерге балалар бөтән төрле бит. Алар медиаконтентның даими алмашынуына күнеккән. Алар инде өч яшеннән үк гаджетлардан файдалана белә. Алар тиз рефлексиягә күнеккән. Мондый балаларның өметләрен ничек акларга?

– Чыннан да, ничек?

– Бала үсеш агенты була ала. Без балалар өчен кызыклы булырга тиеш. Әгәр без аларны кызыктырсак, балалар әти-әниләрен дә үзләренә ияртәчәк. Чөнки ата-ана үз баласыннан калышмаска омтылачак. Мәдәниятне модага кертергә кирәк, ата-ана шуны аңласын: баланы спорт секциясенә генә йөртү түгел, беренче чиратта, аның гармонияле үсеше өчен тырышу мөһим. Мәдәнияттә дә бит, спорттагы кебек үк, һөнәрне яшьтән сайларга кирәк. Спортта үз өлкәңнең остасы булыр өчен, футбол секциясенә, гимнастикага яки хоккейга 4–5 яшьтән йөри башлау зарур. Бала сәхнәдә профессионал булсын өчен, аңа, мәсәлән, хореография белән дә 4 яшьтән шөгыльләнә башларга кирәк. Ә инде музыкант булырга теләсә, шул яшьтән үк музыканы ишетергә өйрәнү мөһим.

Әмма тагын шунысын аңлау да зарур: балачактан музыка, җырлау белән шөгыльләнгән һәр кеше дә һичшиксез сәхнәгә чыгарга тиеш, дигән сүз түгел. Юрий Коротковның бик кызыклы «Виллисы» (в русском тексте неправильное название – Вилиссы) романы бар. Анда балериналар әзерләүдәге рәхимсезлекләр сурәтләнә һәм гомерен шул һөнәргә багышларга теләүче кызларның үзләрен куркыныч астына куюы турында сөйләнә. Без бит бала белән 12, 15 яшендә ниләр буласын фаразлый алмыйбыз. Ул тазарып китәргә, яки буйга үсәргә мөмкин, балет өчен кирәкле пропорцияләр сакланмау ихтималы бар. Шунлыктан, ата-ана баласын музыка яки сәнгать мәктәбенә бирә икән, сабыйларының супердаһи булу ихтималының 50 гә 50 генә икәнен яхшы аңласыннар иде. Әмма бу мөмкинлектән алар барыбер файдаланырга тиеш. Чөнки талантны ачу үзе үк зур бәхет ул.

ДӨНЬЯНЫ ТАНЫП БЕЛҮДӘН КУРЫКМАГЫЗ

– Күптән түгел караган нинди чара (яки укылган китап) сезне таң калдырды һәм илһамландырды?

– Күптән түгел «Тайна трёх государей» бестселлерын укыдым. Миңа эзотерика ошый, миңа безне шәхес буларак үстергән, фикерләү чикләрен киңәйткән бөтен нәрсә ошый. Хәзер мин япон авторларын укыйм – аларның символизмы җәлеп итә. Мережковскийның «Христос и Антихрист» трилогиясен уку бик тетрәндерде. Анда өч сюжет, һәм алар нәкъ менә мәдәни кыйммәтләрнең трансформациясе хакында. Трилогиянең Петр I улы Алексей белән үзара мөнәсәбәтләре турындагы соңгы өлеше бераз күңелне кайтарды. Бу китапка бәйле кызыклы вакыйга булды... Мин аны укыганда Германиядә стажировкада идем. Без Ольденбург шәһәре аша үттек – әлеге территория Алексейның хатыны София бирнәсе сыйфатында рус җирләре казнасына кушылган. Һәм мин нәкъ менә шул шәһәргә килеп җиткәндә нәкъ менә аның турында укыйм икән бит! Тормышта шундый могҗизалы хәлләр дә була. Иң мөһиме – үзеңне кысаларга куып кертмәү, үзең өчен чикләүләр куймау. Әгәр син укырга яратасың икән, бу синең спорттан, хореографиядән һ.б. тулысынча баш тартуыңны аңлатмый бит. Мин гармония турында сөйлим. Бер урында катып калырга ярамый. Бу үсешне туктата. Дөньяны танып белүдән курыкмаска кирәк.

УЛ РОССИЯ ДӘ, АНДАГЫ МИН ДӘ ЮК ИНДЕ...

– Татарстанда «Мәдәният» милли проекты ничек гамәлгә кертелә? »Иҗади кешеләр» төбәк проектында халыкның иҗат потенциалын тормышка ашыру өчен нинди шартлар тудырыла?

– Милли проект өч өлештән тора: мәдәни мохит, иҗади кешеләр, цифралы мәдәният. Минемчә, милли проектта иң мөһиме – иҗат кешеләре. Чөнки цифралы мәдәният һәм уңайлы инфраструктура никадәр генә әһәмиятле булмасын, нәкъ менә кешеләр мөһим – бөтен нәрсә алар тирәсендә укмашырга тиеш, алар оештырачак, кызыктырачак һәм үзләре артыннан ияртәчәк. Мондый кешеләр булмаганда клуб – нибары яңа матур бина гына. Инфраструктура исә аралашу мәйданчыгы сыйфатында булырга тиеш. Әмма... Цветаеваны хәтерлисезме: «Той России нету, как и той меня». Мәгънәсе мондый: безнең гомер – бара торган юлыбыз гына түгел ул, бәлки безне бу юлда озата баручы кешеләр дә. Мәдәният учреждениеләрендә харизмалы шәхес эшләргә тиеш. Әгәр мәйданчыкны җете мәдәни вакыйгаларга баетмыйсың икән, аны һәркем өчен уңайлы итмисең икән, буш клубның беркемгә дә кирәге дә, кызыгы да юк. Шунлыктан иҗади кешеләрне

PRESSA

Ирада Әюповадан аш-су киңәше:

– Тазмах әзерләү өчен, пешкән дөгегә чи йомырка кушып болгатыгыз да, сары май белән майланган кәстрүл төбенә җәегез, алтынсу төскә кергәнче кыздырыгыз. Тазмах әзер!

табу һәм аларга булышу – безнең тармакны үстерә торган иң мөһим нәрсә. Моның өчен грантлар, коммерциячел булмаган оешмалар эше, волонтерлык проектлары кирәк – алар мәдәният-ял учреждениеләре территориясендә гамәлгә кертелергә тиеш тә инде. Милли проектта клуб җитәкчеләре, хореограф, режиссерларның белемен яңартуны күздә тоткан тулы бер юнәлеш бар. Мин, иң мөһиме – кешегә инвестицияләү, дип саныйм.

ТАЛАНТНЫ АКЧАЛАТА БӘҺАЛӘҮ КЫЕН

– «Татарстан» журналы Инстаграмында әледән-әле блогерлар арасында төрле сораштырулар үткәрелә. Күптән түгел артистлар, җырчылар, музыкантлар үзләренең иҗатташлары арасыннан иң актив кешене сайлады. Анлары без финалга узучыларның барысын да җыйдык та, кечкенә генә блиц-сораштыру үткәрдек. Сорауларның берсе мондый иде: мәдәният министры булсагыз, нәрсә эшләр идегез? Блогерлар бертавыштан, иң беренче эш итеп, барлык мәдәният хезмәткәрләренең эш хакын арттырыр идем, дип җавап бирде. Хезмәт хакы шулай азмыни?

– Мин бөтен хикмәт акчада гына дип уйламыйм. Әгәр сез дөнья мәдәнияте тарихына күз салсагыз, барлык иҗат әһелләренең дә тук, бәхетле һәм канәгать булмавын күрерсез. Иҗат – тормыш зарурлыгы ул. Артист сәхнәгә акча өчен генә чыга икән, моны тамашачы бик тиз сизә. Ни өчен бүген «Безнең заман» фестивале безнең артистларның чын көндәше булып тора? Бу балалар чын профессионаллар түгел бит, тик алар тамашачыны үзенең энергиясе белән әсир итә. Алла Пугачева турындагы «Женщина, которая поет» дигән фильмны хәтерлисезме? Ул әлеге җырчының җырламый яши алмавы турында. Мондый җырлау теләген сатып алу мөмкин түгел, ул – сулау кебек. Мондый кешеләр өчен тормыш – иҗат ул. Бездә мондый кешеләр бик күп. Бөтен нәрсәне дә акчага гына кайтарып калдырырга ярамый. Әлбәттә, акчасыз артистка кыен. Тик артист булмаган кешегә дә акчасыз кыен бит. Бу шоу-бизнес, ул акчага башка бөтен һөнәрләрдән дә күбрәк бәйле. Тамашачының сәхнәдән гүзәллек, эстетика күрәсе килә. Ә менә Европада, мәсәлән, сәнгатькә минимализм хас. Анда бездәге кебек җете декорацияләргә ихтыяҗ юк. Кара кабинетта, кара трико һәм майкадан гына да рольне искиткеч итеп уйнап була. Шулай ук кыйбатлы костюм киеп, иң әйбәт, кыйммәтле микрофонга да бик начар җырлап була, аңлыйсызмы шуны? Талантны акчалата бәһаләү бик кыен. Гомумән, мәдәниятне акча эшләү мохите дип уйлау – ялгыш фикер. Һәм, тамашачы килми икән, димәк, бу берәүгә дә кирәк түгел, дип уйлау да тагын бер ялгыш фикер. Профессиональ сәнгатьтә, әгәр кеше чыннан да даһи икән, ул һәрвакыт заманнан алдарак бара. Бары тик тамашачы зәвыгына гына яраклашырга тырышу – дөрес түгел. Барыбыз да хәтәр 90 нчы елларны хәтерли әле: пәрдәләр ачылгач, цензурасыз «сәнгать» сәхнәне басты... Мин цензурага каршы, тик мин сәхнәдә көч куллану, сүгенүгә дә каршы. Мин зәвыксызлыкка, рухи шакшылыкка, безне начаррак кешегә әйләндерә торган һәрнәрсәгә каршы.

КИРЕ КАКСАҢ – ТӘКЪДИМ ИТ!

– Димәк, мәдәнияттә цензура кирәк түгел?

– Цензура белән тәнкыйтьне бутарга кирәкми. Цензура иҗат-

1. Турыйбыз!

2. Ваклыйбыз!

3. Пешерәбез!

4. Болгатабыз!

5. Өстибез!

6. Сөзәбез!

7. Өстибез!



8. Кыздырабыз!

9. Бүләбез!

10. Алабыз!

ка аяк чала, тәнкыйть исә булыша. Мин бик еш Сталин белән булган хәл турында искә алырга яратам: аның янына Совет язучылар берлеге өстеннән шикаять белән килгәч, юлбашчы: «Минем бит башка язучыларым юк», – дигән. Каләмдәшләре өстеннән әләк язучының дәрәҗәсен төшерә торган булалар. Һәм шунлыктан, ул башкаларга яла якмыйча булдыра да алмый, тәнкыйтьне дөрес кабул итми торган булган. Ә бит үзеңә ошамаган нәрсәләрне дә ишетә белү зарур. Алай гына да түгел, сиңа «юк» дип әйтә алучыларга таянырга кирәк. Әгәр сине башыңнан сыйпаучыларга гына таянасың икән, һәлакәт буласын көт тә тор. Тәнкыйтьне кабул итми башлау белән, үсеш туктала. Әмма тәнкыйть конструктив булырга, булганга һәрвакыт алмаш вариант тәкъдим ителергә тиеш. Кире кагасың икән – тәкъдим дә ит! Әгәр син, бернәрсәне дә аңлатмыйча, бөтен нәрсәдән зарланасың һәм барысын да тәнкыйтьлисең икән, бу бары тик критиканлык кына, һәм аның бернинди файдасы да юк.

ЭМОЦИОНАЛЬ ТРЕНАЖЕР

– Тамашачы бик еш сәнгатьне бары тик күңел ачу позициясеннән генә кабул итә. Ә бит сәнгать – зуррак нәрсә. Бу – эмоциональ тренажер. Күңел катмасын, һәм кеше булып калыйм дисәң, барлык хисләрне дә кичерә белергә кирәк. Әгәр син якыннарыңның кайгысын уртаклаша алмыйсың, ярата белмисең, авыр чакта елап бушанмыйсың икән, бу дөрес түгел. Мин үзем, кеше ярдәмгә мохтаҗ икән, һәрвакыт булышырга тырышам. Хәзер без ышанмау һәм битарафлык дөньясында яшибез. Барлык үтенечләрдә дә спекуляция күрәбез. Ярдәм итәсе урынга, кеше бәласен телефонга төшереп хозурланабыз. Болай ярамый. Без нәрсәдер эшләргә сәләтле булганда гына – кеше. Ярдәмгә мохтаҗ кешене күрәбез икән, аның наркоман яки эчкече булуын сәбәп итеп, булышмый калырга һич ярамый, бәлки аның хәле чыннан да авырдыр. Ихтимал, бу безнең бүгенге мәдәнияттә әчтәлекне чигереп, бәлки шоу, тамаша күрергә күнегүебездән киләдер. Ә мәдәниятта иң мөһим кыйммәт – әндәү, уяту ул. Бу-нәкъ менә буыннан буынга тапшырыла торган символ һәм мәгънәләр.

– Минемчә, безнең татарстанлылар бер дә битараф түгел. Моны мәдәни мирасны саклау темасы буенча күзәтеп карый алабыз. Күптән түгел булган хәлләрдән: Казан Арча казармаларын югалтты; Яшел Үзәндә борынгы Полукамушки районы яңгыннан зыян күрде. Җәмәгатьчелекнең әлеге вакыйгаларга мөнәсәбәте бүгенге татарстанлыларның битараф булмавын раслый, аларга республиканың тарихи йөзен саклап калу бик мөһим. Бу юнәлештә нинди эш алып барыла?

– Былтыр мәдәни мирас объектларын саклау комитеты аерым органга әйләнде. Минем, гражданин буларак, позициям мондый: бүген, нәрсәне булса да саклау өчен, һәр объектның кыйммәтен төгәл белергә кирәк. Объектны саклап, без аның диварларын гына түгел, тарихи кыйммәтен дә саклыйбыз. Бу урында мин икътисадчы буларак әйтә алам: реставрация һәрвакыт күпкә кыйбатрак тора. Һәм ул төзелеш яки реконструкциягә караганда күбрәк регламентлаштырылган. Әгәр без бу системаны үтәкүренмәлерәк һәм икътисадый яктан кызыклырак итә алмыйбыз икән, әгәр дәүләт бу мирасны сакларлык механизмнарны булдыра алмый икән, безгә алга бару бик кыенга төшәчәк.

Менә, мәсәлән, әгәр сез мәдәни мирас объектында яшисез икән, сез реставрация өчен күбрәк акча түләргә әзерме? Шунлыктан миңа «Том Сойер Фест» проекты бик ошый – бу очракта мәдәни мирас объектлары территориясен нормаль халәткә китерергә волонтерлар булыша. Үзеңнән башларга кирәк. Әйдәгез, урамнарны чүпләмик, төрле төркемнәр, теләктәшләр, фикердәшләр чылбыры оештырыйк та, территорияләрне җыештыру белән үзебез шөгыльләник! Чөнки мәдәни мирас объектының аяныч хәлдә булуын безгә хәбәр итү генә – тәнкыйть түгел, бәлки мин алдарак әйтеп узган критиканлык ул.

Безнең үзебез өчен нинди саклау режимын файдалануыбызны төгәл аңлау зарур. Акча булмаганга барысын да тукыма астына гына яшереп куеп, шундый шәһәрдә яшәү дә матур түгел бит. Әлбәттә, әлеге объектларны торгызырга кирәк. Бу өстенлекләргә нигезләнгән максатчан позиция булырга тиеш.

КЕЧЕ ШӘҺӘРЛӘРНЕ НИЧЕК САКЛАРГА

– Россиядәге кече шәһәрләр саны сизелерлек кимеде, аларның күбесе хәтта юкка чыгарга да мөмкин. Сәбәпләрнең берсе – мәдәни тормыш булмау. Ә Татарстанның кече шәһәрләрендә вазгыять ничегрәк?

– Кече шәһәрләр проблемасы – аларның моношәһәр булып формалашуында. Алабуга территориясендә Алабуга трактор заводы, Яр Чаллыда – КАМАЗ, Түбән Камада нефтьхимия комбинаты төзелгән. Ягъни шәһәрләрне индустриальләштерү нинди дә булса бер предприятиегә бәйләнгән. Алабугада хәзер махсус икътисадый зона, ул шәһәрне бүген дә яшәү өчен кызыклы, уңайлы ясый. Анда искиткеч мәдәни проектлар гамәлгә кертелә: күптән түгел Спас ярминкәсе, аңа кадәр Борис

11. Табынга куябыз!



12. Теләк телибез!



Paprika
Редакция «Паприка» кулинария студиясенә рәхмәтен белдерә.
8-937-776-33-28, paprika_kazan@mail.ru, Казан шәһәре, Бауман ур., 44/8 йорты.
Реклама

Березовский фестивале узды. Алабугалылар бик бай мәдәни тормыш белән яши. Әлмәттә парк һәм скверларда бик күп проектлар үткәрәләр. Шунлыктан мәдәният кенә үсәргә тиеш түгел, бердәм социаль-икътисадый система булырга, ул эшне дә, ялны да, белем бирү сыйфатын да күздә тотарга тиеш. Гәрчә без бик куәтле мәдәният булдырсак та, бу әле шәһәр дә кызыклы булыр, дигән сүз түгел ләбаса. Кайбер кече шәһәрләрдә исә мәдәният учреждениесе шәһәртөзегеч тә булырга мөмкин, мәсәлән, Алабугадагы музей – шәһәртөзегеч предприятие.

Европада халыкның күп өлеше кантоннарда яки кечкенә шәһәрләрдә яшәвен дәвам итә. Анда алар өчен салым өстенлекләре бар. Керемгә карап салына торган салымның 20–30 проценты кеше яшәгән территориягә тапшырыла. Хәтта ул бер шәһәрдә яшәп, икенчесендә эшләсә дә.

ҺӘРКЕМГӘ – ҮЗЕНЕКЕ

– «Мәдәният – дәүләтнең имидж сәясәтенең бик нәтиҗәле инструменты», – бу сезнең сүзләр. Милли мәдәниятне дөнья аренасына ничек чыгарырга планлаштырасыз? Һәм конкрет нәрсәләрне чыгарырга җыенасыз?

– Беләсезме, «Әлиф» спектакле фикердәшләр төркеме тарафыннан 49 мең сумга куелды. Тагын кабатлыйм, иҗатта бөтен нәрсә акча белән генә үлчәнми. Кичә инде бу спектакль Мексика тамашачысына күрсәтелде. Нурбәк Батулла андагы хореографиясе өчен «Алтын битлек» алды. Спектакль Парижда, Мексикада зур уңыш белән үтте. Заллар аягүрә басып алкышлады. Мондый кече формалар да зур кызыксыну уятырга мөмкин. Быел без фин татарларына «Мулла» фильмын күрсәттек. Тамашачылар арасында финнар күп иде. «Мәдәният» сүзенә мин менә нәрсәне кертәм – дәүләт сәясәтенең имидж асылы ул. Бу кешеләрнең, җәмгыятьнең психологиясе. Әгәр без мәдәниятебезне танытабыз икән, без үз төбәгебез, үз илебезнең дөньяда киңрәк танылуына булышабыз. Без Харбинга бардык, анда симфоник оркестр чыгыш ясады. Зал һәр әсәрдән соң алкышларга күмелде! Ягъни мәдәниятне грамоталы рәвештә тиешле якка юнәлтә генә белергә кирәк – аны кайда күрергә телиләр, шунда алып барырга. Кытайда классик музыкага ихтыяҗ зур. Европада фольклорга мөкиббән китәләр. Кемдер милли аспектларның замана сәнгатендә чагылышын күрергә тели – «Әлиф» нәкъ менә хәзерге заман аспекты булып тора. Бу – маркетинг, тамашачыга нәрсә кызыклы булуын аңлап эш итү.

Республикадан читтә яшәгән милләттәшләребезнең мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен без Татарстанда мөмкин булганның барысын да эшлибез. Уявның ничек үтүен хәтерләгез әле, хәтта Президент та чуаш көлмәген киде – чөнки барысы да чын, ихлас иде! Тулы бер халыкның гаять зур мәдәни катламын күрсәттек. Хәзер Родченко проекты башлана, ул Европада бик популяр. Бөтен дөнья өчен кызыклы Фешин – бүген иң кыйммәтле рәссамнардан берсе. Без мәдәниятне түгел, бәлки кыйммәтләрне трансляциялибез. Һәм без үзебезнең авторларны активрак танытырга тиеш. Күргәзмәләр белән генә түгел. Мәдәнияттән файдаланучыларда ихтыяҗ тудырырга кирәк. Моның өчен исә без үз мәдәниятебезне, үз телебезне белергә тиеш. Мин 43 яшемдә татар телен өйрәнә башладым, миндә шундый ихтыяҗ туды. Өйрәндем һәм моңа бик шатмын. Шуны аңлау мөһим: әгәр без үзебезнең мәдәни мирасыбызны яратмасак, үзебезне югалтырга мөмкинбез.

БӘЙРӘМНӘР КҮП БУЛМЫЙ УЛ

– Туристларны җәлеп итү өчен хәзер Татарстанда ниндидер вакыйгага бәйле бәйрәмнәр бик күп: милли бәйрәмнәр, йомырка фестивале, балыкчылар бәйрәме, ризык фестивале һ.б. Артык күбәеп китмәдеме соң бәйрәмнәр? Аларның асылы югалмасмы?

– Минемчә, һәр бәйрәмнең үз вакыты, үз урыны бар. Мәсәлән, балык шулпасы бәйрәме Зөягә бик туры килеп тора. Хәтта Зөянең гербында да балык сурәтләнгән, анда Чуртан елгасы ага. Балык фестивален монда ясамыйча, тагын кая ясыйсың инде? Яки менә Болгарда урта гасырлар сугышын реконструкцияләү – бу проект турында бәхәсләр булды. Бер яктан, без бөек Болгар җирендә ислам кабул ителүне бәйрәм итәбез, икенче яктан, Тәре йөртүчеләрнең сугышын торгызабыз. Бу җәһәттән миндә эчке каршылык туды. Тик бу болар булмаска тиеш, дигән сүз түгел. Мин әлеге сугышларны оештыручылар белән очраштым… Шулай да минем үземә анда милли компонент булуы зарур, без бит үз территориябезне танытырга тиеш. Тәре йөртүчеләр безнең мәдәни яссылык өчен читрәк күренеш…

Ирада Хафизҗановна кәстрүлне ачып карый, ә анда инде газмах та әзер икән. Безгә дә авыз иттерә.

– Тәмле бит? – дип, канәгатьләнү хисе белән кызыксына пешекчебез, безнең телне йота язып калуыбызны күреп. Искиткеч!

ИКМӘКМЕ, ТАМАШАМЫ?

– Сезнең өчен «мәдәниятле кеше булу» гыйбарәсе нәрсәне аңлата?

– Без мәдәни ял итүгә мохтаҗ булсак һәм талантларны үстерергә өйрәнсәк, чыннан да мәдәниятле милләт булачакбыз. Әмма, кызганыч, әлегә без мәдәниятне ешрак хезмәтче сыйфатында кабул итәбез. Бу дөрес түгел. Кешенең беренчел хаҗәтләре бар – ризык, су… Әмма, туклангач, безгә рухи азык та кирәк. Ягъни без матди байлыктан кадерлерәк кыйммәтләр булуына төшенәбез. Әлегә безнең күпчелегебез беренчел дәрәҗәдә шул. Мул тормыш һәрвакытта да югарырак дәрәҗәгә күтәрми. Минем бай танышларым күп – алар ел саен чит илгә һаман бер үк биш йолдызлы кунакханәгә ял итәргә бара, чөнки көн буе комда кызынырга, диңгездә йөзәргә һәм туйганчы ашарга була – бу әле алар өчен һаман кызык… Ә бит иң мөһиме – яңалыкка, белемгә сусау! Тагын бер казылык түгел, бәлки китап сатып алу яки театрга бару яхшырак икәнен аңлаган очракта гына без беренчел дәрәҗәдән икенчесенә – мәдәни дәрәҗәгә күчтек дип әйтә алачакбыз.

Paprika
Редакция «Паприка» кулинария студиясенә рәхмәтен белдерә.
8-937-776-33-28,
paprika_kazan@mail.ru,
Казан шәһәре,
Бауман ур., 44/8 йорты.
Реклама

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Габдулла Шамуков бәхетне **НИДӘ** күргән

Мәүла Колый турында **НИЛӘР** беләбез

Салават Азаматның хыялын **НИЧЕК** тормышка ашырды

Димаш **НИНДИ** уйлар белән яши

НИ ӨЧЕН авылда яшисе килә

КЕЧЕ ВАТАН ПАТРИОТЛАРЫ



«КЕШЕ ЯРАТКАН ЭШЕНДӘ ЭШЛӘСӘ – БӘХЕТ...»

Татарның күренекле сәхнә остасы, Тукай образын беренче булып сәхнәдә гәүдәләндергән артист, танылган язучы-тәрҗемәче, СССР язучылар берлеге әгъзасы һәм татар актерлары арасында сирәкләрнең бәхетенә тигән «СССРның халык артисты» дигән мәртәбәле исем иясе Габдулла Шамуковның туууына быел 110 ел. Шул уңайдан аның тормыш һәм иҗат сәхифәләре буйлап сәяхәт итеп кайтырга чакырам сезне.

Автор:
Мөршидә Кыямова

«БӘЛӘКӘЙ КОМИК»ТАН – СССРНЫҢ ХАЛЫК АРТИСТЫНА

Габдулла Шамуков 1909 елның 11 декабрендә хәзерге Ульяновск өлкәсенең (ул чактагы Сембер губернасының Мәләкәс өязе) Әсән авылында укымышлы гаиләдә дөньяга аваз сала. Бабасы Фәттәхетдин мулла була, башлангыч дини белемне ул бабасыннан ала. Ләкин илдә вазгыять үзгәрә. Аның яшьлек еллары Бөек Октябрь революциясеннән соңгы елларга туры килә. Авыл мәктәбендә укыганда ук инде ул әдәбиятка тартыла. Шагыйрьләрнең әсәрләрен сәнгатьле итеп уку белән мавыга башлый.

Габдулланың җор теллелеге әнисе Гизенавал ягыннан күчкән булса кирәк, чөнки ул сәгатьләр буе мөнәҗәтләр көйли, Тукай әсәрләрен сөйли торган була. Булачак сәхнә остасы боларның барысын да үзенә сеңдереп үсә. Кечкенәдән күп китаплар укырга яраткан, ә үзенә ошаганнарын хәтта ятлап башкаларга да сөйләгән Габдулла. Әлеге хирыслыгын авылдашлары да үз иткән.

Истәлекләрдән күренгәнчә, Шамуковның сәхнәдәге тәүге образы – кыз бала роле. Мәләкәстә укыганда сәләтле малай драма түгәрәген дә җитәкләгән, димәк ул сәхнәне дә кечкенәдән белеп-тоеп үскән. Татар Колмаеры авылында укыганда Габдулла пионервожатый булып та эшли (Татар Колмаеры урта мәктәбендә аның хөрмәтенә мемориаль такта куелган). Аның ялкынлы чыгышларын күргән иптәшләре: «Син киләчәктә артист яки язучы булачаксың!» – дип, малайның күңелен үсендерә. Юраган юш килә, диләр бит... Шулай килеп чыга ки: артистлыкка укырга кергәнче, сәләтле егет берара Уфада «Яңа авыл» газетасында эшли, башкорт телендә мәкаләләр язарга өйрәнә. Телләргә хирыслыгы, белемгә омтылуы исә аңа эрудит булып формалашырга мөмкинлек бирә.

Фотолар Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры архивыннан алынды.



Мәҗит Гафури фатихасы белән Башкорт сәнгать техникумының театр бүлегендә белем алганнан соң, Габдулла Шамуков Башкорт дәүләт академия театрында эшли башлый. Биредә аңа «Бәләкәй комик» дигән кушамат та бирәләр. Әлеге кушамат (һәм амплуа) яшь артистны җитди образлардан берникадәр читләштерә хәтта. Тик аның сәләте, эчке омтылышы, зыялылыгы Әхмәт Фәйзинең «Тукай» әсәре буенча куелган спектакльдә тулысынча ачыла. Башкорт сәхнәсендә куелган әлеге әсәрнең даны бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән. Театр тәнкыйтьчеләре спектакльгә дә, Тукай образын сәхнәгә чыгарган яшь актер Габдулла Шамуковка да югары бәя бирә.

Халык шагыйре Габдулла Тукайның иҗаты Габдулла Шамуков тормышында зур урын биләп тора. Шагыйрьнең әсәрләрен ул бәләкәй чактан ук сөендереп үсә бит. Шуңа күрә, сәхнәдә Тукай образын тудырырга насыйп булгач та, аның әлеге эшкә дулкынланып, илһамланып алынганы табигый.

«Меңнәрнең йөрәгендә моң һәм җыр булып яңгыраган Тукай образы минем өчен дә бик якын һәм кадерле. Тукай - минем шәхси һәм иҗат тормышымда тирән эз калдырган, мине бөтенләе белән биләп алган шагыйрь. Ул минем бик бәләкәй чагымнан ук хәтеремә сеңеп калган. Минем әнием, гади бер татар хатыны, Тукай шигырьләрен өзелеп ярата, аларны мөнәҗәт итеп көйли иде. Ә инде үсә төшеп, бабамның китаплар тулы кәрзиненә хуҗа булып алгач, миңа Тукайның шигырьләре белән тагын да якыннанрак танышырга мөмкинлек туды. Анда шагыйрьнең әсәрләре шактый күп иде. Мин андагы шигырьләрнең барысын да диярлек яттан өйрәндем. Шул көннән башлап алар минем аерылгысыз тормыш юлдашыма әверелделәр, бөтенләе белән минем хисләремне, уйларымны,акылымны биләделәр. Мине дә иҗат дөньясына чакырдылар».

«Мылтыклы кеше». Г.Шамуков,Ф.Халитов, режиссёр Ш.Сарымсаков репетиция вакытында

1947

«Кол Гали». Г.Шамуков Актай ролендә

1962



«Тукай». Г.Шамуков Тукай ролендә

1970

1968

1976

1978

«Әни килде». Рольләрдә – Г.Ибраһимова, Г.Шамуков

«Мылтыклы кеше». Г.Шамуков Ленин ролендә

Тукай образын тудыру – Габдулла Шамуковның драматик иҗатында гаять әһәмиятле этапны тәшкил итүче бер баскыч була. «Тукай образын иҗат иткәндә» дигән истәлекләрендәге тагын шушындый юллар, безгә беренче карашка җиңел генә күренгән актер һөнәренең никадәр газаплы, авыр һәм катлаулы икәнен дәлилли:

«Шагыйрьнең әсәрләрен укып, тамашачы каршында уңыш казануы бер эш. Әмма сәхнәдә шагыйрьнең үзен җанландырып күрсәтү – бөтенләй башка нәрсә. Габдулла Тукай – халыкның иң сөекле шагыйре. Халкыбыз күңелендә аның мөкатдәс образы яшь, гаҗәеп сөйкемле, бөек һәм изге ул образ. Сәхнәдә гәүдәләндереләчәк Тукай өчен материал – мин үзем ләбаса, гади бер актер. Минем йөзем, күзләрем, тавышым, буем-сыным, килеш-килбәтем, кыяфәтем. Мин бит – җирдә яшәүче гади кешеләрнең берсе. Габдулла Тукай исә, гади кеше түгел – «көч белән бергә гүзәллекне җыйган диңгез» ич ул. Мин, сәхнәгә Тукай булып чыгып, халык хыялындагы нурлы сурәтне бозармын, халкыбызның хисләрен рәнҗетермен, дигән уйлар белән борчыла башладым. Бу борчылу авыр бер чиргә әйләнеп китте. Мин хәтта актерлык кабилиятемә дә шикләнеп карый башладым. Сәхнәгә килүем дә бәлки саташу гына булгандыр...»

Мондый масштаблы рольгә яшь артист, әлбәттә, бар көче-куәте белән алынган. Тукайның бөтен иҗатын диярлек барлап, укып, ятлап чыккан. Образ тудырганда артистның затлы нәселгә нисбәтле булуы да ярдәм итми калмагандыр. Бу урында Габдулла Шамуковның шәҗәрәсе Габделҗәббар Кандалыйга барып тоташканлыгын да билгеләп узарга кирәк.

Композитор Н.Җиһанов, артист Г.Шамуков, язучы Ә.Фәйзи

МӘСӘЛ ОСТАСЫ

СССРның халык артисты Габдулла Шамуков үзенең күпкырлы иҗаты белән дәрәҗәле сәхнә осталарыннан шактый аерылып тора. Сәхнәдә Тукай, Ленин, Хуҗа Насретдин кебек киң диапозон таләп иткән һәм гаять җаваплы, катлаулы образлар тудыруы белән генә дә онытылмаслык эз калдырыр иде ул театр тарихында. Әмма ул үзен башка өлкәдә дә сынап карый. СССР Язучылар берлеге әгъзасы Габдулла Шамуковның әдәби эшчәнлеге аерым соклануга лаек. Дөнья классикасы әсәрләрен тәрҗемә итү белән бергә, Габдулла Шамуков әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм шигырь төзелешенә кагылышлы теоретик хезмәтләр авторы буларак та укучыларга яхшы таныш.

Дөньядагы милләтләрнең әдәбиятында бармак белән генә санарлык булган мәсәл язу остасы да була ул. Крыловның мәсәлләрен татарчага тәрҗемә итеп кенә калмый, ә үзе дә татар мәсәлчесе булып танылa. «Парнас» дип исемләнгән мәсәлен укыганда, күңелдән бу фикер иясенең алдан күрү сәләте дә булган икән, дигән уй ялтырап уза:

«...Безгә хәзер Ишәк хоры төзү кирәк,
Читләр керeп таркатмасын өчен хорны,
Шундый тәртип кирәк монда:
Кем дә кемнең тавышында
Чагылмаса Ишәк моңы
Андыйны без
Парнас тауга мендермибез...»

Пьесалар тәрҗемә итү, сәхнәдәшләренең иҗатына багышлап тирән анализлы күпсанлы мәкаләләр язу, әле киртәләр куелган, тыелган чорда ук татарның шанлы тарихын, аның даһи шәхесләрен өйрәнү. Артист булу белән бергә алып барылган бу эшчәнлекне зур әдәби һәм фәнни, гыйльми хезмәтләр буларак бәяләрлек.

«Тукай» әсәре авторы Әхмәт Фәйзи, спектакльне тамаша кылгач: «Мин сәхнәдә чын Тукайны күрдем», – дип, Габдулла Шамуковка югары бәясен биргән.

Габдулла Шамуков башкорт сәхнәсендә эшләгәндә бер-бер артлы көчле, якты, тамашачы күңелендә уелып калырлык образлар тудыра. Ә инде утыз җиде яшендә, Бөек Ватан сугышыннан соң, ул Казанга килә. Үзенең иң парлак вакытында Татар дәүләт академия театрында эшли башлый ул. Казан тамашачысы алдында беренче тапкыр Ульянов-Ленин образында таныла.

Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Әзһәр Шакиров өлкән сәхнәдәше турында җылы хатирәләрен яңарта:

– Габдулла абый – РСФСРда милли театрда Ленин образын сәхнәгә күтәрүче беренче артист. Ул Владимир Ленин ролендә сәхнәгә килеп чыгуга, бөтен тамашачы аягүрә басып кул чаба башлый иде. Сүзен сөйләргә ирек бирмиләр, кыяфәте шулкадәр охшаган була ки, хәтта бергә уйнаган артистлар да шакката. Габдулла абый болай дип әйтә торган иде: «Шулкадәр каушадым, ничек уйнаганымны хәтерләмим дә». Мин Мәскәүдә Ленин ролендә уйнаган артистларны да күрдем, ләкин тамашачының аларны аягүрә басып, алкышлап каршы алганын хәтерләмим.

Бу дан, абруй артист өчен иң зур сынауларның берсе дә була. Син шушы рольне уйнап, үзеңне бөек артист буларак исбат итәсең яки шуның белән бөтенләйгә сүнәсең ягъни. Артист өчен иң кадерлесе – Ленинның фикере һәм эчке темпераменты була. Ул үзенең бөтен көчен, сәләтен, акылын шуңа җигә. Габдулла абыйның тышкы кыяфәте Ленинга бик якын: зур баш, җыйнак гәүдә, кысылыбрак торган күзләр, борыны, эчке мөлаемлеге (руслар аны «внутреннее обаяние» диләр) тамашачы тарафыннан аны Ленин ролендә кабул итәргә бик нык ярдәм итә.

Нәфис сүз сөйләве белән дә танылган актерның радиодагы язмаларын театр уку йортларында осталык дәресе итеп кулланырга иде, ди бүгенге сәнгать белгечләре. Татарстан радиосы фондында, чыннан да, бәхетебезгә, диик, аның башкаруында күп кенә әдәби мирасыбыз үрнәкләре сакланып калган.

Киң кызыксыну сәләтенә ия булган шәхес гомере буена белемен арттырудан туктамый. 1952 елда Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетын тәмамлый, үзлегеннән күп укый. Габдулла Шамуковны якыннан күреп белгән замандашлары аның тирән белемле булуына соклануын белдерә.

Кич утырып сөйләшүләр вакытында ул татар тарихы сәхифәләрен еш искә ала торган була. «Сезнең буын бәхетсезрәк булды шул, сез татар тарихын да, аның ханнарын да, патшаларын да белмисез. Бәлки, дөньялар үзгәрер әле, тарихны гел яшереп ятмаслар», – дип өмет белдерә торган була Шамуков.

Киңкырлы иҗатчы, педагог булудан тыш, мөхтәрәм сәнгатькәр җәмәгать эшләрендә дә актив катнашкан. Кыю фикерле, кирәк чакта таләпчән дә була белгән язучы-артист беренчеләрдән булып Сөембикә манарасы турында язып чыга.

1970 нче елларда Мәскәүдә КПСС Үзәк Комитетында аның татар халкы мәсьәләләрен кайгыртып йөрүләрен бүген дә сагынып искә алучылар бар. Тормышның һәр мизгеленнән тәм таба, бер минутын да бушка уздырмый торган була ул. Ихтыяр көче шундый куәтле булса да булыр икән кешедә: көнетөне эшли, тәрҗемә итә, үзенә шөгыль таба белә. Кирәк икән, чын мәгънәсендә гыйльми мәкаләләр яза. Галиәсгар Камал театрының музей архивында сакланган язмаларны барлаганда, милләтпәрвәр артистның тел турында ачынып язганнарына күз төшә. Вакытлы матбугатта аның милләт, тел язмышына нисбәтле тирән фикерле, җентекле анализлы язмалары, әйтерсең лә, бүгенге көн халәтен тасвирлый.

«Татар халкы, сан ягыннан, Советлар Союзында бишенче урында тора. Һәм шул күпсанлы халыкның ана телендә бер генә махсус урта яки югары уку йорты да юк. Халык саны, Татарстанныкына караганда, күпкә азрак булган Союздаш җөмһүриятләр исә, андый уку йортларыннан файдаланалар. Бу бик яхшы. Тагын шунысы да бик әйбәт: бу җөмһүриятләрдә милли телне монда яшәүчеләрнең һәммәсе өйрәнә. Бернинчә тел белү шәхеснең карашын гына киңәйтә ләбаса! Нигә соң автономияле җөмһүриятләрдәге милләтләрнең теленә генә кимсетеп карыйлар?..

Милли мәктәпләрне тоташтан урыс теленә күчерүнең ялгыш адым икәнлеге инде хәзер үк ап-ачык. Аяныч хәлләр артык тирәнгә киткәләгәнче, бу хатаны төзәтергә кирәк. Тәкъдимне ерактагы төбәкләрдән күтәргә ярамый, чөнки кайберәүләр мәктәпләрне урыслаштыруга каршы чыккач, милләтчелектә гаепләп, аларның авызларын томалаганнар. Гаҗәп: ни өчендер «милләтчелек» тамгасы аз санлы халык вәкилләренә генә сугыла, ә партиянең X съездында каралган төп мәсьәлә онытыла. «...Съезд үзенең төп һөҗүмен иң куркыныч күренешкә – «бөек урыс» шовинизмына каршы юнәлтә», – дигән сүзләр истән чыга».

ИСТӘЛЕКЛӘР

Татарстанның халык язучысы Туфан Миңнуллин истәлекләреннән:

– Иҗат биографиясе дә кызыклы аның. Үзе мишәр кавеменнән чыкса да, башкорт театрында башкортча сөйләп уйнаган. Аннан Камал театрына күчеп, зур артист дәрәҗәсенә ирешә. Артист булырга җыенган яшьләрне татарча дөрес сөйләшергә өйрәтте. Мавыгучан кеше иде. Бер эшне дә өстән-өстән генә эшләмәде. Бервакыт театрда шахмат уйнау модага керде. Спектакль барганда тәнәфес вакытында артистлар шахматка утыралар иде. Анда инде, әлбәттә, Габдулла абый да була. Уйнаганда берәр пешка отса, Берлинны алгандай сөенә, үзенеке «ашасалар», башын учлары белән кочаклап, коридор буйлап йөренә. Тәнәфестә кием алыштырырга кирәк булса, костюмер кызлар: «Габдулла абый, Габдулла абый», – дип янында сайрап торалар. Ул киенә-киенә уйный. Шундый хәл дә булды, киенә-киенә уйнаганда, режиссер ярдәмчесе радио аша: «Шамуков, сәхнәгә!» – дип кычкыра. Габдулла абый кальсоннан гына сәхнәгә атылып чыга, артистларның күзләре акая, тамашачы көлә. Габдулла абый югалып калмый: «Гафу итегез, мин тиешле формада түгел икәнмен», – дип сәхнәдән чыгып, чалбарын яхшылап киеп керә.

Татарстанның халык артисты Хәлим Җәләй истәлекләреннән:

– Әңгәмәләрнең берсендә мин: «Габдулла абый, имеш, сез Кольцода озак кына вакыт трамвай көткәнсез икән. Трамвай көттереп кенә килгәч, сез, өйгә керәм дип уйлап, галошларыгызны асфальтта салып калдырып, трамвайга кереп киткәнсез, диләр. Шул дөресме?» – дип сорап куйдым. Ул башта рәхәтләнеп бер көлде. Аннары: «Шулай дип сөйлиләрмени? Булгандыр инде. Булгандыр... Ул чакта минем Сөембикә манарасының тарихын язып йөргән вакыт иде... Булды бугай шул...» – диде.

Татарстанның халык артисты Луара Шакирҗан истәлекләреннән:

– Киң вә нечкә күңелле, кешеләргә яктылык, шатлык китерүче, ә үзе моңсу дәү клоун сыман яши күңелдә Габдулла абый. Йөрәгемне тырнап торган бер әрнү булып та яши. Беренчедән, кем-кем, ә инде беренче булып Тукайны сәхнәдә сурәтләгән, татарның тарихында да бик төптән «казынган», СССР Язучылар берлеге әгъзасы Габдулла Шамуков ник соң Тукай бүләгенә тәкъдим ителмәгән?! Күпме пьесалар, Шекспирның әсәрләрен, Крылов мәсәлләрен тәрҗемә иткән, үзе дә шәп мәсәлче! Сүз уңаеннан, мәсәл язу остасы бармы бездә бүген? Көләрлек, акыл бирерлек күренешләр беткәнме әллә юкса?!. Бетмәс алар кешелек дөньясында. Ә менә шагыйрь талантын гына түгел, никадәр зирәклек, үткен акыл, психологик тоемлау, белем, җәмгыятьне, сәясәтне үтәли күрү һәм башка аерым фикерләү, күзаллау талантын да таләп иткән мәсәл язучылар сирәк. Юк, хәтта! Габдулла ага сирәк, кабатланмас шәхес иде! Нинди гаделсезлек! Нинди тар күңеллелек бу бездә! Бик аяныч... Гафу итеп булмаслык... Бәяләп бетермибез, сакламыйбыз шундый бөек талантларыбызны!..

«СҮЗНЕҢ ТӨСЕН КҮРҮЧЕ»

Сәхнә телен өйрәткәндә:

«Сүзнең төсе, авырлыгы, хәтта исе бар. Кайбер сүзләр кош мамыгы кебек җиңел, ә кайбер сүзләр кургаш сымак авыр була. Сүзнең тәэсир итү көчен тоеп сөйләргә кирәк... Сүздәге бөтен авазлар: тартыгы да, сузыгы да тамашачыга ишетелергә, аңлашырга тиеш. Авыз эчендә ботка пешермәгез. Сүзнең мәгънәсен үзең аңласаң гына, ул тамашачыга барып җитә», – ди торган була Габдулла Шамуков.

Г. Шамуков. Ефим Симбирин рәсеме (1973)

Габдулла Шамуков педагог буларак та зур уңыш казанган шәхес. Ул татар сәхнәсенә үзе шикелле үк киң һәм кыю фикерле, талантлы артистлар әзерләгән остаз. Шәүкәт Биктимеров, Ирек Баһманов, Айрат Арсланов, Наил Әюпов, Наил Шәйхетдинов, Рәсим Сәләхов, Илдар Хәйруллин, Дамирә Кузаева, Фирдәвес Хәйруллина, Луара Шакирҗанова.

Татарстанның халык артисты Хәлим ага Җәләлов та – аның талантлы укучыларыннан берсе. Менә ничек искә ала ул остазын:

– Ул кырык биш елдан артык Уфа, Казан театр училищеларында сәхнә телен укыта, сөйләү техникасын өйрәтә. Бу тәҗрибәле остазда дүрт ел укуымны үземнең бәхетем дип саныйм. Үзе дә менә дигән нәфис сүз остасы безгә сүзнең кадерен белергә, мәгънәсен аңларга, аның җегәрен, кодрәтен, тәмен тоярга өйрәтте. Шигырь, хикәя укырга өйрәтүенә тукталып тормыйча, мәсәлләр укырга өйрәтүен генә әйтеп үтәм. Үзе дә оста мәсәлче, Крылов мәсәлләрен иң шәп тәрҗемә итүче, күрәсең, мәсәл жанрын аерата якын күргәндер. Менә ул Ишәк булып сөйли, яки Төлке булып җавап бирә, һәм шунда яраткан остазыбыз күз алдыбызда тышкы кыяфәте, рәвеше, тавышы белән хәйләкәр Төлкегә, явыз Бүрегә, аңгыра Ишәккә әверелә дә куя. Чын әгәр!.. Аның хәрәкәтләре, йөреше, күз карашлары – нәкъ инде менә шушы мәсәлнең персонажлары. Мәсәлгә ул игътибарны да күбрәк бирде. «Мәсәл бит ул – тәмамланган драма әсәре. Аның идеясе дә, композициясе, образлары, конфликты да бар», – дия иде.

Сәнгать мөгаллиме укучыларында әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләп, зәвыкларын формалаштырып кына калмаган, артист буларак мөсәкыйль иҗат юлына баскач, тормыш киртәләрен җиңәргә дә өйрәткән.

Әдәбият, сәнгатьнең төрле тармакларында Габдулла Шамуков үзенең иҗат куәсен дәлилли. Нинди генә өлкәгә алынса да, һәркайсында үз сүзен әйтә алган сәнгать әһеле. Актер буларак, 50 елга якын сәхнә гомерендә татар театр сәнгате тарихында онытылмаслык бик күп образлар калдырган, төрле характерлар иҗат иткән ул. Замандашлары искә алганча, Галиәсгар Камал театрында барлык режиссерлар белән дә аңлашып эшләгән. Алар исә Габдулла агайны рольгә куюны, үз спектакленә алуны мәртәбә санаганнар. Ник дигәндә, даһи актерның сәхнә образларында халыкчанлык, гадилек, җылылык бөркелеп тора. Алар тормыш хакыйкате белән сугарылган.

Заманында татарны телевизор экраннары каршына җыя торган «Клад» нәфис фильмы бар иде. Халык язучысы Гариф Ахуновның Татарстан нефтьчеләренә багышланган «Хәзинә» романына нигезләнеп төшерелгән кинокартинада ул төп геройның карт әтисен, татар агасы Шәвәли образын башкара.

Г.Шамуков яшәгән йорт диварында мемориаль такта ачу тантанасы

Габдулла Шамуков 1981 елның сентябрь аенда 72 яшендә дәваланмый торган авырудан соң бакыйлыкка күчә. Тик, ни хикмәттер, Казанда бүгенге көнгә кадәр аның исеме белән аталучы урам, парк, хәтта музей почмагы да юк! Аның әтрафлы иҗат эшчәнлеген яктырткан, эксклюзив фотолардан, кызыклы материаллардан торган китап та эшләнелмәгән әле... Югыйсә, СССРның халык артисты, торгынлык елларында ук халкыбызның мәнфәгатьләрен яклап чаң суккан публицист, милләтпәрвәр көрәшче моңа бик тә лаек! Шулай да, ул бәхетле иҗат юлы узган дияр идем. Максатына киртәләрне җимерә-җимерә булса да барган, милләт язмышын кайгырткан бу зат. Әнә үзе дә бит бәхет төшенчәсен ничек шәрехли: «Кеше яраткан эшендә эшләсә – бәхет, уңышларга ирешсә – бу зур бәхет. Ә аның шул уңышларын күреп, вакытында бәяли белсәләр – бу инде иң зур бәхет!»

«ТАТАРСТАН» МАХСУС журналы өчен

СУФЫЙ ШИГЪРИЯТЕ ВӘКИЛЕ

Мәүла Колый иҗаты XVII гасыр татар әдәбиятында күренекле урын алып тора. Аның әсәрләре татар милләтенең шул чордагы иҗтимагый омтылышлары, фәлсәфи карашлары һәм сәнгатьле фикерләү үсешен күзәтү өчен кыйммәтле чыганак булып тора.

КЕМ УЛ – МӘҮЛА КОЛЫЙ?

Мәүла Колый әсәрләре бары тик 1926 елда гына табыла. Шагыйрьнең 3 мең 700 дән артык шигъри тезмәләре тупланган кулъязма мәҗмугасы табылуы турында «Кызыл Татарстан» газетасында Фазыл Туйкин мәкаләсе басылып чыга (1926, 9 апрель, № 81). Әлеге җыентыкны Фазыл Туйкин ТАССР Мәгариф халык комиссариаты каршындагы гыйльми үзәккә җибәрә. Кулъязманы өйрәнү эшен гыйльми үзәк Габдрахман Сәгъдигә йөкли. Ул, Мәүла Колый хикмәтләрен өйрәнеп, «Вестник научного общества татароведения» журналында (1927 ел) «Новый материал по истории татарской литературы» дигән мәкалә бастыра. Аннан соң Мәүла Колый иҗаты турында Латыйф Җәләй, Шакир Абилов, Х. Хисмәтуллин, Марсель Әхмәтҗанов, Раиф Мәрданов һәм башкаларның хезмәтләре чыга. Мәүла Колый иҗатын тирәнтен өйрәнүче галим Камил Дәүләтшин булды: ул 1972 елда шагыйрь иҗаты турында кандидатлык диссертациясе яклады.

Марсель Әхмәтҗанов язуынча, шагыйрь Мәүла Колый белән 1677–1678 нче елларда Балемхуҗа каберендә сакчы булып торган Бәйрәмгали Колыев бер үк кеше. Галим тикшеренүләреннән күренгәнчә, 1678 елда Биләр харәбәләре янына Казан өязенең төрле авылларыннан качкан татар крестьяннары күчеп утыра. Алар арасында Бәйрәмгали Колыев – хәзерге Питрәч районына караган Чыты авылы кешесе дә була. Һәм ул гомер буе шунда кабер сакчысы булып яши. Әлеге фараз Мәүла Колыйны шул заман кешесе итеп күзалларга, шагыйрьнең җәмгыятьтәге урынын ачыкларга, дөньяга карашына төшенергә нигез булып тора.

Күчеп килүчеләр Биләр янындагы Балемхуҗа мавзолее тирәсенә хуҗалык корып урнашканнар. Патша хөкүмәте татарларның тарихи үзәге булган Биләр тирәсенә туплануына тыныч кына карый алмаган, аларны аннан кудыру ягын караган. 1699 елда, ниһаять, аларны куып, урыннарына рус укчыларын китереп утырткан. Марсель Әхмәтҗанов «Бәйрәмгали Колыев һәм аның иптәшләренең балалары моннан соң Шушма буендагы Иске Иштирәк авылына барып урнашкан булса кирәк», дигән фикер әйтә.

«КИЛЕН КЕБЕК БИЗӘНЕП, АЛДАУЧЫ БУ ДӨНЬЯ»

Мәүла Колый – лирик, суфый шагыйрь. Аның безнең көннәргә хикмәт жанрында язган йөздән артык шигыре килеп җиткән. Ул аларны барысын да суфыйлык җимеше дип атый. Шагыйрь, әлбәттә, суфыйчылык карашларына тиз генә килмәгән; ул дөньяда күпне күргән, тормышның төрле баскычларын үткән. Әммә барлык хикмәтләренең дә үзәгендә нәфес белән күңел көрәше ята. Нәфес ул – реаль дөнья теләкләренә бирелү, рәхәт яшәргә, байлык тупларга омтылу (шагыйрь тормышны алтын-көмеш тулган гөлбакча итеп тә, ә тормышның ахырын елан-аждаһа итеп тә күрә. «Килен кебек бизәнеп, алдаучы бу дөнья» дип яза). Ә күңел ул – Аллага, сафлыкка омтылу, теге дөньяга әзерләнү, теге дөнья турында гына уйлап яшәү. Аның хикмәтләрендә – тормышта кая барырга белмичә аптырау да, зарлану да, җәбер-золым тулган дөньяга нәфрәт тә, гади халыкка хөрмәт тә бар. Мәсәлән, ул болай дип яза:

Фәридә Харрасова иллюстрациясе

Автор:
Әнвәр Шәрипов

Суфыйлык мивәләре (җимешләре) пешеп җитмеш,
Мән андыйн берен-берен татысам иде.
Ул мивәнең ләззәтидин мәст улубән (тәмам исереп),
Уздин (һушсыз) китеп, иссез булып ятсам иде.
Суфыйлыкта тәуфыйк тапса иркәк-теши
(ирләр-хатыннар),
Гыйшык утында көенүбән пешәр иде.

Бу, әлбәттә, җир кешесенә булган гыйшык түгел, ә Аллага мәхәббәт. Шагыйрь үзенең яраткан заты – Алла белән кушылырга омтыла, ә дөньяны түбән, начар итеп күрә. Аның барлык яхшылык һәм яманлык турындагы фикерләре Алла белән бәйләнештә күрсәтелә. Ләкин шагыйрь – җир кешесе, кешеләр арасында, алар белән аралашып яши. Аның дөньяга карашына әйләнә-тирә, мохит, җәмгыять тә тәэсир ясый; ул «җәмгыятьтә яшәп тә, җәмгыятьтән азат була алмый». Милли-колониаль изү астында интеккән халык өчен дә газаплана ул: кешеләр мондый тормыш белән, әлбәттә, килешеп яши алмый. Татар халкын изүгә корылган сәясәт, бер яктан, баш күтәрүләр, халык кузгалышлары китереп чыгара (Иван Болотников, Степан Разин җитәкчелегендәге түнтәрелешләр, мәсәлән). Икенче яктан, кешеләр, бу дөньяда тынычлык күрә алмау сәбәпле, реаль дөньядан бизеп, тынычлык бирә торган башка дөньяны эзли башлыйлар. Ә бу исә аларны дингә һәм суфыйчылыкка этәрә.

ШАГЫЙРЬ БУРЫЧЫ

Крестьян кузгалышларын бастыру нәтиҗәсендә йортсыз-җирсез калган хәерче-гарипләрнең саны арта. Өстәвенә, бу елларда таралган төрле эпидемияләр, ачлык һәм хәерчелек халык өстенә күтәрә алмаслык афәт булып төшә. Мондый бәхетсез кешеләр, әлбәттә, дөньядан туя, бу авырлыклардан котылу юлын күрә алмаганлыктан, яшәүнең мәгънәсен югалта. Шушы өметсезлеккә баткан, язмышына да, Алласына да рәнҗегән бәндәләрнең күңелен юатуны Мәүла Колый үзенең бурычы итеп саный. Гарипләр турындагы хикмәтен ул: «Хак бирмәсен һичбер кемгә гариплекне», – дип башлап җибәрә. Хикмәтнең бу фикер белән башлануы ук аның ортодоксаль суфыйчылык тәгълиматыннан аермалы булуын күрсәтә. Суфыйлар карашынча, дөньяда яшәү ул – ят җирдә «гарип» булып йөрү, ягъни гарип ул – Алла юлында йөрүче, бөтен мал-мөлкәттән, йорт-җиреннән аңлы рәвештә ваз кичеп, «мәкан» эзләүче аскет. Мәүла Колый «гарибе» исә конкрет иҗтимагый җирлеккә бәйләнгән һәм аның мондый хәлгә төшүе шәхси ихтыярга да, кешенең табигатенә дә нисбәтле түгел. Ул – рәхимсез тормыш нәтиҗәсе. Шагыйрь бу хәерчеләрнең көнкүреше искиткеч авыр булуын, хәтта башларына әҗәл килсә, тыныч кына ятып үләрлек урыннары да юклыкны җан тетрәткеч юлларда тасвирлый. Ул мескеннең бөтен дөньяда ялгызлыгын, бу миһербансыз заманда аңа ярдәм кулы сузарлык бер генә затның да булмавын ачынып яза:

Башындаултырмага атасы юк,
Өстендә хәсрәт йыйар анасы юк.
Уңлы-суллы хәлен сорар ийәсе юк,
Бер үлмәке мең үлмәкдин йаман иркән.
(43нче хикмәт).

Йорт-җирсез, михнәттә яшәүче адәмнәр үз хәлләрен рухи яктан да авыр кичерәләр. Аларның йөрәге хәсрәт утында яна:

Гарипләргә тормага йорт-мәкан кани?
Баш агырса, әҗәл йитәр, куркар җани.
Ыруг-кардәш кыла алмаз сәне гани,
Гариплектә үлүм килсә, дөшвар (кыен) иркән.
(43нче хикмәт).

Күренә ки, бу хикмәтләрдә шагыйрь гариплекнең дини эчтәлеген гомумән искә алмый, ә кыерсытылган ярлы халык вәкилләренең канлы яшь түгүен чагылдыра.

Безгә килеп җиткән йөздән артык хикмәтләрне Мәүла Колый, әлбәттә, бер вакытта гына язмаган. Ул хикмәтләр төрле чорда иҗат ителеп, шагыйрьнең дөньяны танып белү тәҗрибәсе артуын, чынбарлыкка мөнәсәбәтенең үсү-үзгәрү эволюциясен чагылдыралар. Аларда шәхес күңелендәге төрле рухи халәтләр сурәтләнә.

Мәүла Колый хикмәтләрендә еш кына дини-суфыйчыл, этик таләпләр белән дөньяви фикерләр үзара бәрелешеп килә. Мәсәлән, шагыйрь бер очракта күндәмлеккә, сабырлыкка өнди. Ләкин лирик геройның «күңел бәхере» кайный. Ул тормыштан канәгать түгел, борчыла, хакыйкать эзли. Шагыйрь сорыкорт руханиларны, диндарлык битлеген йөзенә каплаган суфый-ишаннарны тәнкыйтьли. Аларга карата ярсулы нәфрәте анык чагыла:

Башларына таҗ күтәрмеш, суфи мән тир,
Тәнләрени симерткәнчә хәрам йийар (ашар).
Ихласы йук, галәм халкын алдайу, күр,
Күңле туймаз, галәм халкын йотар имди.
(15нче хикмәт).

Әлбәттә, шагыйрьнең теләге – «ихлассыз», алдар суфыйларны гына тәнкыйтьләү, әмма аның дөньяга карашына чынбарлык шундый нык тәэсир иткән ки, нәтиҗәдә шагыйрь комсыз, кеше хакын ашап яшәүче суфый образын барлыкка китергән. Мәүла Колый иҗатының үзенчәлекле ягы да шунда: ул, суфый шагыйрь буларак, суфыйчылыкның традицион темаларына мөрәҗәгать итә һәм үз карашларын үткәрергә омтыла, әмма аның талант көче коры тәгълиматлар, вәгазь-нәсыйхәтләр чигенә генә сыеша алмый, хикмәтләре тормышчан күренешләр, җанлы кичерешләр белән дә сугарыла.

ГАДИЛЕККӘ, ГАЛИЛЕККӘ ГИМН

Өметсезлек, дөньядан ваз кичү фикере таралган бер чорда Мәүла Колый хикмәтләрендә кешенең иҗат мөмкинлегенә ышанып карау да сизелә. Шагыйрь бу әсәрләре белән кешене үзенең кыйммәте, үзенең дәрәҗәсе турында уйланырга этәрә. Шундыйларның берсендә ул игенчелек хезмәтенә дан җырлый, игенчелеккә зур бәя бирә. Бу хезмәтнең бөеклеге, дөньякүләм әһәмияте барлыгын ассызыклый. Игенче хезмәте, кешенең нинди дин һәм халыктан булуына карамастан, мөселманнарны да, кяферләрне дә туйдыра, игенче тәмуг утында да янмас, ди:

Игенчелек – галәмара изгү аты,
Нигъмәт йийәр (ашар) мөэмин, кяфер, юкдыр каты.
Игенчене көйдермәгәй тәмуг уты,
Игенчелек гали эшдүр, кыйлыр булсаң.

Шагыйрь игенченең кул-аягы туфрак булса да, аның йөзе ак булуын белдерә:

Игенченең әл-азакы булыр туфрак,
Хак тәгалә хәзрәтендә йөзләре ак.

Бер кабымлык иген үстергән кешегә Алла бер колны азат итү савабын бирәчәген әйтә. «Иген иккел, рәхмәт өмет итәр булсаң», – ди. Бу, әлбәттә, Аллаһның рәхмәте.

Мәүла Колый хикмәтләрендә гыйлемгә һәм галимнәргә мәхәббәт, наданлыкка нәфрәт ачык чагыла. Әмма бу әле тарих аренасына XIX гасырда гына чыгачак мәгърифәтчелек фикере түгел. Шагыйрь нәрсәнең яхшы, нәрсәнең начар икәнлеген генә аерып күрсәтә. Шагыйрьнең «гыйлем» һәм «галим»гә булган карашы да бик үзенчәлекле. Ул бер җирдә гыйлемнең бары тик дини эчтәлеген генә күрә, игътибарны шуңа юнәлтә. Ул гыйлем алуны дөньядагы иң мөһим эшләрнең берсе дип саный, галимнәрнең үзләрен күктәге кояш белән тиңләштерә:

Галимнәр күк йөзендә көнәш яңлигъ,
Шәкертләр тулыб торган айга яңлигъ.
(65нче хикмәт).

Наданнарны шагыйрь коңгызга тиңли. Әмма монда да Мәүла Колый карашында дин йогынтысының көче ачык күренә. Ул наданнарның ахирәт турында уйламыйча, бары тик дөнья өчен кайгыртуларын зур кимчелек дип бәяли:

Наданлар ахирәт димәз, дөнья тотар,
Коңгыз-кортлар, йорт тоташ дип, тизәк тишәр.
(62нче хикмәт).

Мәүла Колый галим булуның шарты итеп гыйлемлекне генә куймый: галим кешедә беренче чиратта кешелекле сыйфатлар булырга тиеш. Минминлекне рәхимсез тәнкыйтьли. Галим кешенең иң кирәкле сыйфаты итеп башкаларга ярдәмчел булуны саный.

Мәүла Колый тудырган лирик геройның кичерешләре гаять каршылыклы, аның күңеле һич тыныч түгел: ул эзләнә, бәргәләнә, бәхәсләшә. Болар, һичшиксез, авторның үз кичерешләреннән туган картиналар. Ул гомер үтүгә борчыла, картлык һәм яшьлек, үлем һәм яшәү турында уйлана. Шагыйрьнең бу хикмәтләрен «картлык лирикасы» дип атарга мөмкин.

ТАБЫЛГАН КУЛЬЪЯЗМАЛАР

1990 елда галим Раиф Мәрданов Әгерҗе районы Яңа Аккуҗа авылыннан Мәүла Колый әсәрләре теркәлгән кулъязма җыентык таба. Анда шагыйрьнең моңа кадәр билгеле булмаган ике поэмасы язылган: «Береккәннәр сыйфаты» (238 шигырь юлы) һәм «Хәләл нәфкъә эстәгәннәр сыйфаты» (66 шигырь юлы, текст тулы түгел).

Беренче поэма – сюжетлы әсәр. Эчтәлеге түбәндәгечә: бер ир белән хатын, үзара киңәшләшкәннән соң, дөнья мәшәкатьләрен читкә куеп, үз тормышларын бары Аллаһе Тәгаләгә гыйбадәт кыйлуга гына багышларга карар итәләр. Бер тауга барып, кечкенә генә гыйбадәтханә төзиләр, шунда гомер кичерә башлыйлар. Шулай 60 ел уза. Бервакыт Иблис боларга вәсвәсә сала. Алар, антларын бозып, дөнья күрергә чыгып китәләр. Бер шәһәр янындагы чишмә буена тукталалар. Ире ипи алыр өчен шәһәргә китә. Аннан кайтышлый ул бер мәһабәт сарай эчендә искиткеч гүзәл хан кызын күреп туктала. Икесенең дә күңелендә гыйшык уты кабына. Хатыны янына кайткач, ир хәлне аңлатып бирә. Шул урында берничә бит югалган, әсәрдә язылган кайбер хәлләр безгә билгесез кала. Ниндидер вакыйгалардан соң, хан кызы белән ирне тотып алалар һәм зинданга ябалар. Хатыны ирен эзләп сарайга килә. Иренең кайда икәнлеген белгәч, башынйөзен ике бөркәнчек белән каплап, ике табак ризык алып, зинданга бара. Бер табак аш белән сакчының күңелен яулап алып, зинданга керә. Башындагы бер бөркәнчекне хан кызына ябып, аңа буш табакны да биреп, чыгарга куша. Аулак җирдә табакларны ташлагач, сараеңа кайт та, тыныч кына йөр, дип, кызны өйрәтеп җибәрә.

Кызының нindидер ят ир белән тотылуыннан хурланган хан җәлладка тоткыннарны китерергә куша. Ир белән хатынны хан янына алып киләләр. Хатын йөзеннән бөркәнчеген алгач, боларның ир белән хәләл хатыны икәнлеген күреп, хан да, җәллад та хәйран калалар. Шулай итеп, ханның йөзе дә «ак» булып кала, ир белән хатын да җәзадан котыла. Өстәвенә, хан аларга күп итеп малбайлык та бирә.

Шагыйрь бу поэмасын береккәнлек, ягъни бердәмлек аркасында гына бәладан котылып, иминлеккә ирешергә мөмкин дигән фикер белән йомгаклап куя. Әсәр укучыларны бердәмлеккә өндәп, «берлектә – көч» дигән рухта тәмамлана.

«Хәләл нәфкъә эстәгәннәр сыйфаты» («Хәләл байлык теләүчеләр сыйфаты») поэмасының аз өлеше генә сакланган. Сакланган өлеше буенча фикер йөрткәндә, сүз хәләл ризык мәсьәләсенә генә кайтып калмый, аның иҗтимагый эчтәлеге күпкә тирән: әсәрдә «үзе бирмәз, үзгәләрдин тамигъ (ачкүзлелек) итүчеләр», комсыз кешеләр тәнкыйтьләнә:

Алма кеше малын тартып-орып,
Чәйнәмә аны агзыңа алыб тултурыб,
Рәхман тешне бирде хәләл йигәймү тиб, –
ди шагыйрь.

Мәүла Колыйның бу ике поэмасы табылу аның иҗат мирасын тулыландырды: аның хикмәт кебек кыска жанрда гына түгел, ә башка жанрларда да иҗат иткән киң колачлы әдип булганлыгын исбатланды.

Мәүла Колый иҗаты үзеннән соңгы татар поэзиясе үсешенә зур йогынты ясады. Мәсәлән, аңардан килә торган стилистик фигура һәм гыйбарәләрне XIX гасыр шагыйре Габделҗәббар Кандалый әсәрләрендә очратырга мөмкин.

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

Реклама 16+

Безнең Инстаграмда –
«Татарстан»ның йөрәге!

КЕШЕЛӘРГӘ ЯРДӘМ ИТҮЧЕ ВАКЫТЫН ЗАЯГА УЗДЫРАМЫ?

«Яхшы эшләр белән дан казанып булмый» – үзенең безгә яхшы таныш җырында мульфильм герое Шапокляк шулай дип җырлый. Ләкин ахырдан ул да бирелә – көненә бишәр яман эш эшләвеннән туктый һәм, «Афәрин, картлач! Дустыңны ташламадың. Яле, тегендәрәк кагыл!» – дип, миһербанлык ягына күчә. Чөнки изге эшләр эшләү барыбер күңеллерәк. Бигрәк тә әлеге гамәлең белән кемнеңдер хыялын тормышка ашырсаң...

ХЫЯЛ ӨЧЕН ТАУЛАР КҮЧЕРЕРГӘ КИРӘКМИ

Сукыр бала нәрсә турында хыяллана? Якты дөньяны күрергә дияр, күпләр. Әлбәттә, монысы – беренче чиратта. Ә тагын? Тагын... яраткан җырчысының концертына эләгергә!

Фото гаилә архивыннан алынды



Автор:
Руфия Фазылова

ЯЛГЫЗ АНА

«Татарстан» журналының Инстаграмына бер хәбәр килеп төште: «Тумыштан сукыр улымның бик тә Салават концертына барасы килә. Тик финанс мөмкинлекләребез чикле. Безнең кебек гади кешеләрнең хәлен йолдызлар белми шул…»

Хәбәр авторы – Чулпан Агадуллина икән. Биектау районының Дөбъяз авылында яшиләр. Гаиләдә дүрт кеше – Чулпан апаның әнисе, абыйсы һәм ана белән ул. Иң олы улының гаиләсе бар, аерым тормыш итәләр.

Чулпан апаның төпчек улы Азамат – тумыштан сукыр. Моннан кала да малайның бер бәйләм чире бар. Азамат – игезәк сыңары. Сабыйлар җитлекмичә, 26 атналык кына булып туган. Билгеле булганча, бу чорда әле баланың әгъзалары ныклап торып формалашмый. Азаматның төрле чирләре менә шуның белән бәйле дә инде.

– Мин күргәннәрне сөйләп аңлата торган гына түгел, – дип сөйләде ана. – Игезәкләремнең берсе 3 ай ярым гына яшәп калды. Ә менә Азамат яшәр өчен җаны-тәне белән тырышты. Без бармаган хастаханә калмагандыр. Күп табиблар: «Бу бала барыбер озак яшәмәячәк», – диде. Ә мин аның якты киләчәгенә ышандым. Хәзер дә ышанам.

Чулпан Агадуллина рәсми рәвештә беркайда да эшләми. Ни өчен икәне аңлашыла, дип уйлыйм, авыру бала тәрбияләгән анага кайдадыр эшләү мөмкин түгел дияргә дә була.

– Һөнәрем буенча югары белемле технолог мин, – ди ана кеше. – Азамат туганчы икешәр җирдә дә хезмәт куйдым. Ә хәзер булдыра алмыйм – улым миңа бик нык бәйле. Ярты көн өйдә булмасам, елый ук башлый. Аннан соң, Азаматка бөтен нәрсәне дә ашарга ярамый, махсус диетик ризыклар әзерлим. Ашказаны белән аерым проблемалар бар. Хәер, бездәге проблемаларны саный китсәң инде…

Азаматка 14 яшь тулган. Мәктәптә укымый, дисәң дә була, укытучылар өйгә килгәли икән үзе. Тик малайга уку нык авыр бирелә. Сукыр булуы өстенә, акыл үсешендә дә аерым кимчелекләре бар. Кешегә озак ияләнә, аерым әйберләрне кабул итә алмый.

Луи Брайль системасы буенча укырга өйрәнмәгән. Ни өчен дигәндә, беренчедән, авылда андый мөмкинлекләр юк, икенчедән, аның бармакларының тоемлау сәләте бик түбән. Шуңа үсмер малайны махсус мәктәпкә дә укырга алмыйлар.

– Азамат әле берничә ел элек миннән башка йөрми дә иде, – ди әнисе. – Бөтен җиргә икәү җитәкләшеп бардык. Хәзер инде, Аллага шөкер, үзе генә дә басып тора, йөри ала. Мин шуңа риза.

Малайның бердәнбер яраткан өлкәсе – музыка. Кәефе булганда, сәгатьләр буе җырлап, көйләп утырырга мөмкин ул.

Мин дә аның тавышын ишеттем. Шулкадәр сузып, моңлы итеп җырлый. Тик кеше алдында җырларга яратмый, ояла. Шуңа да, улына илһам килгән вакытларда, ана кеше кулына телефонын алып, тиз генә аны видеога төшерә.

– Азамат музыканы бик яхшы тоемлый, – ди Чулпан апа. – Җыр укытучысы да шулай диде. Менә шуңа да яхшы концертларга алып барырга тырышам. Оркестр концертларына да йөрибез. Бик бирелеп тыңлый. Ул аннан канатланып кайта. Тик безнең пенсия акчасына әллә ни күп йөреп булмый шул. Чакырсалар, сөенә-сөенә барабыз үзе.

«САЛАВАТ ҮЗГӘРГӘН...»

Ана кеше өч ел рәттән улын Сочига алып барган. Диңгез һавасы дип кенә түгел, дельфинарий булган өчен Краснодар краеның бу шәһәрен сайлаган ул. Аңлашыла ки, пенсиягә генә яшәүче гаиләгә ел саен диңгезгә бару шактый авыр. Шуңа күрә аңа ярдәм сорап шактый ишекләрне шакырга туры килә.

– Кул сузып йөрү бер дә рәхәт түгел, – ди Чулпан ханым. – Ә нишләмәк кирәк, бала өчен утка да, суга да керәсең. Сочидагы дельфинарийда инструктор белән йөзүнең бер сеансы 6000 сум тора. Нәтиҗәле булсын өчен дип, безгә ун сеанс алырга куштылар. Димәк, 60 мең сум акча кирәк. Менә шул акчаны кешеләрдән җыйдым. Үз машинам белән баргач, юлга әллә ни күп акча китми. Яшәү исә бушка. Беренче баруыбызда ук Сочидагы бер кунакханә җитәкчесе белән таныштык. Ул, безнең хәлебезгә кереп, акча алмады. Хәзер ел саен шунда барабыз. Дөресен әйтим, танышлар арасында яратып бетермәүчеләр дә бар. Янәсе, машина алганмын, ел саен диңгезгә йөрим. Мин аларны балам өчен эшлим. Коляскасыз өйдән чыгып китмим. Берәр җиргә баргач, күп йөрсә, Азамат арый. Андый вакытта аны коляскага утыртам. Ә Сочига килгәндә, дельфиннар белән бергә йөзү Азаматка бик килеште. Ул хәзер курыкмый, кеше алдында да үзен тыныч тота.

Сүз башы бит Салават концерты иде. Азаматның хыялы тормышка ашты – яраткан җырчысының концертын тамаша кылды ул. («Салават» җыр театры админстраторы Вадим Фәтхинуровка шалтыраттым. Вадим, берсүзсез, ана белән улны концертка кертәбез, диде. Бактың исә, Салават Зәкиевич көн саен шулай авыру балаларга берничә урын калдырырга куша икән).

Концерттан Чулпан Агадуллина бик тәэсирләнеп кайткан. Улының хыялын тормышка ашырганыбыз өчен рәхмәт әйтеп шалтыратты ул.

– Йә, ничек, ошаттыгызмы? – дидем.

– Салават нык үзгәргән, – диде әни кеше.

– Кайсы якка? – дим.

– Начар яки яхшы якка, дип әйтә алмыйм. Ул – бүтән. Азамат белән җиде ел элек Салаватның концертында бер булган идек. Һич онытмыйм: ул чакта тамаша төнге 12нче яртыда тәмамланды. Салаватта энергия ташып тора иде. Һичшиксез, килгән тамашачы концерттан үзенә дәрт алып кайтып китте.

– Быел алай булмадымы?

– Хәзер Салаватта тирәнлек барлыкка килгән. Концерт программасы да фәлсәфи итеп төзелгән: яшәү белән үлем көрәшә. Яшь барган саен кеше тормыш кыйммәтләрен башкачарак күрә башлый бит. Яраткан җырчыбызда да бу ачык сизелә. Минем күңелгә хәзерге Салават якынрак. Тамашачылар да яхшылык кылу, кеше булып яшәү турында уйланып кайтып киткәннәрдер, дип уйлыйм.

Чулпан апа тагын бер кызык чагыштыру китерде. Җиде ел элек Салават концертына республиканың төрле районнарыннан әниләре белән егермеләп авыру бала килгән булган. (Артист билетларны шулай ук бушка биргән). Тик ул вакытта җырчы балалар янына чыга алмаган. Ә быелгы концертта ул авыру балалар белән кочаклашып фотога да төшкән, рәхәтләнеп аралашкан. Хәтта аларны сәхнәгә дә чакырган. Чулпан апа моны да үзенчә аңлата:

– Ир-ат авыру баланы кабул итә алмый, табигате шундый. Ничек инде аннан туган бала чирле була ала? Шуңа күрә андый вакытта күп ирләр гаиләдән китә, чыдый алмый. Һәм аның шулай булуы яхшырактыр да, югыйсә хатын-кыз, авыру баласы белән беррәттән, тормыш авырлыклары алдында җебеп төшкән ирен дә карар иде. Ә болай ул юк, димәк, яшәргә дә комачауламый. Авыру балаларын ялгыз үстерүче әниләргә дә гел шулай дим. Бик көчле ир-атлар гына андый хәлне кабул итә, гаиләдә кала, хатынына ярдәм итә. Салават Зәкиевичка да җиде ел элек авыру балалар белән аралашырга авыр тоелгандыр. Гәрчә үз балалары булмаса да. Әйткәнемчә, быел ул бүтән, аңарда аксакаллар холкы күренә башлаган. Авыру балаларның күңелен күргәне, бүләкләр биргәне өчен Алланың рәхмәте яусын! Гаиләсенә, үзенә саулык, иҗат уңышлары телим.

...Яхшы сүздән дә күңел була, ди халык. Әйе, кемнедер бәхетле итү өчен таулар күчерергә кирәкми. Авыруларга карата гына, димим, күршедәге, янәшәдәге кешеләрне дә күздә тотам. Кем өчендер буй җитмәслек хыял булып күренгән эш, безнең өчен гади генә булырга мөмкин. Азамат очрагы да шулай килеп чыкты. Бер шалтырату үсмер баланың хыялын тормышка ашырды. Сез дә яхшы гамәл эшләп карагыз. Рәхмәт ишетүдән дә рәхәте юк!

Фотолар Салават Фәтхетдиновның «Инстаграм»ыннан алынды

ЯХШЫ КӘЕФ БҮЛӘК ИТҮ – ҺӘРКЕМНЕҢ КӨЧЕННӘН КИЛӘ

Вадим Фәтхинуров, «Салават» җыр театры администраторы:
– Салават Зәкиевич һәр концертына авырулар, мохтаҗлар өчен урыннар калдыра. Бу күптәннән шулай куелган. Дөресен генә әйткәндә, аңа бик күпләр ярдәм сорап мөрәҗәгать итә, кайберәүләр аның концертына эләгергә хыяллана, чөнки җырларын яраталар. Аларның барысына да ярдәм итү мөмкин дә түгелдер. Ләкин шатлык өләшү, яхшы кәеф бүләк итү – һәркемнең көченнән килә.

ХЫЯЛЛАР ЧЫНГА АШКАНДА

– Хыялларыңның чынга ашуы – бик күп шатлыклы мизгелләр алып килә һәм син яшәүнең ни дәрәҗәдә бәһасез икәнлеген аңлыйсың. Шуңа күрә киләчәктә дә хыялланырга, башкаларга да хыялланырга ярдәм итәргә кирәк, – дип уйлый хыяллары чынга аша торган Ләйсән Сәетназарова.



Ләйсән тумышы белән Чаллыдан. 7 яшендә аның баш миендә яман шеш табалар. Шул вакыттан башлап кыз берничә операция һәм химиотерапия курсын үтә, ләкин авыруны җиңеп булмый. Хәзер аңа 21 яшь, сул колагы бөтенләй ишетми, уң колагы 30%ка гына ишетә. Күзләре начарлана, хәтере югалып ала, ләкин терелергә дигән өмете сүрелми.

Ләйсән һәм аның әнисе Әлфия бу соңгы ярты елда Анжела Вавилова исемендәге балалар хосписында яши. Монда килгәч, битараф булмаган кешеләр тырышлыгы белән, кызның хыяллары бер-бер артлы чынга аша башлаган.

Автор:
Алёна Кутыркина

ЮЛБАРЫС БАЛАСЫН СЫЙПАРГА

– Май аенда хосписка Андрей Малаховның тапшыру төшерү төркеме килде. Малаховның ярдәмчесе – журналист Александр Козявин, безнең белән шактый вакыт бергә булды, Ләйсән аңа үз хыяллары турында сөйләде, – ди Ләйсәннең әнисе Әлфия Сәетназарова.

Бер айдан соң палатада могҗиза була. Хосписка яңадан репортерлар килә, ләкин бу юлы алар үзләре генә түгел: юлбарыс баласы белән! Дрессировщик Михаил Зарецкий Ләйсәннең палатасына, сыйпап карасын, дип, Лилу исемле юлбарысны алып керә.

– Юлбарыс баласы белән очрашу мизгелен мин беркайчан да онытмам. Бу минем өчен көтелмәгән могҗиза булды, бөтенләй дә мөмкин эш дип уйламаган идем. Лилуны палатага алып кергәч, барлык хисләрем бергә кушылды: шаккату, сөенеч, бәхет тә, – дип сөйли җанланып киткән Ләйсән. – Юлбарысның балалары да шундый зур икән. Ай ярым гына булса да, ул шактый гәүдәле иде. Лилу минем белән уйнады, иркәләнде, мин үземне бик бәхетле итеп тойдым!

Миша абый (юлбарыс баласының хуҗасына Ләйсән шулай дип эндәшә хәзер. – Ред.), кызның чын дустына әйләнә. Алар телефоннарын алыша, дрессировщик хәзер Ләйсәнгә көн саен Лилуның фото һәм видеоларын җибәреп тора. Юлбарыс баласы ай үсәсен көн үсә! Ә кыз яңа дустына үзенең хәлләре турында сөйли.

ДИМАШ БЕЛӘН ОЧРАШУ

– Бу җәйдә бер генә түгел, берничә хыялым чынга ашты. Башта мин искиткеч кешеләр, юлбарыс баласы белән таныштым, ә аннары кумирым – Димаш белән очрашу насыйп булды.

Танылган казах җырчысы Димаш Кудайбергенов Ләйсән турында Малаховның «Күз яшьләре белән хыяллар» дигән тапшыруын төшергәндә белеп ала. Шулвакыт ул кыз өчен видеосәламләү яздыра, аны Ләйсән үзенә бүләк ителгән телефон аша карый. Ә бераз соңрак, WordSkills Kazan 2019 чемпионаты ярдәмендә, башкаручының тыгыз графигында Татарстан башкаласы барлыкка килә.

– Ул хосписка ябылу тантанасы башланырга сәгать ярым вакыт калганда килеп керде. Кунак турында мин алдагы көнне белдем, кызыма әйтмәдем, сюрприз ясыйсым килде, – дип сөйли Ләйсәннең әнисе.

Кыз да сүзгә кушыла:

– Ниндидер гадәти булмаган вакыйга булыр, дип сизенгән идем. Очрашу көненә каршы төндә төшемә Димаш керде, ул минем өчен иртәнге сәгать 4кә кадәр җырлады. Шуңа күрә йокым да туймады, ләкин ниндидер

Фото: Виктор Ежов

могҗиза көтү халәтендә идем. Әнинең дә палатаны башка төрле итеп җыештыруына, бизәнүенә игътибар иттем… Мин аннан сорадым да әле: «Әни, син бүген нишләп шундый матур соң?», – дип. Әни: «Кәефем яхшы, шуңа гына», – диде, һәм башыма Димашның фанатлар төркеме бүләк иткән казах яулыгын бәйләргә кушты.

Очрашу вакытында кыз да, җырчы да югалып кала. Ләкин беренче дулкынлану хисләре тынгач, алар ихлас күңелдән утырып сөйләшәләр.

– Ул килеп кергәч, югалып калдым, җанымны кая куярга белмәдем. Үземә-үзем: «Ләйсән, тынычлан, барысы да яхшы, кычкырма, тирән сула», – дип пышылдадым. Минем аңа бармак очлары белән генә кагылып карап: «Ул тере, ул монда!» – диясем килде. Сәер булып күренмәс өчен, үземне тыйдым инде, – дип көлә Ләйсән. Мин аннан ничек шундый гаҗәеп башкару осталыгына ирешүе турында сорадым. Ул миңа 5 яшьтән җырлый башлавы, ата-анасының һәм дусларының иҗади кешеләр булулары һәм һәрвакыт аңа ярдәм итүләре турында сөйләде.

Кызның караваты янында хәзер автографлы Димаш портреты эленеп тора. Казах теленнән тәрҗемәсе дә эчкерсез гади: «Ләйсәнгә, сәламә, хөрмәт белән Димаштан».

– Аның тавышын мин беренче тапкыр 2017 елда ишеттем, Кытайда чыгыш ясавы иде. Бу тавыш һәм башкару рәвеше мине таң калдырды, ләкин мин аның исемен истә калдырмадым һәм аннары таба да алмадым. Ә быел мин аны тагын күрдем һәм тыңлый башладым. Аның җырлавы, хисләрен белдерү үзенчәлеге, тавышының мөмкинлекләре – барысы да минем күңелемә тынычлык бирә.

СӘЛАМӘТЛӘНЕРГӘ!

– Ләйсән икенче класста укыганда чирли башлады, шуннан соң без вакытыбызның күп өлешен хастаханәләрдә үткәрәбез, – дип сөйли Әлфия. – Безнең өчен кызыбызның исән булуы һәм тормыш өчен көрәшүе – үзе зур бүләк һәм уртак хыялыбызның чынга ашуы.

– Иң зур хыялым – терелү, бу катлаулы һәм озын юл, – ди хыяллары чынга аша башлаган кыз. – Ләкин мин сәламәтләнүемә ышанам. Хыял чынга ашканда, үзеңне бәхет канатларында очкан кебек хис итәсең. Хәзерге вакытта минем кебек үк хыялланучыларга теләгем шул: хыялланыгыз, бөтенләй чынга ашарлык булмаса да, хыялга омтылыгыз, башкаларга да үз теләкләрегез турында сөйләгез, чөнки ярдәм итә алырлык кешеләр гел очрап тора.

ҮЗ ФАНАТЛАРЫНЫҢ ФАНАТЫ

Димаш белән элемтәгә керергә аның Самарадагы фанатлары ярдәм итте. Алар кумирларының чыгышын карарга дип, WorldSkills Kazan 2019 чемпионатының ябылу тантанасына башкалабызга килгәннәр иде. Чыгышы алдыннан Димашның Казан хосписына барып, анда яткан Ләйсән исемле кызның күптәнге хыялын тормышка ашырачагын да алар беренчеләрдән булып белделәр. Һәм аны борчымаска тырыштылар. Шуңа күрә «Татарстан»ның сорауларын үзләренең «ВКонтакте»дагы төркемнәре аша юлладылар. Җавапларны концерт тәмамлануга ук алдылар. Димаш – үз фанатларының фанаты – озак көттермәде.

– Димаш, сез ни өчен Казан хосписындагы кыз янына барырга булдыгыз?
– Мин башкача булдыра алмыйм. Минем иҗатымны үз иткәннәргә бик зур хөрмәт белән карыйм. Мин бит үз фанатларымның фанаты.

– Үзеңне кемнеңдер тормышка ашырылган хыялы итеп сизү ничегрәк?
– Үземне кемнеңдер тормышка ашырылган хыялы яисә йолдыз итеп сизмим. Йолдызлар – күктә, ә мин – гади кеше, тик бераз җырлый белүче. Без барыбыз да бу дөньяга, иң беренче чиратта, кеше булыр өчен, зур хәрефтән язылырлык Кеше булыр өчен килгәнбез, бары тик аннан соң гына җырчы, укытучы, табиб һәм башкалар булабыз.

Югарыда аталганнарга өстәп, фанатлары үзләренең кумирын бик тыйнак егет диләр, беркайчан да үзе эшләгән игелекле эшләр турында сөйләмәс. Ул уңайсызланып җилкәләрен генә җыерачак. Ә күркәм эшләрне ул күп эшли. Үз туган көнендә, тамагы авыртып килеш, шау-шуларсыз гына картлар йортына барып, өлкәннәр каршында акапелла җырлаган җырчыларны күп беләсезме?

Җилкәннәр илтә сафлыкка

Идел, дулкыннар, җилкәннәрне сынаган җил һәм спорт дәрте... Регата бу! Һәм гади генә ярыш түгел – үзенчәлекле! Татарстан Республикасы Ресоциализация фонды кубогына җилкәнле регатада наркотик һәм алкоголь бәйлелектән котылу юлына басучылар ярыша. Җилкәннәр киереп җиңүгә омтылу ничегрәк икән ул? «Татарстан» узышның «пәрдә артын» карарга җөрьәт итте.

Автор:
Алсу Троицкая

Фото: Александр Ефремов

Шулай итеп, жирәбә салынды, ачылыш тантанасы тәмамланды. Экипажлар үз яхталарына ашыга: кызыллары «Хантер»-га, зәңгәрләр – «Масяня»га. Сарылар «Галс»ны, кызгылт-сарылар – «Шаман»ны, аклар – «Витязь»не иярли, ә яшелләр исә «Печенег»ны өйрәнеп ята. Ярышлар өчен шартлар идеаль диярлек: шактый җылы көн, кояш, җиле дә туры килеп тора. Алга – күтәренке кәеф кочагына!

Данияр Максудов, ТР Ресоциализация фонды җитәкчесе:
– Регата – күңелне уятып, терелтеп җибәрүнең менә дигән ысулы. Бу – шәп компаниядә энергия туплау һәм вакытны кызыклы итеп уздыру мөмкинлеге. Нормаль тормышка әйләнеп кайту чорын узып ятучылар өчен «ял итү» төшенчәсе юк. Башка төрле, хәзерге тел белән әйткәндә, «экологик» гамәлләргә тартылу тәүлегенә 24 сәгать булырга тиеш. Бирелә, регатада, без егетләргә-кызларга идеаль экологик ялның әзер рецептын тәкъдим итәбез: су, дулкыннар, кояш, рухы белән сиңа якын кешеләр һәм, әлбәттә, спорт дәрте.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының «Республика наркология диспансеры» ДАССУ баш табибы Илгиз Әхмәтҗанов:
– Ике тапкыр кубәюебезгә сөенәм – былтыр өч команда иде, бүген алар алтыга җитте. Барыгызның да актив катнашуын һәм җиңүләр телим!

Регата маршруты Казан һәм Югары Ослан арасыннан уза. Бүгенге регатаны – нәрсә генә дисәң дә тәҗрибәсез дилетантлар катнаша торган ярышларны оештыру – җаваплы процесс. Һәм монда күп нәрсә капитаннардан тора. Алар команданы туплый белергә, тәҗрибә уртаклашырга һәм яңа егет-кызларны җилкәнле спортка җәлеп итәргә сәләтле кешеләр.

Старт алдыннан дистанциянең судьясы Рөстәм Сөләйманов көймәсендә урын алабыз. Моннан капитаннарның әмер-фәрманнарын экипажлар ничек үтәгәне – җилкән белән «җил ауларга» маташулары яхшы күренә. Һәр яхта капитанының бурычы исә старт мизгелендә, сары старт маягы һәм судьялар катеры арасындагы уйдырма сызыкка ничек тә якынрак булуга кайтып кала. Якынрак булган саен, старт шулкадәр уңышлырак санала.

«Картер-30» судьялар катерында флаг күтәрелгән – узыш вакыты санала башлый. Арбитрлар – баш хөкемдар Владимир Баленков һәм дистанция хөкемдарлары Рамил Котдусов, Рөстәм Сөләйманов.

Узыш дәрте аркасында экипажларның берничә сәгать киеренке эше сизелмичә дә үтеп китә, тиздән – финиш.

Ярышның җиңүчесе булып «Витязь» яхтасы – «Яңарыш» тернәкләндерү үзәге командасы (Республика наркология диспансерының 5 нче бүлеге) танылды. Экипаж тулы составта Ресоциализация фондының призларын алырга юл тота. Ә фондның җитәкчесе Данияр Максудов, бернинди икътисадый давыл һәм кризисларга карамастан, бу яхшы гадәтне дәвам итәргә һәм регатаны киләсе елда да уткәрергә вәгъдә бирә.

Ә аннан соң – яр буенда программа, ул да гаять мөһим. Беренче чиратта, аралашу турында сүз бара. Узышчыларның күбесе әнә шуның өчен бирегә икенче ел рәттән әйләнеп кайта да инде.

БӘЙЛЕЛӘР ТАРИХЫ

«АЙНЫТКЫЧ ЙОЛДЫЗЫ»

– Минем исемем Алинә. Мин эчкече. Хәмер куллану стажым – 16 ел. Элек, башкалар кебек үк, кичәләрдә, туган көннәрдә эчтем. Тик бер «ләкин» бар. Нык эчтем. Икенче көнне булган кәефсезлек, аңышмый йөрүләр дә мине туктатмады.

Шундый вакытлар була иде: киенәм-ясанам да клубка юл тотам. Үземчә хәмерне дә нормаль күләмдә генә кулланам кебек, тик айныткычта уянам. Үкчәле туфлидән, матур күлмәктән. Айнытычтагы йолдыз, диярсең!

Дәвалауның һәм реабилитацияләүнең дүртенче омтылышы гына хәмергә бәйлелекне «стенага тери алды». Бүген мин инде берничә ай «чиста» яшим. Тормышым тамырдан үзгәрә...

Бүген автобуста барам. Кояш елмая. Мин аек. Бәйлелектән котылуның Аллаһыга якынаюда һәм кешеләргә хезмәт итүдә булуы турында лекция тыңлыйм. Шулчак башыма бер уй килә: «Ә нигә әле мин үземне кемгәдер багышларга тиеш?» Аннары исә бөтен нәрсәм – яшьлегем, балам, ирем, ата-анам, акчаларымны хәмергә биргәнемне, хәмергә багышлаганымны искә төшерәм. Һәм хәзер миннән бик аз нәрсә – үзем кебекләрне яңадан ярата, ышана башларга өйрәтү, аларга менә шул эштә булышу гына таләп ителә. Гайре табигый бернәрсә дә юк. Һәм миңа бу уйлардан шулкадәр рәхәт булып китте. Сәламәтләнү юлым шулкадәр күңелле бара!

«БУ СОҢГЫ ТАМЧЫ ИДЕ ...»

– Наркотикларга бәйле кеше булып 27 ел яшәдем. Барысы да 14 яшьтә хәмердән һәм җиңел наркотиклардан башланды. Башта ярдәме тиген кебек – кызлар белән мөнәсәбәтләр кору, уртак мәнфәгатьләр табу җиңел булды, кирәкле элемтәләр җайланды. Аннан тормыш фаҗигагә әверелде. Син уңышлы, сәламәт егеттән кимчелекле кешегә әйләнәсең икән, бу – зур бәла. Ничектер иртән уяндым да хатынымның әбием белән сөйләшүен ишеттем. Әби минем әле исәнме-юкмы икәнлегемне сорый, чынлап, җитди итеп сорый. Бу соңгы тамчы булды...

Аннары детокс процессы, реабилитация үзәге... Хәзер мин хәмер һәм наркотикларны инде дүрт елдан артык кулланмыйм. Шушы аеклык чорында кызым туды. Гаиләне саклап калдым, дөресрәге, аны хатыным саклап калды, моның өчен мин аңа бик рәхмәтле.

Икенче югары белем алам. Консультант булып эшлим. Наркотикка бәйлеләргә ничек ярдәм итәргә икәнен беләм, моны эшли алам. Аларга шуны әйтергә телим: килегез, дәваланып була! Иллюзияләрең һәм куркуларың артына качмаска гына кирәк.

«АНЫ УТЫРТЫРГА ТҮГЕЛ, Ә ДӘВАЛАРГА КИРӘК»

– Миңа 29 яшь. Бишенче ел «чиста» яшим. Тернәкләндерү үзәге хезмәткәре булып торам, кешеләргә теләсә нәрсә кулланмыйча да шатланып яшәргә мөмкин булуы турында үз тәҗрибәм, белемем, идеяләрем белән булышам. Һәм мине моны булдырам да, чөнки бу өлкәдә инде – шактый күптән...

Ул вакытларда минем өчен нәрсә һәм ничек куллану мөһим түгел иде, булсын гына. Мин яхшы гаиләдә үстем. Әни-әти, әби-бабай – барысы да бар. Аттестатта да – бишлеләр генә. Ул хәлләргә ничек таруымны әлегә кадәр аңлап бетермим. Чынлыкта, тирәнгәрәк кереп уйласаң, мөгаен, бераз төшенәсеңдер: өйдә әни ягыннан ныклы контроль булды. Кеше мактарлык, яхшы малай дип әйтерлек итеп тырышып укырга кирәк иде. Соңыннан боларның барысыннан да туйдым, аннары исә китте дә китте...

Әни миңа мондый бәйлелекне җиңүдә ярдәм итәргә бик теләде. Судта: «Бу егет авыру. Аны утыртырга түгел, ә дәваларга кирәк...», – диде, ул, әлбәттә, елады. Хәлиткеч фикер исә элеккеге тормышка әйләнеп кайтырга теләмәвем булды. Шулай итеп, реабилитация үзәге, яраткан әнием һәм, сүз уңаеннан, хөкемдар, минем тормышымны үзгәрттеләр, аны баштанаяк кирегә бордылар. Хәзер тормышымны экологик чиста «бәйлелекләр» һәм кызыксынулар белән тулыландырып яшим.

БИЧУРАЛАР... БЕЗ ТҮГЕЛМЕ?

Яңа уку елы башланды, аның белән бергә – балалар, яшүсмерләрнең дә, укытучылар, әти-әниләрнең дә шатлык-куанычлары, борчу-хәсрәтләре, хыял-өметләре, омтылыш-канәгатьсезлекләре... Гел шатлыктан һәм наз-яратудан, уңыш-казанышлардан гына тормаган Балачак дөньясына моңсу, ләкин гыйбрәтле сәяхәт ясыйсы килә бу санда. Яңа яшь авторның сискәндергеч романы аша.

Автор:
Луиза Янсуар

ВАКЫТЛЫ ҺӘМ УРЫНЛЫ

Балачакта «Чучело» фильмын карап үскән буын вәкилләре өчен бу роман әллә ни гаҗәп булып тоелмастыр. Валерия Гай Германиканың зур резонанс тудырган сериалын караучыларга – бигрәк тә. «Аяусыз балачак» темасына язучылар элек тә бар иде, алга таба да булачак, әлбәттә. Бу – классика, диярсез. Шулай да Евгения Некрасова әсәре, үз чорының җан авазы буларак, аерым игътибарга лаек. Юкка гына ул «Роман поколения» сериясендә дә дөнья күрмәгән.

Аның асылы – балалар дөньясын җимерүче һәм аяусыз итүче олылар турындагы тылсымсыз әкияткә генә кайтып калмый, ә күпкә катлаулырак, тирәнрәк. Ул безне бүгенге социаль-мәдәни халәт турында гына да уйландырып калмый, ә ераккарак алып китә – тамырларга, беренчел чыганакларга. Кешелек дөньясы яралган, яратылган чагында алган җәрәхәтләргә, яраларга.

Елена Шубина редакциясендә дөнья күргән әлеге әсәр – психологик проза жанры кысаларына караган, шул ук вакытта мифология, фольклор катламнарына үтеп кергән, Россия прозасында магик реализм ноталарын көчәйтеп җибәргән, балалар телен өр-яңадан ваемларга омтылган кызыклы эксперимент ул. Һәм, әйтергә кирәк, гаять вакытлы, урынлы эксперимент.

Әсәр зур түгел, тыгыз һәм динамик эчтәлекле. Әмма аңарда социаль яктан да, фольклор ягыннан да эпиклыкка йөз тоту күзгә ташлана. Гаҗәеп тере, урыны-урыны белән сискәндереп, чиркандырып куя торган реалистик дөнья картинасына нигезләнгән булуга карамастан, искиткеч нечкә-лирик та, фәлсәфи-мифик та итеп өретелгән, тәртипсезлек, хаос тәэсире калдыруга юнәлтелгән булса да, бик җентекләп, ыспайлап эшләнгән ул. Хәтта эшкәртелгән, дияргә дә мөмкиндер.

Евгения Некрасованың тагын бер казанышы – романның теле. Бу – өлкән кешенең, язучының теле түгел, ә нәкъ менә каһарманнарның теле. «Кечкенә кешеләр»нең уйлары, кичерешләре, эчке архитектоникасы. Шуңа ул коточкыч мантыйксыз да, бер үк вакытта, балачакның үзе, башлангычның асылы кебек, шаштырыр дәрәҗәдә дөрес, хакыйкый да. Аның үз сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре бар, бу логиканы кабул итү дә, ин-

Фотолар: www.livelib.ru, www.goodfon.ru сайтларыннан алынды

карь итү дә – ситуациядән чыгу юлы түгел.

Дөнья әдәбиятында бу темага күпкә радикальрак әсәрләр дә бар, дияр кайберәүләр. Әйтик, шул ук Митч Каллинның «Страна приливов» романы, аңарчы күпкә алданрак дөнья күреп, классик мисалга әверелгән Стивен Кингның «Кэрри» әсәре. «Калечина-Малечина» бүгенге Россия мохитен, бездәге кечкенә дә, дәү дә микрокосмослар – гаилә һәм мәктәп психологиясен микроскоп астына куеп сурәтләве белән үзенчәлекле. «Менә без нинди» дигән ноктадан хикәяләве белән әһәмиятле.

«ҺӘР БАЛАДА ӘКИЯТ ЯШИ!»

Китапның буеннан-буена без вакыйгаларга аның төп персонажы – бәләкәй Катя күзлегеннән карыйбыз, бәя бирәбез, кичерәбез… Һәм иң әһәмиятлесе: сөйләшәбез. Бу тел – үзе бер шөкәтсезлек үрнәге дә, бер үк вакытта мәгънәләр, төсмерләр уенына, биюенә корылган поэзия дә! Бәләкәй генә гомере эчендә иң авыр, авырттыргыч хәлләрдән: «Катя катится-колошматится», – дигән сүзләр магиясенә сыенып котыла торган кечкенә кызның мифопоэтик дөньясына кереп күмелүгә, бу дөньяның ни дәрәҗәдә бай булуына, курку һәм ямь белән тулы икәнлегенә инанабыз. Гәрчә, өйдә әтисе белән әнисе аны кадерләмәсә, барлыгын ук онытса да, мәктәптә үзен «чүп» урынына гына күрсәләр дә, укытучылар җәберләсә, хәтта «акылга зәгыйфь» дип тапса, күрәләтә торып мыскылласа да…

Һәр балада Тылсым яши! Әкият! Әнә шул хакыйкатькә илтә безне фабула чытырманнары, диалоглар һәм монологлар психологиясе аша автор.

Сыйныф диварында эленеп торган сәгать дәреснең азагына кадәр нибары 8 минут калуын хәбәр итте. Катяның йөрәге сикереп чыгардай булып тибә башлады, башында, әйтерсең, барабан кагарга керештеләр. Аңына килә алмыйча, ул дәфтәрендәге саннарга һәм математик билгеләргә карап торды да торды: ничек аларны бер тәртипкә китерергә?! Бу чып-чын һәлакәт иде. Әмма акрынлап Катяны ләззәтле-татлы ирек тойгысы били башлады. Бу тойгы иң авыр халәтләрдә барлыкка килә һәм коткара, гадәттә. Өметсезлек акрынлап чигенде, ул әле чишәргә өлгермәгән мәсьәләләр дәфтәр битендә яңадан багана булып үсеп чыкты, аермачык күренә башлады. Йөрәге уйнаклап тибәргә кереште, башында коточкыч тизлек белән әйләнеп йөргән яшен ташы туктап калды һәм җиңеллек китерде. Катяның иренәнә елмаю кунды хәтта. Моны абайлап алган укытучысы Вероника Евгеньевна борчуга төште, урыныннан кубып, Катяның партасы янына ук килеп басты. Әмма кызның дәфтәренә күз төшергәннән соң тынычланды: кәгазьдә дөрес җавапка охшаш бер генә нәрсә дә күзенә чалынмады.

Ә ул арада Катя тыңлаусыз саннарны бөтенләй башка эшкә җикте:

Одну тысячу девятьсот
восемьдесят четыре
Поделить
На шестнадцать
Равняется – я одна в квартире.

Двести тридцать шесть
Умножить
На семьдесят три
Равняется – на часы не смотри.

Двадцать тысяч ноль ноль ноль
Плюс
Четыре тысячи двести девять –
Всё равно вечера не боюсь.

Девятьсот
Минус
Одиннадцать
Равно –
Время убежало давно.

Акрынлап шәһәрнең «йокы район»нарының берсендә, гадәти йортның 11 нче катында яшәүче, иң гадәти мәктәпкә укырга йөрүче Катяның дөньяны әнә шулай башка төрле итеп күрүе әсәрнең магик катламына алып чыга. Шул катламга атлап чыкканнан соң, кызчык инде үзенең япа-ялгыз булмавын аңлый: аның иптәше һәм яклаучысы табыла. Ул яклаучы… Бичура булып чыга! Һәм бу кешеләр тарафыннан читкә тибәрелгән, хәшәрәткә тиңләштерелгән ике ялгызак зат берләшеп ала да дөньяда яшәргә хокуклы булуларын раслый башлый. Алай гына да түгел, аны төзәтергә һәм үзгәртергә керешә! Олылар галәмендә ниндидер механизмнарның дөрес түгеллеген акылы белән ваемламыйча, әмма интуициясе, күңел сизгерлеге белән тоеп…

Олылар җаваплылыкны үз өстенә ала һәм төзәтә алмаган дөньяны балалар төзәтә алырмы? Бу сорауның безнең җирлек өчен тетрәнгеч дәрәҗәдә актуаль булуын күрсәтә автор. «Невыросшие» исәбендә йөргән балаларның кайберләре «выросшие» сафындагы өлкәннәрдән акыллырак, зирәгрәк тә, кешелеклерәк тә икәнлеген раслый. Әмма без үзебез җәрәхәтләгән һәм кул селтәгән балалар төзәтүнең нинди ысулларын кулланыр да нинди нәтиҗә чыгарыр? Кемнәрне тәрбияләвебез, безне кемнәр тәрбияләгәнгә шушындый булуыбыз турында менә бүген, әлеге мизгелдә үк уйлана башларга өнди язучы. Иртәгәге көннең нәкъ хәзер хәл ителүен искәртә…

Евгения Некрасова – сценарийлар авторы, прозаик. 1985 елның 2 апрелендә Әстерхан өлкәсендә Капустин Яр шәһәрендә дөньяга килә. Мәскәү янындагы бистәләрнең берсендә үсә. Мәктәпне тәмамлагач, Мәскәүдәге Яңа кино мәктәбендә укый. Англиядә, Грециядә яши, аннары кире Мәскәүгә кайтып урнаша. Күпсанлы газета-журналларда басыла. «Бәхетсез Мәскәү» (2017) дип исемләнгән хикәяләр циклы «Лицей» премиясе финалисты дип табыла.

2018 елда басылып чыккан «Калечина-Малечина» романы әдәби мохиттә зур резонанс уята, вакыйга буларак кабул ителә. Ул 2019 елның «НОС» милли премиясенең, Милли бестселлерлар исемлегенең һәм «Большая книга»ның шорт-битләрендә урын ала. Быелгы китап сезонының алыштыргысыз фаворитлары исәбендә йөри, китап фестивальләре буйлап сәяхәт итә.

Евгения Некрасова бу әсәрен башта сценарий, пьеса буларак яза башлый. Соңыннан проза буларак тәмамлый.

Евгения Некрасова иҗатын «социаль магизм» жанрына карый, дип табалар. Язучы үзе болай җавап бирә: «Миңа чынбарлык белән турыдан-туры эшләү кызык түгел, ә менә аңарда тылсымлы, әкияти элементлар пәйда булса, шул чакта чып-чын хәрәкәт башлана».

Язучы фольклор белән бик нык кызыксына. 2019 елда ул Коломна әкиятләрен туплап, яңа әсәр иҗат итү белән мәшгуль булды. Иҗат эшенә баштанаяк күмелер өчен, бер аен «Арткоммуналка. Ерофеев и другие» музей-резиденциясендә уздырды.

2019 елда Елена Шубина нәшрияты Евгения Некрасованың тагын бер китабын бастырып чыгарды. «Сестромам: о тех, кто будет маяться» дип аталган бу китап та «Роман поколения» сериясендә дөнья күрде. Тәнкыйтьчеләр аны «рус космизмының шаманнарча чагылышы» дип атады.

Евгения Некрасовадан гыйбрәтле гыйбарәләр:

- Тарихны сөйли белү – ул бер нәрсә, ә укучыда халәт тудыру – бөтенләй икенче. Язганда, син нәкъ менә шул халәтне тудырырга тиешсең: укучың куркырга тиеш, аңа читен булырга, елыйсы, йә көләсе килергә. Әмма монда спекуляция куркынычы яный. Бу бик нечкә чик.
- Мин безнең әдәбияттагы арыган һәм берөзлексез аракы чөмерә торган ир-атлар турындагы китаплардан туйдым.
- «Хатын-кыз прозасы» «хатын-кызныкы» булудан туктады, ул бары тик прозага әйләнде, ниһаять. Көчле, колачлы һәм сыйфатлы.
- Балалар һәм үсмерләр олылар укый торган китапларның каһарманнары булырга тиеш. Олылар үзләрен онытмасын өчен.
- Нормаль гаилә һәм нормаль тормыш турында кем дә булса әйбәт китап бастырып чыгарса, менә ул Россиядәге иң көтелгән супер роман булачак, минемчә. Үзем бу хакта ничек язарга икәнен белмим. Мин гомумән нормаль тормышны белмим.
- Америка авторлары үзләренең чынбарлыгын бик яхшы тоемлый һәм ваемлый. Аның турында ачыктан-ачык язарга да курыкмый. Югыйсә без дә шундый ук бит: коточкыч зур ил һәм ул илдә коточкыч күп проблемалар.
- Магик реализм гадәттә яшәү дәрәҗәсе бик үк әйбәт булмаган һәм дәүләт үз халкын кайгыртмаган илләрдә чәчәк ата, шуны онытмыйк. Ә мондый шартларда бердәнбер барып сыену, йә котылу чарасы – ул могҗиза.

Быелгы «Большая книга»ның шорт-битенә эләккән романны «олылар өчен әкият» дип атап йөртәләр.

«КЕЧКЕНӘ КЕШЕЛӘР»НЕҢ ЗУР ФАҖИГАСЕ

Без һәр адымда диярлек гаджетларга төбәлгән сабыйларга, үсмерләргә юлыгабыз. Алар, әйтерсең, икенче бер галәмнән карый. Әмма виртуаль галәмгә аларны күчерүчеләр – без бит үзебез. Игътибардан, кадер-наздан мәхрүм итүчеләр дә. Шулай җайлырак, шулай чыгымсызрак. Утыртып куй да баланы кабыз смартфонны – ә үзең үз комфортың эчендә яшә. Йә булмаса, дөнья ку, тормышны кайгырт… Социологлар инде шактыйдан «ана капиталы ыруы» булган сабыйлар плеядасы турында чаң кага. Мәхәббәт яшәмәгән гаиләдә кадерсез булып үсеп килгән Катя – безнең чынбарлыкның куркыныч бер чагылышы түгелме? Аңа берәү дә әкиятләр укымый, аны берәү дә кочагына алып сөйми, аңарга гаиләсендәге «өлкәннәр» үзенең төзәлеп бетмәгән балачак җәрәхәтләреннән калган комплексларын чыгарып чәчә, аны ачыктан-ачык рәвештә мокыт итеп күрәләр һәм мокыт булырга өйрәтәләр. Ул үз дөньясына китеп яшәгән арада өлкәннәр компьютер артына утырып пасьянс тезә, бер-берсе белән акырыша-бакырыша. Ул тәрбияләнгән йортта китаплар юк, наз яшәми… Андагы бер шкафка оялаган Бичура гына, иптәш табылуына сөенеп, тантана итә. Әмма, көннәрдән бер көнне, ул Бичураны да юк итәләр. Ә бит рус мифологиясендәге Кикимора без ияләшкән Бичурадан аерылып тора – аның өйдә пәйда булуы хәвеф-хәтәр билгесе.

Гоголь, Ремизов, Платонов, Искандер, Петрушевская чалымнары бар бу яшь авторда, дип таба тәнкыйтьчеләр. Әйе, һәм әле тагын – Диккенс, Гюго, Короленко… Саный китсәң – җитәрлек. Ул – үзенә кадәрге «җәберсетелгән», «кечкенә кешеләр» яшәешен бар хәтәрендә ачып күрсәтүчеләр исемлегендәге тагын берәү. Катясы да әле Козеттаны хәтерләтә безгә, әле Тыбурцийның нәни кызчыгы Марусяны… Әмма Евгения Некрасовада үзенә кадәргеләргә иярү, аларның күләгәсендә таптану юк. Ул – авторларча өслүбен анык эзләп тапкан, аяусыз да, гаҗәеп нечкәлирик та чынбарлык моделен шикләнмичә тудырырга өлгергән язучы. Үз тел структурасын. Һәм бу тел органикасы сокландыргыч эффект тудыра! Дөресен әйтим, минем күптәннән рус теленең халыкчан бормаларын болай иңләп йөргәнем юк иде…

Евгения Некрасова романнарын тагын озак еллар дәвамында укыйсы, аларны көтеп аласы, дуслар, фикердәшләр белән бүлешәсе килә. Һәм бу әсәрләрнең дөньяны чыннан да мәрхәмәтлерәк итүенә дә – тере шаһит буласы.

«Искитмәле, мин ничек кинәт шулай олы булып үсеп җиттем соң әле», – дип уйлап куйды Катя.

Ә аннары күптән түгел генә Кикимора утырган табуретны тәрәзә төбенәрәк этте. Андагы гөл савытларын идәнгә алып куйды. Икенче бүлмәдә әтисе белән талашкан әнисенең тавышы акрынлап сүрелә башлады. Әтисе дә, ызгышка нокта куярга теләп булса кирәк, кухняга таба атлады. Катя табуретка менде дә, юеш джинсы чалбары чабуларына баса-баса, тәрәзәне ачып җибәрде. Йөзенә шунда ук тешләк кышкы җил китереп бәрде. Катя тәрәзә төбенә утырды һәм кап-кара упкынга борылып бакты. Кешеләр, машиналар, гаражлар, балалар уйный торган таныш мәйданчык, этләр, чүп контейнеры, малай-шалайлар белән ул төзегән кар сарае – болар барысы да шундый кечкенә, тәмам лилипутларча булып күренде аңарга. Кул сузуың җитә – рәхәтләнеп урыннарыннан күчереп уйный башларга була, әйтерсең. Катя аякларын әле һаман да кухня ягында селки-селки утыра бирде. Ишек артында барлыкка килгән ыгы-зыгы көчәя төште. Ишек токасына кысытырып куелган швабра дуамалланып селкенергә керешә. Менә-менә атылып чыгачак. Шул мизгелдә Катя Ольга Митиевнаның сөйләгән бер бәянен искә төшерде. Кикимораларның каян килеп чыгуы турында иде ул бәян. Кикиморалар – терелләр дөньясында берәүгә дә кирәге чыкмаганга, башка дөньяга күчәргә мәҗбүр булган бәләкәчләр, дигән иде ул… ■

МАХСУС ПРОЕКТ

— 46нчы чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

Наил Мәһдиев, Яр Чаллы шәһәре мэры, октябрьдә үзенең 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Тотрыклылык һәм иртәгәге көнгә ышаныч гаранты

Мәҗит Салихов,
«ТР ДЭБИ» ДАУ башлыгы

– Хөрмәтле Наил Гамбәрович! Сезне юбилеегыз белән котларга рөхсәт итегез!

Без Сезне оста идарәче, Россия сәнәгатенең иң эре үзәкләренең берсе булган шәһәрнең һәрвакыт зур максатларга омтылган көчле һәм зирәк җитәкчесе буларак беләбез.

Яр Чаллының потенциалы бик зур. Автомобильләр каласы бүген – актив үсештәге территория, илебез һәм чит ил инвесторларының игътибары аңа юнәлгән. Биредә куәтле сәнәгать потенциалы, уңайлылык һәм социаль-мәдәни тармакның байлыгы кабатланмас рәвештә ярашкан, берләшкән. Туган ягыгыз үсешенә керткән гаять зур хезмәтегез хөрмәт уята. Сезнең күпьеллык эшегезнең нәтиҗәләре башка моношәһәрләр өчен прогрессив үсеш һәм алгарыш моделе үрнәге булып тора.

Актив тормыш позициягез һәм эшләрегезнең колачлылыгы белән Сез республика халкы арасында зур абруй һәм тирән хөрмәт казандыгыз. Бүген Сез халык өчен тотрыклылык һәм иртәгәге көнгә ышаныч гарантына әверелдегез.

Динамик эш стиле, искиткеч фидакарьлек, максатчанлык, шәһәр тормышының төрле юнәлешләренә кагылышлы мәсьәләләрне хәл итүдәге принципиальлек – Татарстаныбыз файдасына колачлы яңа сорауларны хәл иткәндәге көчегез һәм өстенлегегез әнә шуларда!

Хөрмәтле Наил Гамбәрович! Сезнең юбилей – яшәү көче тәҗрибә хисабына күп тапкырлар артып, мөмкинлекләр ача торган истәлекле көн. Сезгә ихлас теләгем: заман белән бергә баруны дәвам итегез! Игелекле һәм кыю уй-ниятләрегезне, идеяләрегезне тормышка ашырганда, илһам чишмәгез саекмасын! Сезне иман һәм өмет ташламасын, ә йортыгызда һәрвакыт тынычлык һәм татулык хөкем сөрсен! Сезгә һәм якыннарыгызга сәламәтлек һәм иминлек телим!

Реклама

Фото «ТР ДЭБИ» ДАУнән алынды

Николай Николаев, «ЛУКОЙЛ» ГАҖ вице-президенты, «РИТЭК» ҖЧҖ генераль директоры, октябрьдә үзенең 65 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Нефть – кешеләр өчен

Александр Герасименко, «ПетроИнжиниринг» Инновацион сервис компаниясе» ҖЧҖ генераль директоры

Фото «ПетроИнжиниринг» ИСК» ҖЧҖдән алынды

Реклама

– Хөрмәтле Николай Михайлович! Бездән ихлас котлауларны кабул итеп алыгыз, һөнәри уңышлар һәм гаилә иминлеге Сезгә!

Бүген илебезнең нефть предприятиеләре күп кенә яңа бурыч-мәсьәләләр белән очраша, аларны чишү өчен өчен матди-техник базаны даими камилләштерү һәм нефть чыгаруның яңа ысулларын гамәлгә кертү таләп ителә. Предприятиенең һәм бөтен тармакның уңышы да әнә шул эшләрнең нәтиҗәлелегенә бәйле. Инде 10 елга якын Сез җитәкләгән «РИТЭК» ҖЧҖ нефть бирүчәнлекне арттыруның яңа технологияләрен булдыруның һәм авыр чыгарыла торган углеводород запаслары кебек стратегик мөһим ресурсны үзләштерүнең авангардында бара. Россия нефть табу сәнәгатендә инновацияләр булдыруга һәм аның көндәшлеккә сәләтен үстерүгә керткән өлешегез бәяләп бетергесез.

Сез – кайчандыр үзегез сайлаган шактый авыр хезмәт юлына тугры калып, яңа офыкларны максатчан рәвештә яулап килүче чын профессионал. Нефть табу тармагында дистәләрчә еллар эшләү дәверендә сез күпсанлы проектларны башлап җибәрдегез, алар үзләре тормышка ашырылган территорияләрнең социаль-икътисадый үсешенә нык ярдәм итте.

«Кешеләр нефть өчен түгел, ә нефть – кешеләр өчен», – дигән девизга таянып, «РИТЭК» иң югары максатларга ирешүгә, җитештерү һәм фән бурычларын үтәү һәм арттырып үтәүгә, социаль йөкләмәләрне тормышка ашыруга юнәлтелгән эшен теләсә нинди шартларда да алып бара. Компания Волгоград, Самара өлкәләрендә, Татарстан Республикасында колачлы социаль-мәдәни проектларны гамәлгә ашыра. «РИТЭК» белән безне күптәнге тотрыклы һәм нәтиҗәле партнерлык мөнәсәбәтләре бәйләп торуына ихлас шатланабыз һәм горурланабыз.

Сезнең уңышларыгыз, җитәкчелек таланты, тирән белемегез һәм тәҗрибәгез төбәк һәм федераль дәрәҗәдә күп тапкырлар билгеләп үтелде. Тыгыз график буенча эшләвегезгә дә карамастан, төбәкләргә килергә һәм предприятие хезмәткәрләре белән аралашырга, мөһим мәсьәләләр, аларны чишү юллары буенча фикер алышырга вакыт табасыз, шул рәвешле җитештерү процессында катнашучылар белән мөһим элемтәне саклап, бу эшнең нәтиҗәлелеген арттырасыз.

Әлеге истәлекле көндә үз алдыгызга куйган максатларга ирешүегезне телибез! Хезмәттәшләрегез һәм фикердәшләрегезнең ярдәмен, туганнарыгыз һәм якыннарыгызның кайгыртуын тоеп яшәгез! Ныклы сәламәтлек һәм уңышлар Сезгә!

Инновацияләр – тотрыклылык ул



Илшат Гафуров, Казан (Идел буе) федераль университеты ректоры

Фото КФУдан алынды

Реклама

– Хөрмәтле Николай Михайлович! Казан (Идел буе) федераль университеты коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән чын күңелдән котлыйм!

Дөнья, һәрхәлдә, фән һәм технологияләр дөньясы, пассионарийлар, башкалар кайчак аяк басарга да җөрьәт итмәгән юллар буйлап кыю атлаучы кешеләр тарафыннан хәрәкәткә китерелә. Бу фикер нефть тармагына да кагыла, бүгенге көндә анда, мәшһүр китап сүзләре белән әйтсәк, «бер урында калу өчен дә бик тиз йөгерергә» кирәк. Сезнең кебек эшчән, тәҗрибәле, җаваплы профессионаллар ярдәмендә илебезнең нефть һәм газ чыгару предприятиеләре алга бара, каршылыклар мөмкинлекләргә һәм өстенлекләргә әверелә. Сез эшләгән еллар, максатчан күрсәткечләрне үтәү өчен генә түгел, нефть чыгару предприятиеләрендә эшләүче меңләгән кешеләр өчен дә зур әһәмияткә ия җиңүләр һәм казанышлар белән тарихка керде. Инновацияләр аларның хезмәт шартларын – уңайлырак, эшләрен – нәтиҗәлерәк, тормышларын сыйфатлырак итә. Ә хезмәткә хөрмәт һәм аңа лаеклы түләү илнең икътисадый тотрыклылыгына һәм чәчәк атуына нык нигез булып тора.

Сезгә яңа масштаблы проектлар, планнар, идеяләр һәм аларны тормышка ашыру өчен дәрт-дәрман телим! Сезгә һәм якыннарыгызга сәламәтлек, иминлек һәм бәхет насыйп булсын! Юбилеегыз белән!

Рәис Сөләйманов, «Агро-Инвест» идарә компаниясе ЖЧҖ генераль директоры, октябрьдә үзенең 50 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

– Хөрмәтле Рәис Әхтәмович!

Алмаз Әхмәтшин, Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре башлыгы

Сезне Нурлат районы халкы һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз белән чын күңелдән тәбрик итәм! Язмыш һәрвакыт Сезгә игелекле караштa булсын! Юбилей елы бары уңай хис-кичерешләр генә алып килсен, ә оптимизм һәм уңыш даими юлдашыгызга әверелсен!

Без Сезне Нурлат районының агросәнәгать комплексы үсешенә зур өлеш керткән уңышлы идарәче буларак беләбез. Сезнең җитәкчелектә район аграрийлары искиткеч уңышларга ирешә: районыбыз авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү буенча алдынгылар рәтенә керә.

Сезнең мөһим сыйфатыгыз – үз хезмәтегезгә һәм якыннарыгызга карата тугрылыкны аерым билгеләп үтәсем килә. Сүздә һәм эштә тугры булу ягыннан күпләргә Сездән үрнәк алырлык. Уңышка ирешәчәгегезгә ышанып, шул ышаныч белән янәшәгездәгеләрне рухландыра белү Сезгә тормыш юлыннан яңа җиңүләр яулый-яулый атларга ярдәм итә.

Фидакарь хезмәтегез, әйткән сүзгә тугры калуыгыз, хезмәт сөючәнлегегез, куелган бурычларга ирешүдә нык торуыгыз өчен, Сезне ихлас хөрмәт итәм. Һичшиксез, Сезнең горурланырлыгыгыз бар. Хезмәт биографиягез бай һәм нәтиҗәле, ул исә уңышның көчлеләргә, катлаулы сорауларны чишүдән, авырлыктан курыкмаганнарга, вәгъдәләр чәчмичә, эш күрсәткәннәргә, алай гына да түгел, лаеклы эш күрсәткәннәргә елмаюын раслый. Һәр кеше, Сезнең кебек, янәшәсендәгеләр турында кайгыртып яшәсә һәм битараф булмаса, җәмгыятьнең иминлеге турында һәрдаим сөйләргә булыр иде.

Рәис Әхтәмович! Сез бергә яшәү һәм эшләү бәхете тигән туган җиребезнең чын патриоты булып торасыз. Һәрвакыт шундый тәвәккәл һәм дәрт-дәрманлы булып калыгыз. Сезгә бәхет, тыныч күк йөзе һәм уңышлар телим! Һәм, әлбәттә, якыннарыгыз, тугрылыклы дусларыгыз һәрвакыт янәшәгездә булсын!

Фото Нурлат муниципаль районы хакимиятеннән алынды

Актив тормыш һәм киң күңеллелек

Фото «Татнефтепром-Зузэйнефть» АҖ тарафыннан бирелде

Шамил Яһудин, Татарстан Республикасы алтынчы чакырылыш Дәүләт Советы депутаты, «Татнефтепром-Зузэйнефть» АҖ генераль директоры

– Хөрмәтле Рәис Әхтәм улы, 50 яшьлек гомер бәйрәмегездә яңгыраячак бик күп җылы теләк-котлауларга кушылырга рөхсәт итегез! Сез үзегезне ышанычлы, тәвәккәл, эш сөючән хезмәттәш һәм чын профессионал итеп күрсәттегез. Сез авырлыклардан курыкмыйсыз һәм үз өстегезгә кыю рәвештә зур җаваплылык аласыз. Алдынгы карарларыгыз белән бизнесны алга этәрәсез, республика икътисады үсешенә ярдәм итәсез.

Авыл хуҗалыгын үстерүдә һәм Татарстанның азык-төлек бәйсезлеген тәэмин итүдә өлешегез бик зур. Сезнең бу өлкәдәге казанышларыгыз күп тапкырлар иң югары дәрәҗәдә билгеләп үтелде. Сез теләсә кайсы эшкә алынырга һәрчак әзер, хәйриячелектә дә актив катнашасыз.

Рәис әфәнде! Сезгә һөнәри эшчәнлегегездә чын күңелдән уңышлар, шәхси тормышыгызда гармония һәм бәхет телим. Тормышыгызның һәр елы иҗади энергиягә бай булып, туганнарыгызның һәм якыннарыгызның йөрәк җылысына тиенсен. Ә һәр яңа көн башкарылган эшләрдән канәгатьлек хисе һәм алга барырга омтылыш алып килсен. Ныклы сәламәтлек һәм иминлек сезгә!

Ирек Закиров, «Татагропромстрой» ААҖ генераль директоры, сентябрьдә 70 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Сизгер йөрәк һәм зирәк акыл иясе

Фото «Татптицепром» ҖЧҖ тарафыннан бирелде

Марс Алиев, «Татптицепром» ҖЧҖ генераль директоры, авыл хуҗалыгы фәннәре докторы, профессор, Россия агросәнәгать комплексының мактаулы хезмәткәре, РФ Дәүләт премиясе лауреаты

Хөрмәтле Ирек Мөнирович, юбилей көнегездә Сезнең адреска яуган бик күп җылы сүзләргә һәм котлауларга кушылырга рөхсәт итегез!

Сезнең тормыш юлыгыз шактый катлаулы, шул ук вакытта матур һәм гыйбрәтле дә. Комсомолда чыныгу, Казан төзелеш институтында үзеңне практик инженер һәм теоретик галим буларак сынау... Аннары һөнәри үсешнең иң югары ноктасы – «Татагропромстрой» ширкәте җитәкчесе вазыйфасы.

Сезнең җитәкчелектә компания икътисадның мөһим секторында иң алдынгылардан булды, Татарстан Республикасының бөтен Россия күләмендә лидерлыгын тәэмин итүгә бәяләп бетергесез өлеш кертте.

Сезне бик күп тармакларда, бик күп рольләрдә беләләр, аларның һәрберсендә тиңсез сыйфатларыгыз чагыла. Сез – стратег менеджер, иң югары дәрәҗәле профессионал, сез – Буа якташлык җәмгыяте «генералы», үз авылының, үз милләтенең тугры улы. Сез кешеләрне яратасыз һәм кадерлисез, ихлас елмая беләсез (бу – кабатланмас бизәк), тирә-юньдәгеләргә җылылык, яктылык һәм өмет бүләк итәсез.

Минем өчен Сез, беренче чиратта, якташ, җандай якын дус, фикердәш. Яхшы кешеләр кояшка тиң була: алар янында җиңел һәм күңелгә рәхәт – бу яктан миңа бәхет елмайды.

Кыю рухлы, тулыканлы күркәм язмыш үрнәге өчен Сезгә ихлас рәхмәт.

АРТАШ: КЕЧКЕНӘ АВЫЛНЫҢ ҮЗ РӘХӘТЕ

Авылларга барабыз да, андагы яшәү рәвешенә, кешеләренә таң калып кайтабыз. Һәм ничек шундый табигатьне, матурлыкны ташлап китә алдык икән, дип уйлый башлыйбыз. Иң кызыгы – бу уртак фикер: фотографыбыз, машина йөртүчебез дә шулай уйлый. Мамадыш районының Арташ авылыннан кайтканда да янә шул турыда сөйләштек.

Клуб җитәкчесе Марсель Шәйдуллин белән элеккеге колхоз рәисе Хәлим Сәләхов.

«АЗАН ТАВЫШЫ ЯҢГЫРАСЫН»

Арташ зур түгел: биредә 100 кеше яши, 55 хуҗалык бар. Башлангыч мәктәпне биш ел элек ябып куйганнар, чөнки бала саны аз. Мәктәп яшендәге биш бала бар икән. Алар укырга күрше авылга йөри. Арташның клубы бик үзенчәлекле. 1932 елда төзелгән бина ул. Карап торышка өлкән кешене хәтерләтә: бер яккарак янтайган. Балчыктан эшләнгән бу бинаны аз-маз ремонтлаганнар үзе, тик капиталь ремонт бер дә кермәгән.

– Клубка ремонт кайчан буласы билгеле түгел әле, – диде Урта Кирмән авыл җирлеге башлыгы Булат Хәсәнов. – Тыштан шактый таушалган күренсә дә, эче әйбәт аның.

Чынлап та, клубның эчке ягы начар түгел. 100 кеше сыйдырышлы залы, махсус сәхнәсе бар. Декорацияләр дә эшләп куйганнар. Клубның җитәкчесе Марсель Шәйдуллин белән дә таныштык. Җыр-моңга һәвәс кеше икән.

Фото: Лилиана Валитова



– Районда бездән дә карт авыл клубы юк, – диде Марсель абый. – Ләкин аңа карап моңаеп утырмыйбыз. Бөтен бәйрәмнәргә концертлар оештырабыз. Халык өчен очрашу, күңел ачу урыны да бу. Яңа мәдәният йорты булган авыллардан бер дә ким яшәмибез. – Арташта халык саны гел шулай аз булганмы? – дим клуб мөдиренә.

– Арташ элек тә әллә ни зур булмаган. Тарихи документларда: «1859 елда 217 кеше яшәгән», – дип язылган. Аннан халык саны арткан. Революциягә кадәр авылда җан исәбе 800 тирәсе булган. 1914 елда Арташта көчле янгын чыгып, алтмышлап хуҗалыкны юк иткән. Менә шуннан авыл кечерәя башлаган. Колхозлар җимерелгәч, бу кимү тагын да көчәйде. Яшьләр шәһәргә китү ягын карый бит.

Арташта бер манзараны күреп гаҗәпкә каласың: сиксән биш ел элек төзелгән клуб бинасы каршында заманча төзелгән мәчет тора. Бу ике гасырның бергә кисешү ноктасы кебек тоелды. Мәчет быел гына ишекләрен ачкан. Иман йортына 2014 елда нигез салынган булган. Аның төзүчесе – Казан егете, **эшкуар Илнур Усманов**.

– Арташ – әниемнең туган авылы, – диде эшкуар. – Һәр каникул саен монда кайттым. Авылның һәр урамы, һәр тыкрыгы минем өчен якын, кадерле. Әби-бабайлар еш сөйли иде: революциягә кадәр авылда мәчет булган. Дингә каршы сәясәт алып барыла башлагач, мәчетнең манарасын кисеп, мәктәп ясаганнар. Күңелдә бер теләк бар иде: яңадан шушы урында иман йортын торгызырга... Бала саны аз булу сәбәпле, иске биналы мәктәп ябылды һәм аның урынына менә шушы иман йортын салып куйдык.

Илнур тыйнак егет. Мәчет төзүне ул ниндидер бер батырлыкка да, гаҗәеп эшкә дә санамый.

– Дөресен генә әйткәндә, бу турыда бик сөйлисем дә килми, – диде. – Мактану кебек килеп чыга. Дәү әнием, дәү әтием рухы шат булсын, авылыбызда һәр көн азан яңгырасын дип эшләдем. Рәхмәт яусын авыл кешеләренә, гел ярдәмгә килделәр. Нәрсә әйтсәм дә каршы килүче булмады...

Арташның яңа мәчете янында искесе дә тора. Иске, дип, ул 1992 елда төзелгән. Әйе, яңасы кебек ике катлы, зур түгел, шулай да авыл кешеләренә гыйбадәт кылу өчен урын булган. Ә яңа мәчет ачылу җирле халык өчен тарихны торгызу да, иманга килү өчен тагын бер форсат та.

Яңа мәчетнең әле сайлап куелган мулласы юк. Бу эшләрне **Фоат абый Сафин** башкара икән.

– Минем бабай 1992 елда ачылган мәчетнең мулласы иде, – дип сөйләде хәзрәт. – Хәтерлим, мәчетнең нигезенә такта җәелгәч, авыл картлары шунда намаз укый башлады. 27 ел буена мәчет бер көн дә ябылмады. Инде яңа мәчетебез дә көн саен авыл халкын намазга дәшәр, күңелләренә иман салучы бер изге урын булыр дип ышанам.

Автор:
Руфия Фазылова

«ЧӘЧӘК ЯРАТМАГАН КЕШЕ ЧИГӘ АЛМЫЙ»

Арташта Мамадышка гына түгел, бөтен республикага атаклы чигү остасы яши, шунда юнәлдек. Ерактан ук балкып торган капка төбенә килеп туктадык. Бөтен җирдә аллы-гөлле чәчәкләр үсә. Ишегалдына кергәч, матурлыкка янә бер сокландык. Каршыбызга чигүле алъяпкыч бәйләгән бик сөйкемле апа чыкты, хуҗабикә Зәкия Әхмәтгәрәева икән. Якын туганнарын каршы алгандай, кочаклап ук алды.

– Мондый зур чәчәк бакчасын берүзегез карыйсызмы? – дидем.

– Үзем, – ди Зәкия апа. – Чәчәкләрне бик яратам. Иртә яздан шулар белән мәш килә башлыйм. Күңелгә рәхәтлек бирә ул. Әле өйдә гөлләрем дә күп. Шуны әйтим: чәчәк яратмаган кеше чигү чигә алмый.

Өйгә уздык. Зәкия апаның йорты бер күргәзмәне хәтерләтә: ишек чаршавыннан башлап тәрәзә пәрдәсенә кадәр чигүле аның. Мендәр тышлары, урындык япкычлары турында әйтеп тә тормыйм.

– Боларның барысын да үзегез чиктегезме? – дим.

– Әйе, үзем. Хәзер дә чигәм. Чаршауларны яңартып торырга тырышам. Төрле чәчәкләрдән эшлисе килә бит.

Зәкия апага 75 яшь икән. Ун яшеннән бирле бәйли-чигә ул. Тамбур энәсе белән әнисеннән күкрәкчә бәйләргә өйрәнгәнен әле дә хәтерли.

– Әнием атаклы кул эшләре остасы иде. Җепне аның кебек әйбәт эрләүчеләр сирәк очрый. Чигүне дә бик матур, тиз эшли иде. Без, өч кыз туган, әнинең дәвамчылары. Барыбыз да оста чигә, бәйли.

Зәкия апа ике ул, бер кыз үстергән. Балалары гаиләләре белән Алабуга шәһәрендә яши икән. Алты оныгы бар. Без килгән көнне оныгының баласы туган иде. «Карт дәү әни булдым», – дип зур сөенече белән уртаклашты.

Зәкия апа тормышны сөя торган затлардан. Һәр нәрсәгә шөкер итеп, елмаеп, балкып сөйләшә ул. Бакчада ялгызы бәрәңге алуны да, төнгә кадәр бәйләү, чигүне дә авыр эшкә санамый.

– Эшсез тора алмыйм, – диде Арташның ак әбие. – Балалар үскәндә дә көндәлек эшләр бетүгә, челтәр, шәл бәйләдем. Хәзер күбрәк йон оекбашлар, башмак, бияләйләр бәйлим. Оныклар, балалар яратып кия. Әйбер юк заманнарда, кешеләр сорагач, кофта-штан кебек кием-салымнар да бәйләп бирдем.

– Алайса бу сезнең өчен мавыгу гына түгел, аз булса да акча эшләү мөмкинлеге дә булгандыр, – дим.

– Юк, кул эшләремне сатмадым, сатмыйм да. Кешедән акча ала белмим мин. Кучтәнәч бирәләр иде үзе, тик сорап алмадым. Әле менә хәзер Коръән тутырам. Шулай ук акча алмыйм. Иң кыйммәтлесе – кешегә яхшылык эшлим, дус булып калам. Мин мохтаҗлыкта үскән бала түгел, ирем белән дә тилмереп яшәмәдек. Шуның өчен акча дип җан атмыйм. Булганына канәгать. Аллаһы Тәгалә биреп тора бит әле. Менә бу йортны да ирем үлгәннән соң эшләп чыктык. Балалар ярдәм итте.

Зәкия апа – «урман баласы». Әтиләре урманчы булган. 10 бала шунда үскәннәр. Урман һавасы сулап үскәнгәдер, нык, көчле булганнар.

Зәкия апа актив тормыш рәвеше алып бара. Районда узган төрле конкурсларда катнаша, заманча әйтсәк, мастер-класслар үткәрә. Аның кул эшләрен Казанга күргәзмәләргә дә алып китәләр, хәтта Прагадан сораганнар.

– Төнге бергә кадәр кул эшләре белән утырам, – ди оста. – Бакчада арып кергәннән соң шулай ял итәм. Кулга энә тотмыйча бер көн калганым юк.

Саубуллашканда Зәкия апа безгә дә үзе бизәкләп бәйләгән бияләйләр бүләк итте. «Кирәкми», – дип карышып торсак та:

– Минем төсем итеп киярсез. Йөрәк җылым кергән аңа, – диде.

Рәхмәт, Зәкия апа, Арташта булган ул эссе көнне салкын кышларда гел искә алырбыз.

– Чәчәк яратмаган кеше чигү чигә алмый, – диде Зәкия Әхмәтгәрәева.

ИКЕ ГАИЛӘНЕҢ БЕРСЕ – УМАРТАЧЫ

Мамадыш төбәге республикада иң күп умарта тотучылар районы булып дан казанган. Арташта да һәр ике йортның берсендә умарта тоталар. Бу аларга ата-бабаларыннан күчеп калган шөгыль.

Без авылның иң тәҗрибәле умартачысында – Рәкыйп Гатин хуҗалыгында булдык. Аның фермер хуҗалыгында якынча 150 баштан артык умарта бар. Баш саны күп булгач, аны төгәл генә әйтү дә авыррак икән.

– Берничә ел элек баш саны 200дән артык иде, – диде Рәкыйп абый. – Хәзер азрак кимеде. Кортлар алар тиктормас, әле очып чыгып китәләр, әле өер булып очып керәләр. Шуңа күрә санап җитешеп тә булмый. Күзгә төгәл әйтеп була инде.

Рәкыйп абый умартачылар нәселеннән. Бабасы тирә-юньдә дан тоткан умартачы булган. Ә менә әтисе, икенче группа сугыш инвалиды булганлыктан, күпләп корт асрый алмаган. Шулай да Гатиннар беркайчан кортсыз яшәмәгән.

Рәкыйп абый 1986 елда колхоз умарталыгында эшли башлаган. Күмәк хуҗалык таралгач, бу эшне үз кулына алган.

– 140 оя кортны, ел саен бер тонна бал бирү шарты белән, күмәк хуҗалыктан арендага алдым, – ди Рәкыйп абый. – Берничә елдан бөтенләй сатып алдым. Ул вакытларда баш саны 250 дән артып китте.

Шунысын да әйтергә кирәк: Гатиннар кортларны үзләре генә карый. Рәкыйп абыйның тормыш иптәше Рузилә апа да умартачылар нәселеннән икән. Кортлар белән эш итү тәртибен белә ул. Балалары да булыша, ди.

– Әле минем арендага алган җирләрем бар, техника да сатып алдым, – ди фермер. – Кырда эшләргә кеше чакырам, ә менә кортларны кешегә ышанмыйм. Гаилә белән эшлибез. Хатынымның энекәше дә умартачы, ул да булыша.

Фермер кортларын аланда тота. Арендага җир алуның сәбәбе дә кортлар белән бәйле. Аларга бал җыярга урын булсын өчен төрле үләннәр – фацелия чәчәге, әңгерәк уты, тукранбаш, тәкәмөгез (донник) чәчкән. Кышын кортларны саклау өчен таштан сарай эшләгән. Аны балчык белән күмеп калдыра икән.

Рәкыйп Гатин хуҗалыгында 150 баштан артык умарта бар.

– Тагын 8 келәтем дә бар, – диде фермер. – Бер елны, төзелеш эшләре белән йөреп, кортларга игътибар җитмәде. Шул елны кортлар, бетләп, күбесе үлде. Кырык баш кына калды. Хәзер ел да ояны махсус препарат белән эшкәртәм. Башка химик матдәләр кулланмыйм.

Гатиннар хуҗалыгында быел бал уңышы уртача булган. Алдагы еллар белән чагыштырганда кимрәк, әлбәттә. Шулай да зарланырлык түгел. Хуҗалар балны урнаштырып бетергән инде. Ел саен ала торган клиентлары бар икән.

Рәкыйп абый кортлардан бер дә курыкмый. Кызык итеп менә ничек сөйләде:

– Корт чакса сизмим дә. Эш беткәч, тәнгә кадалган корт укларын чүпләп алам яки сыпырып кына төшерәм.

Бу гаиләнең үзләрен дә бал кортларына охшаттым: бер дә тик тормыйлар. Юмор белән сөйләшәләр, мәзәкчәннәр, тормышка авыр итеп карамыйлар. Менә шуңа да эшләре уң барадыр кебек тоелды

...Арташка баргач, бик күп кешеләр белән очраштык, барысы турында бер язмага кертеп кенә бетереп булмый. Дөресен генә әйткәндә, бөтен авылларда да тарих, авылның үткәне, киләчәге дип җан атып тормыйлар. Ә Арташта бөтенләй икенче хәл. Хәтта элеккеге колхоз җитәкчесе Хәлим Сәләхов та килгән иде. Район үзәгендә яшәсә дә, Арташны онытмый икән.

– 1990 елга кадәр безнең колхоз республикада өченче урында иде, – диде ул. – Колхозга кергән өч авыл арасыннан Арташ иң кечкенәсе булса да, иң бердәме, иң тырышы булды. Колхоз таралгач, Арташны аерып алып, бер хуҗалык итеп ясамакчы идем, барып кына чыкмады. Арташлылар белән утны да, суны да кичәргә була. Монысын курыкмыйча әйтәм.

Шулай икәненә ышанам да. Гомумән, Мамадышта бик тырыш кешеләр яшәвенә шигем юк. Республика буенча умарта асраучыларның иң күбе биредә икәнен исәпкә алсак та, моңа инанырбыз. Умартачылык белән уңган кешеләр генә шөгыльләнә. Арташ исә районның кечкенә, бик тырыш бер авылы. Биредә кешеләр ерактан ук сине елмаеп сәламли, өенә чакыра. Каралты-куралар матурлап эшләнгән, бакчалар чәчәккә күмелгән... Татар авылларына хас бер җыйнаклык, пөхтәлек бар. Шуңамы икән, Арташтан бер дә китәсе килмәде.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

– Архив документларыннан күренгәнчә, Арташ авылына 1710 елда нигез салынган. Атамасына килгәндә, төрле фикерләр бар. Монда башта удмуртлар яшәгән дип фаразлыйлар. «Ар» исеме шуннан калган булырга мөмкин. Арташта удмуртлардан кала мари, татар, башкорт халыклары яшәгән. Монысы бәхәссез. «Таш» исеме дә юктан гына килеп чыкмаган. Безнең авыл ак ташка бик бай. Җир казысаң да, болынга чыксаң да, гел ташка юлыгасың.

Гомумән алганда, Арташның тарихын яңадан өйрәнәсе бар. Андый теләк белән күптәннән янам.

Шаһинур Мостафин, әзтабар язучы.

Александр Ефремов фотолары

БӨЕК ПОЛКОВОДЕЦНЫҢ **ЕГЕТЛЕГЕНӘ ЛАЕКЛЫЛАР**

Сентябрь аенда Казан Суворов хәрби училищесы үзенең 75 еллыгын билгеләп үтте. Юбилейны хәрбиләрчә җитди итеп – парадлар һәм бүләкләр белән үткәрделәр. Яшь суворовчыларның тигез сафлары артыннан ныклы адымнар белән училищены әүвәлге елларда тәмамлаганнар – пенсионерлардан башлап узган елгы чыгарылышка кадәргеләр атлады. Хәрби әзерлекләре бу тантаналы сәгатьтә барысына да ярдәмгә килде һәм беркем дә училищеның дәрәҗәсен төшермәде. Чөнки суворовчыларда дисциплина ягыннан һәрвакыт тулы тәртип булды: училищега исеме бирелгән шәхес үзе дә «дисциплина – җиңүнең анасы!» – дип кабатларга яраткан бит. Юбилярларны Татарстан Президенты исеменнән ТР Премьер-министры урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин котлады: «Бу диварлар арасында рух нyклыгы һәм патриотлык хисе тәрбияләнә, илебезнең хәрби әзерлегенә нигез салына», – дип ассызыклады ул. Ә иң өлкән чыгарылышлар, барлык суворовчылар «атасы» – Александр Васильевичның васыятьләрен искә төшергәндә, югарыда әйтелгән сүзләргә үзара түбәндәге фикерне дә өстәделәр: «Солдатка сәламәт, батыр, нык, тәвәккәл, гадел, иманлы булу фарыз».

Булачак полководецларны һәм ил сакчыларын Россия оборона министры Сергей Шойгу да котлады. Аның сәламләү сүзен РФ Хәрби көчләренең Коры җир гаскәрләре башкомандующие, армия генералы Олег Салюков укыды: «75 ел дәвамында Казан Суворов училищесы гомуми һәм махсус әзерлекнең югары дәрәҗәсе белән дан тота, үзенең бай традицияләрен кадерләп саклый һәм үстерә. Училище киләчәктә дә бөек полководец Александр Суворов егетлегенә лаеклы Ватан патриотларын тәрбияләүдә әйдәп баручы урыннарның берсендә торыр дип ышанам».

75 ел эчендә Казан Суворов училищесы 12 меңнән артык егетне тормышка путёвка белән тәэмин итте. Аларның унысы Советлар Союзы Герое яисә Россия Герое исеменә лаек булды, 130дан артыгы – генерал, 11е – академик, йөзләрчә чыгарылышы фән докторлары һәм кандидатлары дәрәҗәсенә иреште. Суворовчыларның һәр буыны да алган профессиясеннән канәгать, чөнки «Кем батыр, шул исән. Кем кыю – шул тере!» – полководец Суворовның тагын бер зирәк шигаре бу.

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ



Алабуга шәһәре, Казан урамы, 2018 ел.

Фото: Ната Смирнова

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ

Алабуга шәһәре, Казан урамы, 1910 ел.

ТАССР 100 ЛЕТ ЕЛ